Борынгы кеше табигать белән гармониядә яшәгән, аны даими өйрәнгән, тәҗрибә туплаган, үскән, камилләшкән. Кешелек үткән бу эволюция җәмгыятьнең тарихи-диалектик үсешен билгели, һәм ул кеше исемнәрендә дә чагылыш таба. Билгеле бер исемнәрне кушу, икенчеләренә табу кую шул чор кешеләренең мәҗүси ышанулары, йола-традицияләрне исәпкә алып эш итүләре белән бәйле. А.В. Суперанская билгеләвенчә, «исемнең мотивлашуы – күптөрле исемнәрдә тәкъдим ителгән, өйрәнү һәм күзәтү өчен төрле дәрәҗәдә аңлаешлы булган сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше комплексы» [5: 20].

Еш кына ыруг-кабилә башлыгының исеме, кушаматы я булмаса аерым бер җиргә төпләнеп, утырак тормышта яшәүче аерым бер халык белән идарә итүче, әлеге урынга нигез салучының исеме тарихи эволюция барышында авыл, аннан шәһәр исеме дәрәҗәсенә күтәрелеп, ныгып калган. Бүгенге көндә нигезендә антропонимнар яткан авыл, район һәм шәһәр исемнәре байтак.

Антропонимик системада катлам күрсәткече, теге яки бу титул компонентлы атамалар да очрый: Тимерхан, Күчембәй һ.б. Мондый исемнәр ирләргә генә бирелгән һәм аларның җәмгыятьтәге урынын күрсәтеп торган. Титул атамасы кергән антропонимнарның топонимга күчү очраклары да юк түгел: Алабино (Мәскәү), Баймак (Мәскәү), Кочубей (Дагестан), Беково (Пенза) һ.б.

Бүгенге көндә Россия Федерациясендәге шәһәрләр исемлегенә кертелгән мондый шәһәр атамаларының берсе – Ишимбай шәһәре атамасы. *Ишимбай* атамасы чыгышы белән борынгы төрки *иш+бай* – «бай баласы, гаиләсе» сүзләренә карый:

***иш** «один из пары; напарник; спутник», диал. «коллектив; множество (подобных друг другу)» > мар., удм. *эш* < гом. төрки *эш, әш, ээш* [Радлов I: 902; Будагов I: 196; ЭСТЯ I: 313–315; Rdsdnen 1969: 50] id., төр. *еє* «җефет», чув. *йыш* «коллектив, артель; туган-тумача, гаилә, хуҗа», безнеңчә, тат., башк. *иш-* «аллы-артлы, чиратлы, ритмик хәрәкәтләр ясау» белән (*бау ишү, ишкәк ишү,* диал. **иш-ү** «бер-бер артлы сугу; зур, авыр адымнар ясап озак чабу») < гом. төрки *эш-* id. [Радлов I: 871, 872; ЭСТЯ I: 316] белән тамырдаш, ягъни бу сүзләр – бор. төрки телләргә хас булган исем – фигыль парын тәшкил итәләр (чаг. *кат – кат-у, куш – куш-у*), к. алт. диал. [Радлов I: 904] *эш-, дш-* «иярү». *Иш* < *эш, әш* тамырын чув. *ал-* < *әл-* «дөмбәсләү» фигыле белән дә чагыштыралар [1: 108].

Лексик мәгънәсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә (2015-2017) түбәндәгечә бирелә:

***иш** *и.* **1.** 1) Матди, рухи яки башка яктан тиң, пар булырлык кеше, үзе кебек кеше; тиңдәш. <...> *кешеләр, туган чакта ук, үзләренә*

*билгеләнгән ишләре белән туалар <...>*. Ә.Еники. – *Зөмәрә, син үзеңә тиң иш тап, – диде Фаяз, көлә-көлә*. Х.Камалов. *Нәркиснең яшьтәшләре фронтта кырылып беттеләр. Нәркис үзенә иш тапмады <...>*. М. Мәһдиев // Теге яки бу яклары белән бер-берсенә охшаган, бер үк төрле характердагы кеше. *Ә ир-ат халкының барысы да бер иш, дигән сүз хак икән <...>*. Р. Мөхәммәдиев. Димәк, *Ишимбай* полисонимы, башлыча антропоним булып, «бай катламнарның ише, байларга тиң» мәгънәсен белдереп, катлам күрсәткече вазифасын да үтәгән.

Еш кына төрки антропонимнарда бала тууны сорау, ялвару ята. Мисал өчен, Ульяновск шәһәренең элеккеге атамасы *Симбирск* антрополисонимы шушы төр үтенечне үз эченә ала.

*Симбирск* атамасының этимологиясенә бәйле рәвештә берничә бәхәсле караш яшәп килә. В.Ф. Барашков фикеренчә, монгол топонимиясе һәм монгол теле материаллары *Симбир* топонимын монгол теле нигезенә ишарәли. Монголиядә *Сумбэр* – көнчыгыш Гобийск аймагындагы шәһәр, *Сумбур* – тау һ.б. Монгол һәм монгол-бурят телләрендә сумбур сүзе хәзерге көндә дә «изге тау мәгънәсендә кулланыла». Билгеле булганча, монголлар борынгы чорларда ук калку урыннарда гыйбадәтханәләр төзегәннәр. Алар монгол телендә *сум* дип аталганнар. Сумнар урнашкан кайбер тауларшул рәвешле Сумбэр атамасын алганнар. Галим фикеренчә, монгол чорында (XIII-XV) мондый сумның биек идел ярында булуы да бик мөмкин [2: 64].

Безнең фикеребезчә, әлеге полисонимның этимологиясен Г.Ф. Саттаров шактый дәлилле ачыклый. Галим фикеренчә, *Симбирск* атамасы «Симбирск тавы» («Симбирская гора») шәһәре исеменнән алынган. Симбирск атамасының нигезен исә татар ханнарының берсенең исеме хасил итә. Мәгълүм булганча, шәһәр, барлыкка килү моментыннан алып XVIII йөзгә кадәр рәсми рәвештә *Синбирск* дип аталган. Симбирск губернасы авылларын үз эченә алган Чебоксар өязендә В.К. Магницкий тарафыннан башкарылган кеше санын алу вакытында теркәлгән татар һәм чуваш мәҗүси исемнәре арасында *Симбер, Синбиръ, Синбулат, Синдырмыш, Синдимер, Синәхмәт* антропонимнары очрый. Аларның бер компоненты буларак *сөн* «җан» тәкъдим ителә. Бир лексемасы белән килгән төрки исемнәр, Г.Ф. Саттаров билгеләвенчә, әлеге халыкларда ир бала тууы хакында үтенү күренешенә бәйле [4: 180]. Шул рәвешле, Симбирск шәһәрен хаклы рәвештә антрополисонимнар рәтенә кертеп карарга мөмкин.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: кеше исемнәре, фамилияләре, кушаматлары белән мотивлашкан төрки полисонимнар, халык иҗаты үрнәкләре булып, төрки халыкларның көнкүреше, мәдәнияте, гореф-гадәтләре турында хәбәр итә. Төрки антрополисонимнарның нигезендә, асылда, халыкның ышануы, исем кушу үзенчәлекләре чагылуы ачык күренә. Антропонимнарга нигезләнгән шәһәр атамаларының Россия

территориясенең төрле почмакларында урын алуы төрки халыкларның славян кабиләләре һәм халыклары белән тыгыз аралашып яшәвенә дәлил булып тора.

**Әдәбият**

1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге. – Казан, 2015. – 271 с.
2. Барашков В.Ф. Топонимия Ульяновской области. – Ульяновск, 1974. – 80 с.
3. Гарипова Ф.Г. Татарская гидронимия. – Казань, 1998. – 572 с.
4. Саттаров Г.Ф. Мәктәптә туган як ономастикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 208 б.
5. Суперанская А.В. Что такое топонимика? – М.: Наука, 1985. – 177 с.

## МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНДА СПОРТ ТЕРМИНОЛОГИЯСЕ

*Галәветдинова Л., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Д.Х. Хөснетдинов*

Соңгы елларда илебездә спортка аеруча зур игътибар бирелә башлады. Һәркемгә үзе теләгән спорт төре белән шөгыльләнергә мөмкинлекләр көннән-көн арта. Ул физик яктан гына түгел, ә рухи яктан да тәрбияли, ихтыяр көчен ныгыта. Спорт – кешеләр өчен иң мөһим өлкәгә әверелеп бара.

Массакүләм мәгълүмат чараларында да спорт темасы аерым урынны алып тора. Махсус спорт темасына багышланган басмалардан кала барлык газет һәм журналлар да спортка кагылышлы мәгълүматны яктырталар. Телевидениядә спорт редакцияләре эшләп килә, спорт яңалыкларын гына хәбәр итүче каналлар да әз түгел.

Спорт журналистикасы зур тизлекләр белән үсә, үзгәреш кичерә. Әлеге тармакка кына караган төшенчәләр, атамалар, профессиональ жаргоннар төркемләнә башлады. Спорт терминологиясе спортсменнарның, тренерларның, хөкемдарларның сүзлек составының аерылмас өлешен тәшкил итә.

Спорт терминнарын кулланылыш буенча түбәндәгечә төркемлиләр:

1. *Гомуми һәм төрле тармакларга хас булган терминнар:* җәрәхәтләнү, физик әзерлек (медицина өлкәсеннән), мотоцикл, җилкән (транспорт өлкәсеннән);

2. *Барлык спорт төрләрендә дә кулланыла торган терминнар:* хөкемдар, җиңү, җиңүче, җиңелү, тренер, тренировка, турнир, ярыш, финал, әзерлек һ.б;

3.*Бер яки ике спорт төрендә генә кулланыла торган терминнар:* кәшәкә (клюшка), туп, туп тоту, гол, вратарь, сакчы (защитник), сугу (удар), йөгерү, сикерү, хет-трик, уен һ.б.

4. *Бер спорт төренә генә караган терминнар*. Мисал өчен, футбол уены: гекса-трик (спортчының бер уенда алты туп кертүе), инсайд, корнер, пенальти һ.б.

Спорт терминологиясенең татар телендәге массакүләм мәгълүмат чараларында бирелешенә күзәтү ясау өчен, “Ватаным Татарстан”, “Шәһри Казан” газеталарына мөрәҗәгать иттек. Әлеге басмаларда спортка кагышлы мәкаләләр, рубрикалар еш басыла. Кызганыч, татар телендә махсус спорт өлкәсен генә яктырта торган газет һәм журналлар юк. Санап киткән газеталарда без футбол уены турында мәкаләләрне һәм язмаларны барладык һәм футбол уенына кагышлы терминологияне өйрәндек.

Футбол – командалы спорт уены. “Футбол” сүзе инглиз теленнән алынган. “Фут” (foot) – “аяк”, “бол” (ball) “туп” дигән мәгънәне аңлата. Уенның зур тарихка ия. Футболга охшаган беренче уен якынча 5000 ел элек Борынгы Кытайда барлыкка килгән.

Футбол кырында һәр уенчының үз вазыйфасы бар. Шул вазыйфадан чыгып аларга атамалар бирелгән, алар рус теленнән татар теленә турыдан-туры тәрҗемә ителгән. Мисаллар:

*Капкачы* (рус телендә голкипер) капка янындагы мәй данда уйный. Аның вазифасы – көндәш команда уенчыларына гол кертер гә мөмкинлек бирмәү, капканы саклау. *“Андый чакта авырлыкның зур өлеше капкачылар җилкәсенә төшә. Юрий Дюпинга икенче очрашу рәттән каһарман булырга туры килде”* (Ватаным Татарстан).

Сакчы (защитник) – командадагы иң мөһим уенчыларның берсе. Ул, гадәттә, капкачы мәйданының алдында уйный. Аның вазифасы – көндәш команда уенчыларын капка янына китертмәү һәм гол кертергә комачаулау. *Беренчесе сакчылар арасында ышанычны арттырса, икенчесе һөҗүмгә үткенлек өстәде* (Ватаным Татарстан)

Һөҗүмче (нападающий) көндәш команда капкасы янында урнаша. Аның максаты – гол кертү. Ярымсакчының урыны сакчы белән һөҗүмче мәйданнары арасында. Аның максаты – сакчыларга һәм һөҗүмчеләргә ярдәм итү. “*Казан командасы нибары дүрт уенда җиңү яулап, 11 туп кертә алды. Чагыштыру өчен: “Зенит” һөҗүмчесе Артем Дзюба берүзе әнә шул кадәр уңышка ирешкән”* (Ватаным Татарстан).

Футбол уенына караган күп терминнар алынма вариантта кулланалар. Мәсәлән: офсайд, фаворит, премьер-лига, пенальти, матч һ.б.

*“Дөрес, Англия клубы да соңгы вакытта зур уңышлары белән мактана алмый, ләкин күпсанлы көчле футболчылары һәм Юрген Клопп кебек көчле остазы булган «Ливерпуль», «Рубин»га каршы уенда, һичшиксез, фаворит иде”* (Шәһри Казан).

*“Иң элек команданы премьер-лигада калдыру өчен тырышачакбыз. Аннары күз күрер. Киләсе ярты елда команданың нигезен барлыкка китерү бурычы да бар”* (Ватаным Татарстан).

*“Локомотив”ка каршы узган уенда ул кагыйдә бозганнан соң, “Рубин” капкасына пенальти билгеләделәр”* (Ватаным Татарстан).

*“Быел Россия җыелмасы Чемпионат кысаларында үткәрелгән дуслык матчларында бер тапкыр да җиңү яуламыйча Футбол буенча дөнья чемпионатының рекордын куйган”* (Шәһри Казан).

**Әдәбият**

1. Ватаным Татарстан. “Рубин”ның баш тренеры: “Мин Кыш бабай түгел” [Электрон ресурс]. URL: https://vatantat.ru/2019/12/rubinny%D2%A3-bash-trenery-min-kysh-babaj-t%D2%AFgel/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 10.01.2019).
2. Ватаным Татарстан. Казан командасы Мәскәүдән дүрт очко алып кайтты [Электрон ресурс]. URL: https://vatantat.ru/2019/07/bulsa-gruzin-%D2%97i%D2%A3%D3%99-rubin-kazan-komandasy-m%D3%99sk%D3%99%D2%AFd%D3%99n-d%D2%AFrt-ochko-alyp-kajtty/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 10.01.2019).
3. Шәһри Казан. Футбол турында җиде кызыклы факт [Электрон ресурс]. URL: http://shahrikazan.ru/news/kyiskacha-ya%D2%A3alyiklar/futbol-turynda-ide-kyzykly-fakt (мөрәҗәгать итү вакыты: 12.01.2019).
4. Шәһри Казан. Татарстандагы төп футбол клубы [Электрон ресурс]. URL: http://shahrikazan.ru/news/sport/ni-chen-rubin-evropadagyi-futbol-grandlaryinyi-bas (мөрәҗәгать итү вакыты: 12.01.2019).

## ИНТЕРТЕКСТУАЛЬНЫЕ ВКРАПЛЕНИЯ В ТВОРЧЕСТВЕ ТАТАРСКОГО ПОЭТА XX ВЕКА ИЛЬДАРА ЮЗЕЕВА

*Галеева А., БГПУ им. М. Акмуллы, студент II курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Р.Р. Гареева*

В настоящее время в литературоведении и стилистике большой интерес вызывает интертекстуальность. Как известно, явление интертекстуальности само по себе не ново, однако термин был предложен только в 1967 году теоретиком постструктурализма Ю. Кристевой: «Интертекстуальность – социальное целое, рассмотренное как текстуальное целое» [3: 98]. Иначе говоря, интертекстуальность понимается как общее свойство художественных текстов, благодаря которым тексты могут разнообразными способами явно или неявно ссылаться друг на друга [2: 131].

Несмотря на то, что исследования в области интертекстуальности являются одним из ведущих направлений в лингвистике, поэтике, литературоведении и других науках, отдельные положения интертекстуальности остаются мало изученными. До настоящего момента вопрос об интертекстуальности как важной характеристике стиля поэта оставался за рамками исследований, либо освещался недостаточно полно, что подтверждает актуальность данного исследования. Кроме того, творчество выдающегося татарского поэта XX века Ильдара Юзеева остается неизученным с точки зрения использования им интертекстуальных вкраплений. Тему интертекстуальности исследовали такие учёные-лингвисты, как Ю.М. Лотман, М.М. Бахтин, Н.А. Фатеева, Ю. Кристева, Х.Р. Курбатов, Н.Г. Юзеев и многие другие. Ильдар Юзеев – выдающийся татарский поэт XX века. Ю.Г. Нигматуллина так определяет преобладающие в художественных

произведениях Ильдара Юзеева литературное направление и стиль: «Условность образов и грандиозность их масштабов, отказ от бытовой конкретики, подчиненность интонационной структуры одной доминантной интонации – всё это приметы романтического стиля». Особенностью поэзии Ильдара Юзеева является экспрессивное использование им интертекстуальных вкраплений. Примеры интертекстуальных вкраплений такие, как аллюзия, цитата, реминисценция, мы часто встречаем в его творчестве.

Одним из ярких примеров использования поэтом интертекстуального вкрапления является стихотворение «Татар бавы» («Татарская веревка», 1987). Оно впервые было напечатано в журнале «Казан утлары». Читатель в данном произведении сталкивается с несколькими видами интертекстуальных вкраплений. Одним из них является цитата из стихотворения Семёна Липкина «Зимний закат» (1984):

А порой от намека слабого
Поднималась надменно бровка…
Далеко, далеко Елабуга
И татарская та верёвка...

В данном произведении Ильдар Юзеев использует не только цитату в форме эпиграфа, но и такой вид интертекстуального вкрапления как аллюзия. Аллюзия – это заимствование определенных элементов претекста, по которым происходит их узнавание в заимствующем тексте. Например, В.Набоков, по образованию энтомолог, играя на одинаковости названий бабочек и героев мифов и чередуя их латинское и кириллическое написание, вводит в свои произведения сочетания, части которых одновременно представляют собой и поэтические аллюзии. Одна из бабочек в романе «Дар» получает название Orpheus Godunov; первая часть названия соотносится с именем поэта-певца Орфея, вторая, воспроизводящая первую часть фамилии героя и одновременно фамилию русского царя, вынесенную в заглавие пушкинской трагедии «Борис Годунов», при латинском написании парадоксально высвечивает корень God (Бог), имя же героя романа – Федор в переводе с греческого означает «божий дар».

В нашем случае аллюзией является лексема «татар бавы» («татарская веревка»), которая прямиком отправляет нас к произведению Семёна Липкина «Зимний закат». Стихотворение Ильдара Юзеева «Татар бавы» («Татарская веревка») является своеобразным ответом на произведение Семёна Липкина «Зимний закат».

Притворились, что не заметили,
Как над нами кружится стужа.
Где присяжные? Где свидетели?
Где Париж? Где погибель мужа?

В стихотворении «Зимний закат» в центре мы видим образ Марины Цветаевой, которая трагически покончила собой в городе Елабуга и Семен Липкин делает акцент на татарской веревке. А в произведении «Татар бавы» («Татарская веревка») Ильдар Юзеев высказывает мысль о том, кто б не сплел эту веревку, у неё нет нации и в этой трагедии не виноват народ и не следует его осуждать:

Авыр бер чор, сугыш гарасаты
Маринаны монда китергән.
Хәзер кемне, кемне гаепләргә?
Сорыйк әнә Чулман, Иделдән.
Кем ишсә дә, бауның милләте юк,
Сылтамагыз аны милләткә!

Аллюзию мы также видим в другом стихотворении Ильдара Юзеева «Әйтелмәсен әле...» («Пусть не будет сказано…», 1989). Данное стихотворение посвящено татарскому писателю, публицисту Амирхану Еники. Прочитав заглавие, мы уже ссылаемся на произведение Амирхана Еники «Әйтелмәгән васыять» («Невысказанное завещание»).

Аннан юлны дәвам иттерегез
Гел **«Тауларга карап»** юл тотып,
**«Соңгы китап»**, **«Васыять»**ләр диеп,
Һаман шулай безне куркытып...

В этих строках поэт использует аллюзию, которая отсылает нас к следующим произведениям Амирхана Еники «Тауларга карап» («Смотря на горы»), «Соңгы китап» («Последняя книга»), «Әйтелмәгән васыять» («Невысказанное завещание»). Последнее произведение коррелируется с заглавием стихотворения Ильдара Юзеева.

Бөгелмисез әле, сыгылмыйсыз,
Җанда йөртсәгез дә чорны Сез.
Әйтелмәсен әле васыятьләр,
Әйтелмәсен әле соңгы сүз...

Эти строки поэт противопоставляет произведению Амирхана Еники «Әйтелмәгән васыять» («Невысказанное завещание»). «Васыять» («завещание») обозначает приближение какого-то конца. А в стихотворении автор преободряет читателя, надеется на продолжение жизни и говорит о вере несказанности завещаний и последних слов.

В стихотворении Ильдара Юзеева «Яралар» («Раны») читатель сосредотачивается на эпиграфе из произведения татарского поэта Хасана Туфана:

Кайсыгызның кулы җылы,
Бәйлисе бар йөрәкне?

Интертекстуальное вкрапление придает данному произведению элемент самовыражения автора. Здесь автор отвечает на вопрос лириче-

ского героя Хасана Туфана и задает ему встречный вопрос. В итоге получается так называемый историко-культурный диалог.

Таким образом, мы рассмотрели несколько типов интертекстуальных вкраплений, примеры взаимодействия текстов, их взаимопроникновения, а также бесконечное рождение одного текста через другой в творчестве Ильдара Юзеева.

**Литература**


1. Гареева Р.Р. Художественный текст: теория и практика анализа: учебно-методическое пособие по курсу «Филологический анализ художественного текста». – Уфа: Изд-во БГПУ, 2016. – 139 с.
2. Еременко Е.Г. Интертекстуальность, интертекст и основные интертекстуальные формы в литературе // Уральский филологический вестник. Сер. Русская классика: динамика художественных систем. – Екатеринбург, 2012. – №6. – С. 130–140.
3. Кристева Ю. Бахтин, слово, диалог и роман // Вестн. Моск. ун-та. Сер. Филология. – Москва, 1995. – №1. – С. 97–124.
4. Курбатов Х.Р. Татарская лингвистическая стилистика и поэтика. – М.: Наука, 1978. – 218 с.
5. Юзеев И.Г. Мәңге ян, күңел!: шигырьләр, җырлар, балладалар, поэма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 479 б.


## Һ. ТАКТАШ ИҖАТЫНДА ТЕЛ-СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ


*Галиәхмәтова Д., Саба р-ны Шәмәрдән лицее, XI сыйныф*

*Җит. – Д.И. Галимҗанова*


Һ. Такташ – хәзерге татар әдәби теленең үсешенә җитди өлеш керткән, татар поэтикасын яңа сурәтләү чаралары белән баеткан шагыйрь. Аның шигырьләре җиңел укыла һәм бик тиз истә кала. Тикшеренүчеләренең хезмәтләреннән күренгәнчә, ул һәр шигырен, һәр поэмасын өчәр-дүртәр кабат язган, кайбер юлларын, аерым сүзләрен күп тапкырлар үзгәрткән. Ул үзе дә бер мәкаләсендә: «Язучы үзенең һәр җөмләсе, һәр сүзе өчен җаваплы». «Алар, – ди ул, – әсәрнең идеясен мөмкин кадәр көчәйтеп, тирәнәйтеп бирүгә карата сайлансыннар». Икенче бер урында ул: «Шагыйрьнең кыйммәте бөек идеяләрне... гади рәвештә өч-дүрт җөмләдә әйтеп бирә алуда», «тормышка бәйләнмәгән абстракт образлар шигырьне матурламый да, тирән мәгънәле дә итми», әсәрдәге бер генә образ да «безработный» булмаска, ә «конкрет бер вакыйганы җанландыруга хезмәт итәргә тиеш», кебек фикерләр әйтә [3: 132]. Һ. Такташның теле бай, күпкырлы һәм образлы. Образлылыкның тирәнлегенә омтылу шагыйрьне сурәтләү чараларын, мул кулланырга мәҗбүр иткән.

Монда шуны әйтәсе килә: әдәбият теориясенә нинди тел күренешләре, сурәтләү чаралары билгеле булса, Такташ иҗатыннан шуларның һәркайсына да диярлек мисаллар табарга мөмкин.

Аның теле – үзе бер дәрья, үзе бер диңгез. Такташ татар милли әдәби теленең формалашуында һәм аның үсүендә гаять зур роль уйнаган. Ул әдәби телебезне яңа троплар, стилистик фигуралар белән баеткан.

Шагыйрь, күзгә ташланып тормаган гади әйберләргә, табигать күренешләренә, кош-кортларга, хайваннарга игътибар итә һәм аларны үзенең әсәрләре тукымасына оста кертеп җибәрә. Ә алар исә «конкрет бер вакыйгаларны җанландыру» өчен хезмәт итәләр. Шагыйрь шулай ук әйләнә-тирәне, табигатьне дә кешеләрнең эчке дөньясы белән гаҗәп оста бәйләп бирә.

Әйтик, тулган ай, нурлы йолдыз, якты кояш, алсу таң, айлы төн, кызыл гөл, ак чәчәк – болар бит Көнчыгыш классик әдәбиятында да, Көнбатыш Европа әдәбиятында да киң таралган образлар. Әмма Такташ аларны үзенчә, үз эпитетлары белән файдалана: нурлы таң [1: 5], сандугачлы таң [1: 159], язгы зәңгәр күкнең йолдызлары [1: 159], нурлы ай [1: 21], яфраклы төн [1: 124], караңгы төн [2: 50], нәфис гөл[2: 25], кара гөл [1: 69], сирень гөле [2: 22], кызыл гөл [2: 9], назлы гөл [2: 21], нурлы йөз [2: 23], нурлы йолдыз [1: 3].

Шуның өстенә Такташның үзенә генә хас деталь яки образлар да байтак. Мәсәлән: Җил [2: 10], урман [2: 9], [2: 19], [2: 24], ат [2: 3], каз [2: 32], [1: 146,148], буран [1: 110], күк [1: 92, 117] һәм ак [2: 11], [2: 25] зәңгәр [2: 23], [2: 49] төсләр.

Такташ иҗатында риторик сорау җөмләләр, ендәшләр мул кулланыла. Аларның күбесе – җавап таләп итми торган сорау җөмләләр. Шуларның бер төре эмоциональ мөнәсәбәтләрне (риторик сорау) белдерә, ә икенче төре исә лирик кичереш, уйлануларның махсус формасын тәшкил итә:

– Нигә... Нигә синең шаян күзләр
Ник елыйсыз сез, урамнар,
Күзләремә болай багалар?
Ник елыйсыз? Туктагыз! ...[1: 105]
Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыңнан агалар?![2: 18]

Такташта үзенчәлекле метафорик троплар, фигуралар әһәмиятле урынны алып тора. Шундыйлардан түбәндәгеләрне аерып күрсәтергә була:

1) эмоциональ-экспрессив сүзләр:
а) Мин карадым, ә ул йөзкәйләрен
б) Тик ул чакта, тик ул чакта безне аерган
Ябынчасы белән каплады.[2: 23]
Бу кануннар булмас, йолдызым.[2: 28]
в)Фәрештәкәй, кач бу илдән![1: 4]
д)Төнге салкын зәмһәрирдән
г)Кабилем, аһ! Йолдызым![1: 36]
Туңды күңлем, алтыным![1: 24]

2) чагыштырулар: алма кебек матур Зөбәйдә [2: 52], ай кебек син читтә ялгыз калма [1: 152], солтангалиевтәй этләр [1: 201], балалардай уйнап йөрербез [2: 22], күсе койрыгыдай мыеклар [1:128], күбәләктәй гөлдән-гөлгә күчеп йөри [2: 16], су кызыдай кил дә хәзер минем алдыма [2: 16], төштә

күргән пәри сараедай [2: 25], синең атың кебек җирән атта [2: 31], кара болыт кебек тузган чәчләр [2: 48], җыр кебек яшьлек таңым [2: 50], Алсу бала кебек елмая да [2: 59], усал түгел кебек шикелле [2: 60], җәһәннәмдәй утлар уйный уңда-сулда [1: 3], нәфис гөлдәй, елмайды нурлы йөзләре [1: 89], кояш нуры кебек нурлар сибеп [1: 106], эшле кешедәй тикшереп йөри [1: 139], Хәмитовтай кешеләр [1: 175],очкын коштай синең туры атың [1: 177], ак каенга асылып менгән кебек [1: 192], зурлар кебек кулны артка куеп [1: 192], чабатаңдай матур үрмәдең [1: 193], май аедай матур башланды [1: 193], бит тиресе таудай булып өелеп тормасай [1: 199], әкияттәге ике бала кебек[1: 191].

3) метафора, метонимия, синекдохалар: күңел язы шаулап үтте аның тәңкә яуган буранда [2: 50], канлы яшь [2: 52], сөялләнеп беткән кул [1: 138], мәхәббәт ул – нәфис матур чәчәк [2: 49], бөтен дөнья йоклый, тәмле йокы [2: 51], җир уянган, урам дулкынланган [1: 108], тормыш симфониясе башланган [1: 108], зал тын гына аңа карап торды [1: 226], зал аңардан күзен алмады [1: 226], йомшак җилләр [2: 18], ак чәчәкләр ява урамда [2: 35], зал көтә, зал елый, үкси иде [1: 100], туңды зал, зал таралды [1: 101], зал эчендә ул да бар [1: 111], зал алкышка күмелеп дулкынлана, зал аякка баса, кузгала [1: 211], зал тын, зал тыңлады, зал өстенә күзен төбәде [1: 225].

4) фразеологик әйтелмәләр: күкрәктә канлы ут сүнү [1: 140], тал чыбыгын ашау [1: 192], эшкә таяк тыгу [1: 201], дарга басып антлар итү [1: 10], дарга басып күккә ашарга [1: 9], уйга талды [1: 55], борын салындыру[1: 174], ачык авыз[1: 194].

5) сынландырулар: *чәчәкләр сискәнеп уяналар, керфекләрен ачып карыйлар* [2: 39], җил йоклады [2: 52], ай көлә [2: 52], җил күрде дә [2: 53], кояш күктә көлә-көлә йөзәр [1: 92], төнге аксу карлар, маңгаеңа кунып үбәләр [1: 181], йоклап яткан назлы гөлләремне уяттым [1: 87].

Югарыда карап үткән тел-сурәтләү чаралары гына да Такташның телебез мөмкинлекләреннән, аның лексик-грамматик, стилистик төрлелекләреннән оста файдаланган, татар поэтикасында үзе бер яңа мәктәп ачкан шагыйрь булуын күрсәтә.

**Әдәбият**


1. Такташ Һ. Сайланма әсәрләр. Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Тат. кит. нәшр.,1963 .– 238 б.

2. Такташ Һ. Мәхәббәт тәүбәсе: Шигырьләр, поэмалар. – Казан: Тат. кит. нәшр.,1993. – 62 б.

3. Хәйруллин Х.Ф. Һади Такташ (Атаклы кешеләр тормышы). – Казан: Тат. кит. нәшр.,1984. – 176 б.


## РАВИЛЬ БУХАРАЕВ – ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬНАЯ ГОРДОСТЬ НАЦИИ!


*Галиева К., Казань, школа № 181, X класс*

*Рук. – А.Ф. Валиуллина*


Моя бабушка всю жизнь собирала книги**.** Это пришло ей от матери, ведь в её семье считалось, что книги – друзья, бесстрастные, но верные.

Один из её самых любимых авторов – Равиль Бухараев. Я познакомилась с ним при чтении стихов Габдуллы Тукая в переводе на русский язык. Безусловно, есть множество вариаций переводов творчества Габдуллы Тукая на многочисленные языки, но переводы за авторством Равиля Бухараева – мои самые любимые. Равиль Раисович Бухараев - поэт, прозаик, драматург, журналист и переводчик. Уже в школе Равиль начал писать стихи, а после поступления на механико-математический факультет Казанского университета, стал заниматься и переводами с татарского языка, а также историческими исследованиями. Для нас, Равил Бухараев – выдающаяся многогранная личность: поэт, уникальный переводчик, ученый-историк, философ и просветитель. Литературным кругам Москвы он был известен изначально своими стихами, которые были написаны на русском языке. Хотя у него были стихотворные произведения на венгерском языке (венок сонетов), на английском, и конечно, на родном татарском. Переводчиков, которые могут переводить крупные произведения с чужого языка на свой, родной, немало, но другое дело – с родного языка на чужой, такие – наперечет...

«Скажем, в советскую эпоху, благодаря переводам с английского Самуила Яковлевича Маршака, мы познакомились в молодые годы с Шекспиром, Бернсом. Но я не знаю, не слышал, чтобы Маршак переводил свои стихи или чьи-либо другие с русского языка на английский. А Равилю Бухараеву это удавалось, и в этом его отличительная черта», *– писал член-корреспондент Международной экономической академии Евразии, карьерный дипломат, публицист Юлдуз Нуриевич Халиуллин.*

В 1986-87 гг. Бухараев по командировке СП СССР учился венгерскому языку в Будапеште, результатом чего стало то, что он не только стал переводчиком венгерской литературы, но и поэтом на этом языке. За сочиненный на венгерском языке венок сонетов – первый в истории венгерской литературы! – его приняли в Венгерский ПЕН-Клуб и Союз писателей Венгрии в 1989 г.

С 1990 года – жил и работал в Лондоне. В 1992 г., во время пребывания в Англии, был приглашён на Русскую службу Би-би-си в Лондоне, где работал до мая 2009 г. как штатный сотрудник и журналист. Переводческая деятельность Бухараева отличается еще и тем, что он свое знание английского языка великолепно использовал для перевода фундаментальных трактатов исламской культуры. Он перевел и издал свыше десятка книг – переводов на русский язык фундаментальных исламских трактатов, прежде всего, ахмадийского движения в исламе. Не зря же самым лучшим изданием Корана нашего времени является тот, который осуществила «команда» во главе с Р. Бухараевым. В этом фундаментальном труде проявилась вся его сущность – и переводческая, и поэтическая, и литературная.

Когда об этом спросили Р. Бухараева, как он добивался максимальной четкости, ясности в изложении сур Корана, он ответил, что, с одной стороны, придерживался русского перевода Саблукова, а с другой, – последнего издания Корана на английском языке.

Велики его заслуги перед татарским народом. Без всякого преувеличения можно сказать, что при содействии Правительства Татарстана Равиль Бухараев вывел на международную арену многие шедевры татарской литературы. Прежде всего, он перевел и издал на английском языке Антологию татарской поэзии. Затем он пошел назад – перевел и опубликовал на английском поэзию Золотой Орды. И, наконец, он опубликовал в одном из самых престижных лондонских изданий «Глобал Ориентал» свой перевод поэмы «Кыйссаи Йосыф» (Сказание о Юсуфе). Поэмы выдающегося булгарского поэта-гуманиста Кул Гали, являющейся родоначальницей татарской письменной литературы. 800-летие со дня рождения поэта и 750-летие его бессмертного произведения по решению ЮНЕСКО были отмечены в 1983 году. Таким образом, впервые шедевр общетюркской поэзии раннего средневековья стал доступным для англоязычного читателя. Произведения Бухараева настолько значительны по смыслу и формам, что можно сказать с полным основанием и с энтузиазмом: Равиль Бухараев – интеллектуальная гордость нации! Жизнь поэта была полна парадоксов и, быть может, ещё неразгаданных тайн. Только освоив новый для себя венгерский язык, он пишет самую сложную «высшую математику поэзии» – венок сонетов. Так он входит – практически как прижизненный классик! – сразу в литературы на русском, татарском, венгерском и английском языках. Владеет также урду и арабским, что даёт «прямой выход» на многие источники исламских знаний, как классических, так и небесспорных, апокрифических.

Равиль Бухараев был добровольным послом русской и татарской культуры за рубежом. Он воплощал в себе единство этих двух культур, единство русского и татарского языков, будучи творцом мирового масштаба. Об этом свидетельствует написанные им книги – их более 40, многочисленные статьи, интервью, сценарии. Об этом свидетельствует вся его многообразная работа – поэтическая и писательская, продюсерская на русской службе BBC, организаторская в представлении лучших творцов и лучших произведений татарской культуры в Великобритании. Об этом свидетельствуют его высокие награды, среди которых орден Организации Объединенных Наций «Единение. Деяние во благо народов» (2005), государственная премия Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая за поэтическое творчество (2006), орден «Культурное наследие», Международной федерации русскоязычных писателей (2011).

**Литература**

1. Казанский альманах Бирюза. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2017. – С. 136, 145-149.

# НАЦИОНАЛЬНАЯ И КУЛЬТУРНАЯ ИДЕНТИЧНОСТЬ В РАМКАХ МЕЖКУЛЬТУРНОГО ВЗАИМОДЕЙСТВИЯ

*Галимбикова И., КФУ, студент I курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Ф.Р. Сибгаева*

На сегодняшний день очень сложно найти культуры, которые не испытывали бы на себе воздействия со стороны культур других народов. Хотя при этом глобальные изменения в политике, экономике и культуре сопровождаются также разобщением культур и народов, вызывают у некоторых наций стремление к культурному самоутверждению и желание сохранить собственные культурные ценности. Э.А. Усовская, изучавшая ключевые условия и факторы формирования американской культуры и нации, отмечает противоречивый характер межэтнических отношений и подчеркивает, что именно стратегия мультикультурализма, сменив доктрину «плавильного котла», является причиной обострения проблемы национальной идентичности [3: 131].

В современной науке часто используется слово «идентичность». Под идентичностью понимается осознание человеком своей принадлежности к какой-либо социальной группе, позволяющее ему определить свое место в социокультурном пространстве и свободно ориентироваться в окружающем мире. Поскольку каждый индивид может являться одновременно членом нескольких социальных и культурных общностей, в зависимости от типа групповой принадлежности принято выделять различные виды идентичности: гражданскую, национальную, этническую, культурную, профессиональную, политическую, религиозную. В культурологии и межкультурной коммуникации идентичность является основанием для национального и культурного тождества, индикатором своего и противоположностью чужому. Следовательно, межкультурную коммуникацию можно рассматривать как взаимоотношение противостоящих идентичностей, при котором происходит взаимодействие партнеров по коммуникации.

А.П. Садохин определяет культурную идентичность как «принадлежность индивида к какой-либо культуре или культурной группе, формирующей ценностное отношение человека к самому себе, другим людям, обществу и миру в целом» [2: 57]. Следует рассматривать идентичность как один из важнейших инструментов, который оказывает влияние на сам процесс коммуникации, тем более что самоопределение в культуре невозможно без знания других культур. Так, можно сделать вывод о том, что, сущность культурной идентичности заключается в осознанном принятии индивидом соответствующих культурных норм и образцов поведения, ценностных ориентаций и языка, понимании своего «Я» с позиции тех культурных характеристик, которые приняты в данном обществе. По мнению Ж.А. Верховской, в процессе межкультурной коммуникации каждый

человек одновременно решает две важнейшие проблемы – стремится сохранить свою культурную идентичность и включается в чужую культуру. Круг проблемных вопросов, связанных с культурной идентичностью в межкультурной коммуникации, основывается на разделении всех представителей культур на «своих» и «чужих». Обычно «своей» называют ту культуру, с которой человек связан своим происхождением, местом проживания, воспитанием, языком, на котором он говорит и мыслит, традициями, сохраняющимися в его памяти.

Вместе с понятием «культурная идентичность» следует также рассматривать определение «Национальной идентичности». Есть несколько подходов к пониманию идентичности. А.И. Куропятник заявляет, что нет единого набора признаков для определения и формирования национальной идентичности [1: 143].

Сторонники определения национальной идентичности через этнокультурные основания считают, что идентичность нации зависит, прежде всего, от ее исторических корней и символических форм, воспроизводящихся через религию, язык, национальную архитектуру. Существует точка зрения, согласно которой национальная идентичность базируется на политической (гражданской и территориальной) основе.

В современном мире увеличивается количество людей, которые покидают границы своего культурного мира; для обозначения взаимодействия и взаимовлияния культур в культурологии используется термин «аккультурация». Аккультурация – процесс и результат взаимного влияния различных культур, при котором все или часть представителей одной культуры перенимают нормы, ценности и традиции другой, при этом происходит смешение культур и достигается состояние культурной и этнической однородности.

На стадии минимизации коммуниканты признают поверхностные культурные различия: традиции, обычаи, но предполагают, что по своей сути люди имеют свои достоинства и недостатки. На стадии принятия культурных различий люди принимают и исследуют культурные различия, осознают, что являются представителями той или иной культуры.

В современном мире можно наблюдать стремление к унификации культур, к построению мультикультурного общества. Но данное явление нередко приводит к силовому противостоянию наций и острой потребности этносов сохранить собственную национальную идентичность. Поэтому нет определенной оценки данному процессу, противники и сторонники мультикультурализма по сей день продолжают вести дискуссии на эту тему.

**Литература**

1. Куропятник А.И. Мультикультурализм. Нация. Идентичность // Глобализация и культура: аналитический подход. – СП б., 2003. – С. 126-150.

2. Садохин А.П. Культурология: теория и история культуры: Учебное пособие. – М.: Эксмо, 2007. – 624 с.

3. Усовская Э.А. Этносоциальные и конфессиональные процессы в современном обществе: сб. науч. статей. – Гродно: ГрГУ, 2012. – 426 с.

# ЛИЛИЯ ГЫЙБАДУЛЛИНА ИҖАТЫНДА ОБРАЗЛАР БИРЕЛЕШЕ

*Галимова Д., Казан, 23 нче лицей, X сыйныф*

*Җит. – А.Х. Шәехова*

XX-XXI гасыр чикләрендә татар поэзиясе эчтәлек һәм форма, фәлсәфи яктан тирәнәя, төрләнәә. Чынбарлыкны, рухи дөньяны үзләренчә күрү сәләтенә ия, бай фикерле, гүзәллекне тоя, сәяси хәрәкәтләрне аңлый торган сәләтле сүз осталары, яшь язучылар, ташкын кебек, килеп кереп тора. Алар арасында “Такташның яшьлек чоры иҗатын хәтерләткән” [2: 432] бик тә үзенчәлекле яшь шагыйрә – Лилия Гыйбадуллина. Яшь шагыйрәнең иҗат җимешләре Татарстанның “Казан утлары”, “Идел”, “Мәйдан”, “Мәдәни җомга”, “Шәһри Казан”; Башкортстанның “Тулпар”, “Шоңкар”, “Йәшлек” [4: 5] кебек газета-журналларында даими басылып килә.

Лилия Гыйбадуллинаның иҗаты тәнкыйттән читтә йөри. Бу як фәнни эшебезнең актуальлеген тәшкил итә. Фәнни эшебезнең максаты: Лилия Гыйбадуллина иҗатын образлылык биреше ягыннан тикшерү. Максатка ирешер өчен түбәндәге бурычлар куелды: Л. Гыйбадуллина иҗаты белән танышу, аның турында тәнкыйди материал туплау, образлылык биреше ягыннан тикшерү.

Шигырьләрнең үзләренә килсәк, сафлык, ихласлык, матурлык, мәхәббәт белән сугарылган табигать образлары күзгә ташлана. “Җил” [3: 34] шигырен алыйк. Бу шигырьдә – җил образы. Шушы образны тасвирлаганда, автор җанландыру алымын еш куллана. Мәсәлән, җил “сөйли”, “табигатьнең җырын көйли”, “сөйләштерә”, “серләштерә”, “уйнап йөри”, “уйлап йөри”, “урлап китә”, “куа”, “ишеткән”. Минемчә, автор җил образы аша гомернең фанилеген, вакытның агышын тасвирлаган. Шигырьнең кайбер юлларына игътибар итик. “Биек агач яфракларын сөйләштерә, / Изрәп яткан үләннәрне серләштерә” – бу юлларда гомернең яз-җәй мизгелләре, “Берәүләрнең бүрекләрен урлап китә, / Салкын кышта карлар өеп кызык итә” юлларында – гомернең кыш мизгеле, “Күзләр моңсу, ә ул шаян яфрак куа, / Тынын өрсә, җырлый кырда кура” юлларында тормышның көзләре ачык сизелә. Шигырьнең соңгы юлында автор гомуми нәтиҗә чыгара: “Еллар җилләр җитезлеге белән узып тора.” Адәм үз тормышында нәрсә генә күрсә дә, дөнья барыбер “җилләр җитезлеге белән” алга бара. Кыскача әйткәндә, җил – гомернең, вакытның тиз үтүе. Әсәрдә шагыйрә кулланган метафораларга *табигать җыры, җилләр җитезлеге,* эпитетларга *чал чәчле җил, шаян яфрак, моңсу күзләр*не кертеп була.

“Яңгыр” [3: 42] шигыренә Лилия Гыйбадуллина яңгыр образын алган. Яңгыр ул – яшәү чыганагы. Ул “табигать яшәртә”. Яңгыр булса, урманнар яшәрә, елгалар ташый, җир-ана терелә. Яңгыр образын

тасвирлаганда, автор аны яшенле, ярсулы дип яза, аңа “зәңгәр күк хуҗасы” (монда шагыйрә метафора тропын кулланган) дип эндәшә. Шулай ук яңгырны “асылташ” белән тиңли. Минемчә, шагыйрә бу әсәрендә яңгыр образы белән кеше күңелен параллель рәвештә тасвирлый. Болытлар, яңгырлар булмаганда, зәңгәр күк кояш белән балкый. Шулай ук кеше күңеле дә: адәм кайгы-хәсрәтләр күрмәсә, аның җаны тыныч, кәефе бөтен була. Яшенле яңгыр, ярсулы яңгыр сүзтезмәләре күңелнең моң-зар, кайгы белән тулуын аңлата. Яңгырның “күңеле тулганда”, ул “чиләкләп коя”. Кеше күңеле тулгач, ул елый. “Елачы бер, әйдә”, “Еласаң, бушанып калырсың” дип лирик герой үзенең күңеленә эндәшә. Чыннан да, елап алсаң, күңелдә ниндидер бер җиңеллек сизәсең. Яңгыр явып үткәч, күктә кояш балкый, салават күпере чыга. Шулай ук кеше үзенең күңелендәге кайгы-борчуларын чыгаргач, аның кәефе күтәрелә, эчендәге авыр хисләр җиңеләя, начар уйлар югала.

Лилия Гыйбадуллина иҗатындагы татлы җимешләрнең берсе – “Имән” [4: 23] шигыре. Бу әдәби әсәрдә имән образы сурәтләнә. Имән “кара көйгән”, “карт”, аның ботаклары “көчсез”, ләкин ул “сабыр”, аның тамыры “нык”. Минем уйлавымча, имән образы бу шигырьдә карт кешене күз алдына китерә. “Ут-дәһшәтне күреп кара көйгән” имән – кайгы-хәсрәт, тормышның әче-төчесен күп күргән кеше. Имән “ялгыз башын таш кыяга игән”, аның “көчсез ботаклары җиргә тигән”. Шулай ук кешенең дә хәле юк, ул көчсез, авырлыклар күреп хәлсезләнгән ул. Ләкин имәндә дә, кеше күңелендә дә өмет сүнмәгән. Имәннең тамыры нык, ә кеше күңеленең пакълеге, сафлыгы, чисталыгы бар, аның ышанычлары, өметләре зур. Шулай булгач, “сабыр имән күтәрелер, яфрак ярыр”, кешенең дә өметләре чынга ашар, киләчәге яхшы булыр, “изге айдан иман табар”.

“Йолдызлар” [4: 13] шигырендә дөньяның, яшәешнең матурлыгын күрә белмәгән, күңеле начар уйлар белән тулган кешеләр сурәтләнә. Автор аларны “таш бәгырь”, “күңелдә ачылмас keләләр” дип яза. Чыннан да, искиткеч тылсымлы йолдызларны “кирәкмәс чүп” дигән кеше кеше түгел. Шагыйрә әсәрнең соңгы юлларында өмет белдерә: “һәр таш җанның да үз күге, үз күзе, йолдызы бар...”. Кеше бу дөньяда яши икән, димәк аның хыяллары, уй-ниятләре бар. Кешегә Ходай тарафыннан күз бирелгән. Шушы күзләр аша кеше матурлыкны күрә, таный, аңлый белергә тиеш. Адәмнең өмете булырга тиеш. Чөнки шушы өметләр, йолдызлар булып, безгә яшәр өчен көч бирәләр, алга атлар өчен максатлар куеп, юлыбызны яктыртып торалар.

Шагыйрәнең “Юкка” [3: 18] дигән дүртьюллык шигырендә образ буларак лирик геройның өметләре күренә. Бу өметләр аклык, сафлык, чисталык, пакълек белән тулы. Шагыйрә аларны ак гөрләвек белән чагыштыра, ак хыяллар, хыяллар океаны, ак дулкыннар кебек образлы сурәтләр белән бизи. Өметләр ак хыяллар океанын ак дулкыннар белән

тышларга агып китәләр. Тик өметләрне автор чынга ашмаслык дигән фикер белән тәмамлый.

Лилия Гыйбадуллина күңелендә, шигырьләреннән күргәнебезчә, югары дәрәҗәдә романтик, эчкерсез һәм ихлас шигырьләр яралган. Лилия – җир кызы, ләкин аның уйлары, хыяллары биектә. Лилия ханым – табигать кызы. Аның кайсы гына шигырен алма, анда – күк, болытлар, йолдызлар, кояш, ай, җил... Бүгенге катлаулы, усал, шәфкать белмәгән аяусыз дөньябызда гөнаһсыз, рухи, әхлакый тормышның чишмә башын – сафлыкны, ихласлыкны, матурлык һәм мәхәббәтне саклап яшәргә чакыра Лилия Гыйбадуллина.

**Әдәбият**


1. Галиуллин Т. Татар шигърияте: 1980-2000 еллар. – Казан: Мәгариф, 2003.
2. Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – 654 б.
3. Гыйбадуллина Лилия. Мин бәхетне күрәм!..: Шигырьләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – 47 б.
4. Гыйбадуллина Л.Ф. Тынлык кайтавазы: шигырьләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2010. – 39 б.


## XIX ГАСЫР ТАТАР ҺӘМ ЧУВАШ ӘДӘБИ ТЕЛЛӘРЕНДӘ ФОНЕТИК ВАРИАНТЛАР


*Гарипова Д., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. М.Р. Саттарова*


Рус-европа сүзләре элек-электән рус һәм башка халыклар белән аралашып яшәүче төрки халыкларның телләренә җанлы сөйләм аша үтеп кергәннәр. Алар тора-бара әдәби телебездә үз урыннарын алганнар, телгә яраклашканнар. Әлеге мәкаләдә без 19 гасыр татар һәм чуваш әдәби телләрендә рус алынмалары үтеп керү нәтиҗәсендә туган фонетик вариантларны караячакбыз. Аларның барлыкка килү сәбәпләрен, телгә яраклашу үзенчәлекләрен ачыклаячакбыз.

Рус-европа алынмалары татар теленең XIX-XX гасырларга караган гади сөйләмендә зур үзгәрешләр кичергәннәр:

а) рус теленең авазлары (о, е, ы, ц, в) татар теленең авазлары белән чиратлашкан, татар теле вәкилләре өчен җайсыз тартыклар уңайлы тартыклар белән алышынган;

ә) татар теленә хас аккомодациягә (калын сузыкның тартыкка йогынтысы) буйсыну күзәтелә: *беглый – бигылый, Покров (день) – Пыкрау (көн)*;

б) сингармонизмга буйсыну: *танцевать – тансавайт, совсем – чәпчим;*

г) палаталь тартыкның гадәти тартык белән чиратлашуы таралыш алган: *писарь – писыр, хоть – хыт, начальство – нәчәлстыво, волость – вулыс;*

д) сүз башындагы ике тартык алдына яки арасында кайчак сузык өстәлгән: *здесь – эздич, ведро – бидерә;*

е) иҗек кыскару-үзгәрүләр күзәтелә: *образованный – абразауный, жалованье – жалуния*;

Әдәби телгә үтеп кергән рус-европа алынмаларының гади сөйләмдә кичергән төп фонетик үзгәрешләре:

1) сүз азагындагы яңгырау тартыкның саңгыраулашуы: *кораб – карап, юбка – йүпке, трубка – трүпке;*

2) ц – с: *станция – станса*;

3) з – җ: *газета – гәҗит* (әдәби телдә газета // газет);

4) с – ч: *Россия – Рәчәй* (әдәби телдә Россия // Русия);

5) сүз азагында яки уртасында а кыскару: *фабрика – фабрик, тарантас – трантас;*

6) сүз азагындагы мөәннәс яки урта род шәкеленең иҗеге кыскару-үзгәрү: *крепостное право – крипаснуй права*;

7) р алдыннан сүз башындага сузык өстәлү: *ресторан – ыристаран.*

8) ф – п: *Федосья – Пидук; ф – к: фуфайка – куфәйке* һ.б.

Чуваш әдәби теле тарихын өйрәнүче күренекле галим Н.П. Петров билгеләвенчә, түбән диалект нигезендәге яңа әлифба кертелгәннән соң 1872–1917 еллар аралыгында 725 китап бастырыла, шуларның 439 дини характерда була. Китапларның 250дән артыгы Чуваш дәүләт архивында, калганнары Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә һәм шәхси коллекцияләрдә саклана. Күп тәрҗемә хезмәтләр берничә тапкыр нәшер ителәләр. Мәсәлән: «Священная история Ветхаго и Новаго Завета» 12 тапкыр, «Молитвенник» – 8, «О загробной жизни», «Пасхальные службы», «Главные церковные праздники Господни и Богородичны» – 4әр тапкыр яңадан бастырыла. Күпләре аларның даими төзәтелгән һәм үзгәртелеп барган. Шуңа күрә әлеге дини текстлар берничә вариантта сакланганнар. Чуваш телендәге алынмалар белән бәйле фонетик вариантларны да без әлеге 19 гасыр дини тәрҗемә текстларыннан карадык. Бу текстларда алынмалар нигездә үзгәрешсез кулланылган, ягъни рус орфографиясе кагыйдәләренә нигезләнеп язылган һәм төрләндерелгән. Әмма шулай да алынма сүзләрнең берникадәр өлеше чуваш теленә яраклаштырылган. Шунысы да мөһим, тәрҗемәчеләр билгеле бер принциплар һәм кагыйдәләргә нигезләнмәгәннәр. Шул рәвешле бер сүзнең берничә фонетик вариантлары барлыкка килгән. Әлеге вариантларда рус орфографиясе принциплары телнең диахрон үсешендә чагыла. Мәсәлән: пашне (1873 –1882 еллар) – башня (1888 ел и позже), тиаккгн (1873 ел) – диакон (1891, 1894,1896, 1910 еллар һәм бүгенге көн), сапповет (1873 ел) – заповедь (1876-1906 еллар), свитеттĕл (1873 ел) – звититтĕл (1876 ел) – свидетель (1905 ел һәм соңрак), кĕнез (1882 ел) –княз (1888 ел) – княз (1899 ел), празник (1873 -1885 еллар) – праздник (1885 ел һәм соңрак) һ.б. . Кире процессны дәлилләүче мисаллар юк дәрәҗәсендә. Бер сүз теркәлгән: бархат (1891 ел) – пархат (1897 ел).

Татар телендә исә кире процессны дәлилләүче сүзләр күбрәк. Әлеге татар телендә гади сөйләмдәгечә әйтелеше нормалашкан рус-европа алынмалары телебездә бүген дә актив кулланылышта. Мәсәлән: *гармонь – гармун, кровать – караваm; кисель – кесәл, печь – мич* һ.б. Әлеге рус-европа алынмалары татар теленең гади сөйләмендә үзгәрешләр кичереп, хәзерге татар теленең орфографик системасына үтеп кергәннәр.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар һәм чуваш телләренең гади һәм әдәби сөйләм үзенчәлекләренә һәр ике телдә дә зур урын алып торган рус-европа алынмалары йогынты ясый.

**Әдәбият**

1. Абдуллина Р.С. Алфавитка бәйле орфография һәм орфоэпия мәсьәләләре: Монография. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 215 б.

2. Курбатов Х.Р. Орфоэпия. Орфография // Татар грамматикасы. 1 т. – М.: Инсан; Казан: Фикер, 1998. – Б. 104–112, 134–152

3. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 2002. – 280 б.

4. Лингвистический энциклопедический словарь. – М.: Сов. энц., 1990. – 685 с.

5. Чувашская книга до 1917 года: ретросп. библиограф. указ. лит. / Государственный архив печати Чувашской Республики. 2-е испр., доп. изд. – Чебоксары, 2001. – 201 с.

## ЯЗЫК ЖЕСТОВ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ РИНАТА МУХАММАДИЕВА

*Гафарова А., БГПУ им. М. Акмуллы, студент IV курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Р.Р. Гареева*

Литература любого народа вбирает в себя те особенности исторического периода, в котором она формируется. Переход в новый исторический период времени обуславливает переломные моменты в литературе. Так, например, можно условно определить границы существования Советской литературы в России, в частности, татарской, с середины 1920 гг. до конца 1980 гг. То есть на протяжении более чем 70 лет писатели творили и создавали в рамках строгой тоталитарной системы. Естественно, что произведения тех лет в основном были пронизаны высоким пафосом и служили средством укрепления социалистической идеологии. Но время не стоит на месте. С середины 80-х годов XX века в связи с некоторой свободой слов начинают появляться произведения другого направления – реализма. Мы видим и ощущаем героя нового времени – времени распада СССР. Эти персонажи еще живут прошлым, но чувствуют, что перемены стремительным ураганом врываются в их жизнь. Устоять на ногах порой бывает сложно.

Цепи рассказов и повестей Рината Мухаммадиева «Запутанный узел» (1988) и «Первый подснежник» (1985) рисуют нам именно таких героев. Данная работа не ставит своей целью характеристику отдельных образов, тем или идей. Задача немного иная: мы постараемся раскрыть глубинные психологические состояния женщин и мужчин через изучение особенностей мимики, жестов, телодвижений, которые являются частью

понятия гендер. Тщательный анализ повестей и рассказов писателя показал, что можно довольно точно разграничить и сгруппировать жесты, принадлежащие женщинам и мужчинам.

Рассмотрим женское поведение, которое включает в себя 4 основные группы жестов:

I группа: *көзгегә якын килеп, боргаланып алды; зур көзге каршына килеп, озак-озак кына үзен күзәтеп торды.*

Эти движения характеризуют женщину, явно довольную своей внешностью. Она пристально смотрит в зеркало, чтобы лишний раз убедиться в собственной неотразимости.

II группа: *кыз [егетнең] муенына сарылды; [егетнең] муенына четердәтеп ябышты.*

Движение, в котором инициатива принадлежит женщине. Она уверена, что ее любят, ей нравиться ощущать себя беззащитным ребенком, требующим к себе снисходительного отношения. Но в то же время она хитра, проявление такой нежности скрывает под собой корыстные намерения.

III группа: *күлмәк итәкләрен тарткалады; кабалана-кабалана, жиңсез кыска күлмәгенең итәкләрен тарткалап ала; итәген сыпыргалый-сыпыргалый; итәгенә сыеша алмый боргаланды.*

Жест, характеризующий состояние от легкой робости до очевидной неуверенности. Поправляя юбку или лишний раз до нее дотрагиваясь, женщина пытается взять себя в руки в неловкой ситуации.

IV группа: *яулык читен, иягенә таба тартып куйды ул; Фатыйма апа яулык чите белән авыз читләрен капларга ашыкты.*

Как правило, жест принадлежит женщинам старшей возрастной группы, которые по мусульманским традициям сохранили привычку прятать лицо от незнакомых людей. Такие движения символизируют скромность, терпимость, смирение.

Мужское поведение представлено боле разнообразно и отличается яркой экспрессивностью. Здесь также выделяются 6 групп жестов:

I группа: *кул селтәде; кулын гына селтәде; кулын селтәде.*

Жест означает отказ от собственных намерений после тщетных стараний, либо резкое неприятие мнения собеседника.

II группа: *кулын сузды; үзенә сузган кулга җавап бирми чарасы юк иде; кулын бирде.*

Этот жест присущ в основном мужчинам. Выражает проявление уважения и предложение к сотрудничеству.

III группа: *уч төпләре белән ике яңагына таянган хәлдә өстәлгә капланып озак кына уйланып утырды; егет ..., башын уч төпләренә салып;*

*уч төпләре белән чигәләрен арап алды; чигәләрен уч төбенә кысып сыгылып төште*.

Данный жест характеризует состояние отчаяния, шока, безвыходного положения в неожиданно сложившихся обстоятельствах. Человек пытается осознать, что же произошло, так как произошедшее едва укладывается в голове.

IV группа: *күзләрен яшерергә теләп, башын стенага таба борды, борынын тартып алды; пешкән сыман бугазында арлы-бирле йөрергә тотынган тоерне юрган читен тартып капларга итте; бугазына килеп тыгылган төерне кеше күзенә күрсәтүдән куркып, йөзен атның ялы арасына яшерде.*

Сильной мужской половине не свойственно проявление слабости, тем более слез, но как бы то ни было, даже мужчинам хочется плакать, по этому жест означает желание скрыть свою слабость от чужих глаз.

V группа: *иңбашларын жыергалап алды; иңбашларын сикертеп куйды; кат-кат иңбашларын жыерып алды.*

Это движение предшевствует принятию серьезного решения. Человек нервно перебирает в мыслях все новые и новые варианты.

VI группа: *кабаланып, чәчләрен сыпыргалап куйды; чәчләрен сыйпап алды; чәчләрен сыпырып алды ул.*

Движение выражает явное замешательство и растерянность в затруднительном положении. Он мобилизирует свои мысленные процессы, концентрируется на проблеме, ищет правильный ответ на возникший вопрос.

Итак, проведенный анализ жестов позволяет сделать некоторые выводы о героях Рината Мухаммадиева в изученных рассказах. Интересна позиция автора по отношению к женщинам: молодые девушки описываются детально, в их движениях чувствуется доля интимности, в отличие от взрослых женщин, в поведении которых доминирует традиционно-татарский менталитет. Поведение мужчин более ситуативно и мобильно. Рассмотренные жесты свидельствуют о намерении контактировать с окружающим миром.

Новое время диктует свои правила. Поэтому мужчины характеризуются неуверенными в поступках и неприспособленными к обстаятельствам.

**Литература**

1. Замалетдинов Р.Р. Татарская культура в языковом отражении. – М.: Гуманит. издат. центр Владос, Казань: Магариф, 2004. – 239 с.

2. Мухамадиев Р.С. Первый подснежник: повести и рассказы. – М.: Современник, 1987. – 266 с.

3. Мухамадиев Р.С. Запутанный узел: повесть, рассказы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1988. – 208 с.

4. (Нео)психолингвистика и (психо)лингвокультурология: новые науки о человеке говорящем / И.А. Бубнова, И.В. Зыкова, В.В. Красных, Н.В. Уфимцева. – М.: Гнозис, 2017. – 387 с.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ ЛЕНАР ШӘЕХНЕҢ БАЛАЛАР ӨЧЕН ЯЗЫЛГАН ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ ТИҢДӘШ КИСӘКЛӘР

*Гафиятова И., Саба р-ны Олы Кибәче мәктәбе, IX сыйныф*

*Җит. – Ә.Ф. Гафиятова*

Минем фәнни-тикшеренү эшемнең темасы – "Габдулла Тукай һәм Ленар Шәехнең балалар өчен язылган шигырьләрендә тиңдәш кисәкләр".

Максатым – бу ике шагыйрьнең балалар өчен язылган шигырьләрендәге тиңдәш кисәкләрне табу, чагыштыру, аларның кулланылу үзенчәлеген, әһәмиятен ачыклау. Бурычларым – Г. Тукай белән Л. Шәехнең балалар өчен язылган шигырьләрен уку. Шигырьләрдәге барлык тиңдәш кисәкләрне җыю. Аларны сүз төркемнәре һәм җөмлә кисәкләре ягыннан анализлау.

Мин кечкенәдән Г. Тукай шигырьләрен яратып укыйм. Үзем дә иҗат итәргә бик яратам. Мине Габдулла Тукайның балалар өчен язылган шигырьләрендә тиңдәш кисәкләрнең бик күп булуы гаҗәпкә калдыра. Минем аларны җыеп анализлап карыйсым килде. Тукайның балалар өчен язылган 36 шигырен, 4 поэмасын укып чыктым. Барлыгы 138 тиңдәш кисәк табылды. Аларны сүз төркемнәре һәм җөмлә кисәкләре ягыннан анализладым. Миндә Тукай иҗатын бүгенге көндәге берәр балалар шагыйренең иҗаты белән чагыштырып карау теләге туды. Мин бигрәк тә Р. Корбан, Р. Вәлиева, Л. Шәехләрнең иҗатына үлеп гашыйк. Мин Л. Шәех әсәрләренә тукталдым. Аның 112 шигырен, 2 әкиятен укып чыктым, тиңдәш кисәкләрне бергә җыйдым һәм кушымта итеп куйдым. Төп эшкә тотынганчы, тиңдәш кисәкләрнең өйрәнелү тарихын беләсем килде. Шушы өлкәгә караган бик күп хезмәтләр белән таныштым, Интернет материалларыннан файдаландым.

Татар телендә тиңдәш кисәкләр XIX йөздә өйрәнелә башлаган икән. Каюм Насыйри тиңдәш кисәкләрне кушма кисәкләр дип атый. Г. Ибраһимов тиңдәш кисәкле җөмләләрне оешкан җөмләләр исеме белән тикшерә. Тиңдәш кисәкле җөмләләр берничә җөмләнең оешуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән дигән фикерне әйтә. 1926 нчы елда бу фикерне Г. Алпаров та куәтләп чыга. Бу өлкәдә М.З. Зәкиев, Ф.С. Сафиуллиналарның хезмәтләре дә игътибарга лаек. Әмма тиңдәш кисәкләрне ике шагыйрь иҗатында тикшергәндә, аларны чагыштырып карау мөмкинлеге була. Шуңа күрә дә бу хезмәттә, Габдулла Тукай белән Ленар Шәех поэзиясенә тукталып, аларның иҗатында тиңдәш кисәкләрнең кулланылу үзенчәлеген билгеләү максаты куелды.

Тукай шигырьләрендәге тиңдәш кисәкләрне (138 тиңдәш кисәк) җөмлә кисәкләре ягыннан аерганда, аеруча хәбәр, аннан кала ия буларак күп кулланылуын күрдем ( Хәбәр – 69, ия – 56 урында). Хәл буларак 21, тәмамлык – 15, аергыч буларак 13 урында кулланылганнар. Л. Шәехтә дә алар хәбәр буларак күп кулланылганнар. (Хәбәр – 49, ия – 29 урында) . Алардан кала хәл буларак 13, тәмамлык – 29, аергыч буларак 14 урында кулланылган.

Ә тиңдәш кисәкләрне сүз төркемнәре ягыннан аерганда, Тукайда иң күп очракта фигыль сүз төркеме буларак (81), исем (69), сыйфат (11), рәвеш (9), алмашлык (2), сан (1), бәйлек сүз буларак 1 урында кулланылганнар. Л. Шәехтә исә иң күп очракта исем буларак (57 ), фигыль сүз төркеме буларак (51) урында, сыйфат буларак – 19, рәвеш – 4, ә сан буларак 1 урында кулланылганнар.

“Г. Тукай һәм Л. Шәехнең балалар өчен язылган шигырьләрендә тиңдәш кисәкләр” дигән темага эзләнү–тикшеренү эше башкарып, мин шундый нәтиҗәгә килдем: тиңдәш кисәкләрнең өйрәнелү тарихы бик кызыклы, галимнәр аларны башта кушма кисәкләр яки оешкан җөмләләр дип кенә атыйлар.

Г. Тукайның балалар өчен язылган 36 шигыре һәм 4 поэмасында 138 тиңдәш кисәк булу шагыйрь иҗатының, сүз байлыгының гаҗәеп дәрәҗәдә булуын күрсәтә. Л. Шәехнең 112 шигыре һәм 2 әкиятендә 132 тиңдәш кисәк кулланылу әсәрләрен тагын да тәэсирлерәк итә.

Тиңдәш кисәкләрне җөмлә кисәкләре ягыннан тикшергәндә, ике шагыйрьдә дә хәбәр һәм ия буларак аеруча күп кулланылганнар.

Тиңдәш кисәкләр сүз төркемнәре ягыннан караганда, иң күп очракта фигыль, аннан кала исем буларак киләләр.

Тиңдәш кисәкләр Тукай поэзиясендә, сөйләмнең тәэсир көчен арттыру өчен, күбесенчә, кире тәртиптә кулланылалар. Нәкъ менә шул ияртүчесеннән соң килгән кисәкләргә көчле басым ясала һәм алар Тукай поэзиясен тагын да җанлы итә. Г. Тукай шигырьләрендә кайбер тиңдәш кисәкләр градация алымы буларак кулланылганнар.

Тиңдәш кисәкләр иң күп очракта санау интонациясе ярдәмендә, аннан кала һәм теркәгече белән бәйләнгәннәр. Алар иҗатында киң кулланылган тиңдәш кисәкләр әсәрләренә аһәң, моң өстиләр һәм укучы күңеленә тирән үтеп керерлек итеп җанландыралар.

Без, бүгенге замана балалары, бер-беребез белән сөйләшер, аралашыр өчен сүзләр тапмыйбыз. Ә Тукайдагы тел байлыгына гаҗәпкә каласың. Ул бер җөмләдә алтышар-җидешәр тиңдәш кисәк кулланган. Шагыйрьләребез шигырьләре аша туган телебезнең нинди бай, матур тел булуын күрсәтергә тырышкан. Менә бу безнең өчен үрнәк, менә бу безгә бәһасез зур мирас! Шушы мирасыбызны саклау безнең кулда. Телебез беркайчан да бетмәсен, тел байлыгыбыз кимемәсен иде.

# Ә. ЕНИКИ ИҖАТЫНДА ФОЛЬКЛОР ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

*Гафиятуллина Э., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Л.Ф. Җамалиева*

Әдәби әсәрләрдә фольклор элементларын куллану төрле яссылыкларда бара. Фольклор традицияләренә мөрәҗәгать итү максатчан да, табигый рәвештә дә очрый, чөнки халык иҗатыннан үсеп чыккан әдәбиятның һәрбер формасы фольклор жанрлары белән тыгыз бәйләнештә, аларның эзлекле үсеш нәтиҗәсе булып тора.

Күренекле язучы Ә .Еники үз әсәрләрендә фольклор элементларынннан актив файдаланган. Мәсәлән, "Тауларга карап", "Ялгызлык", "Кунакта", "Кем җырлары", "Курай" хикәяләрендә, "Йөрәк сере", "Уяну", "Рәшә" кебек повестьларында әдип фольклор элементларын әсәр тукымасына кертеп җибәргән. Алар һәрберсе әсәрләрдәниндидер роль уйныйлар.

Ә. Еники иҗатына бик оригиналь рәвештә мәкаль-әйтемнәр үтеп керә. Ул еш кына аларны халык авыз иҗатындагыча калдыра. Мәсәлән, "Тауларга карап" хикәясенә игътибар итик: *"Юк, дөньяның "**ашын ашаган, яшисен яшәгән**" ялгыз кунагы булып кына яшәргә иртәрәк икән әле, хәрәкәт кирәк аңа, кешеләр белән бергә булу кирәк икән"* [1: 18]. Биредә язучы *"**ашын ашаган, яшисен яшәгән**"* әйтеме аша Локман карт тормышына, язмышына, яшенә бәя бирә; геройның бик карт булуын күрсәтә, әмма шул ук вакытта аның шушы картлыкка бирешергә теләмәвен, яшисе килүен дә күрсәтә.

"Ялгызлык" хикәясендә дә автор Петр Котовны мәкаль ярдәмендә харатерлый: *"Элеккечә ваемсыз, мәнсез ул; аның өчен **үгез үлсә – ит, арба ватылса – утын**, һаман шул "әйдә, ярар!" дигән принцип белән селкенеп йөрүче кеше булып кала бирде"* [1: 41].

Ә.Еники еш кына мәкальләрне диалогларда куллана:

– ***Эш бездән, киңәш синнән**, бабакай!* [1: 18].

– *Бетсен инде ул, **алма пеш, авызыма төш**, дип ятул*ар [2: 12].

"Кем җырлады" хикәясендә исеменнән үк халык җырлары кулланылышы күренеп тора. Әмма автор безгә җыр юлларын бик тиз генә бирми, аңа кадәр ул яраланган солдатның күңеленә үтеп кергән татар җыры турында тәфсилләп сөйли, аннары түбәндәге юлларны китерә:

*Сарман буйлары ай киң ялан,*
*Печәннәре җитәр бер заман шул,*
*Печәннәре җитәр бер заман* [1: 32].

Газап эчендә, үлем белән көрәшеп ятучы сугышчы егет, шул хәлдәге сөеклесе белән очрашу бәхетеннән мәхрүм кыз, аның мәхәббәткә һәм яшәүгә сусау белән тулы сагыш моңы, шуны ишетел сихерләнгән егетнең фаҗигале язмышы – болар һәммәсе романтик контраст итеп бирелә [3: 121]. Автор нәкъ менә шуңа күрә җырга мөрәҗәгать итә.

Җыр мотивы “Рәшә”, “Йөрәк сере” повестьларында да бирелә. Ә. Еники әсәрләренең музыкаль яңгырашына аерым очракларда турыдан туры җыр, халык җыры да ярдәм итә. Җыр һәм моң аның күп кенә әсәрләрендә яңгырап тора. Бу сызыкның ни дәрәҗәдә эзлекле булуын язучының “Җиз кыңгырау” һәм “Гөләндәм туташ хатирәсе” исемле повестьлары да раслый.

Халык авыз иҗаты – тел-сурәтләү чараларының төпсез коесы. Халык иҗатында алма образы яисә әлеге сүз ярдәмендә эндәш сүз, метафора тудыру еш кулланыла. Ә.Еники “Кунакта” хикәясендә әлеге образны ике тапкыр куллана. Мәсәлән:

*– Әй улым, **алтын алмам**, сине онытa язганмы, ләбаса,* - *диде әнисе* [1: 46]. Биредә алтын алмам – бик кадерле, яраткан кешегә әйтелә торган сүз буларак бирелә.

*– Һай Аллам, ни булды, ни булды, нишләттегез мине **алтын алмамны?*** [1: 47]. Әлеге очракта алтын алма метафора итеп бирелә.

Әлеге сүзләрдән тыш бүтән ягымлы эндәшүләр дә “Туган туфрак” әсәрендә очрый. Клара “поезддан төшеп, авыл туфрагына басу белән бик якын итеп, якты йөз белән каршылаган туганнарын, авыл кешеләрен күргәч, аларның “җыр әйткәндәй көйләбрәк” “канатым”, “якты күзем”, “иркәм”, “күз нурым”, “иркә туташ”, “бәбкәм”, “ике күзем”, “аккошым” дип ягымлы эндәшүләрен ишеткәч, табигатькә якын җирдә генә була торган шигърият белән танышкач, бу төшенчәнең бик тирән эчтәлекле булуын аңлый” [4: 14]. Әлеге эндәшүләр халык авыз иҗатында еш очрый. Алар еш кына җырларда урын ала.

“Курай” хикәясе тулысынча татар халык иҗатыннан тора дип әйтергә дә була. Әсәр курайның ничек барлыкка килүе турындагы легенда сөйләүдән башлана: *“Борын-борын заманда...”* Әлеге сүзләр тезмәсе белән күп кенә татар халык әкиятләре, риваять-легендалары башланып китә.

Хикәядә ханның чәч кырдыру легендасы бирелә, ул чәч алган малайларны үтерә торган булган, чөнки алар барысы да ханның мөгезен күргәннәр. Шул мөгез аркасында хан шүрәле белән чагыштырыла.

Хикәя курай турында булгач, биредә сүз халык җырларына барып тоташа. Әмма җырлар бирелмәсә дә, әлеге курай музыкаль уен коралы ярдәмендә төрле көйләр уйналуы әйтелә. Мәсәлән, “Буранбай” көе.

Шулай итеп, Ә.Еники әсәрләрендә фольклор бизәкләре очрый. Әмма автор аларны сак кына, арттырып җибәрмичә генә куллана.

**Әдәбият**

1. Еники Ә. Мәк чәчәге: Хикәяләр. – Казан: Мәгариф, 1999. – 142 б.
2. Еники Ә. Әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 447 б.
3. Халит Г. Таләпчән һәм эзләнүчән талант // Казан утлары. – 1969. – № 3. – Б.112–128.
4. Хатипов Ф.М., Сверигин Р.Х. Әмирхан Еники иҗатының поэтик аһәңнәре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 109 б.

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАРАГАН МАТЕРИАЛЛАРНЫ КУЛЛАНУ

*Гафурова И., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Г.Р. Галиуллина*

Туган җиргә, туган җир төшенчәсе аша туган халкыңа, аның үткәненә һәм бүгенгесенә, теленә һәм, гомумән, яшәү рәвешенә карата укучыларда хөрмәт, мәхәббәт хисләре тәрбияләү – тел һәм әдәбият дәресләренең асыл максатыдыр. Үз илен, үз өен, үз ана телен яраткан бала гына үзенең туган җире белән горурлана, аның өчен җаваплылык хисе тоя ала. Ә горур кеше – ирекле шәхес, ул беркайчан да үз дәрәҗәсен югалтмый.

Дәресләрдә милли төбәк компонентын куллану зарурлыгы менә шундый зур максатларга барып тоташа. Балада туган җиренең һәр почмагына, һәр кешесенә, аның үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә кызыксыну, якын итү, үзенеке итеп тою хисләре салу зур бурычыбыз. Ә республикабызда горурланырлык урыннар, тарихи истәлекләр дә, үрнәк алырлык шәхесләр дә җитәрлек.

Бүгенге буыннарга республикабызның танылган шәхесләре белән никадәр тәрбия бирергә, халыкның бөек уллары бер милләт кысаларына гына сыеп бетмәвен аңлатырга мөмкин бит. Бик ерак булмаган тарихыбызда горурланырлык татар шәхесләре дә җитәрлек.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә әлеге байлыкны ничек файдаланырга, укучының хәтер запасына кереп калырлык, әмма төп дәрес материалына зыян китермәслек итеп дәреснең кайсы этабына кертеп җибәрергә соң?

Әлбәттә, сыйныфтан тыш чаралар, сыйныф сәгатьләре, туган тел атналыклары аша, шәһәрнең истәлекле урыннарына экскурсияләр аша (бәхеткә, республикабыз чын-чыннан музейлар каласы дияргә була) бу максатларга өлешчә ирешергә мөмкин. Әмма бу эшне даими, дәрестән дәрескә эзлекле алып барганда гына, ягъни төбәк компонентын дәрес этапларына кертеп, тематик бәйләнеш, структур бөтенлек булдырганда гына нәтиҗә яхшы булачак, дип уйлыйм. Моның өчен уку елы башында ук эш программаларында милли төбәк компонентын күрсәтү, ничек куллануны планлаштыру зарур. Ул төп дәрес структурасына, темага бәйләнешле булырга, төп материалны ачарга ярдәм итәргә, шул ук вакытта артык басым ясамыйча гына укучының хәтер запасына керә барырга, республикабызда мондый шәхес тә бар икән бит, дип уйландырырга тиеш. Югыйсә, урынсыз, төп материалга ямаулык төсендә генә кереп киткән мәгълүмат укучы күңелендә тискәре караш та формалаштырырга, дәреснең төп яңалыгына зыян да салырга мөмкин бит.

Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләрендә шәһәрләрнең истәлекле урыннары турында әңгәмәләр үткәрү, экскурсия, юлъязма характерындагы сочинениеләр яздыру алган белемнәрне системалаштырырга ярдәм итә.

Югары сыйныфларда презентацияләр дә ясарга мөмкин. Картина буенча сочинениеләр язу өстендә эшләгәндә, Шишкин рәсемнәре ярдәмгә килә. Алар буенча сочинение язганда, туган җиребезнең матурлыгына, илаһилыгына сокланмый, үзеңнең шушы матурлык эчендә яшәвең белән горурланмый мөмкин түгел. Картиналардагы матурлыкны шигырь, хикәя, эссе аша әйтеп бирү таләбе укучыны иҗади эшкә этәрә, балада үзенең хисләрен сүзләр аша тасвирлап бирү күнекмәсе булдыра. Үрнәк итеп, Равил Вәлиевның "Шишкиның шашкын мәхәббәте" эссесын укып күрсәтү отышлы.

Тукай, Такташ, Җәлил, Гыйззәт иҗатларын өйрәнгәндә, җирле шагыйрьләрнең бу бөекләргә багышлап язган шигырьләре дәресләрне үзенчәлекле башлап җибәрергә, я тәмамларга ярдәм итә. Мәсәлән, Ф. Шәех "Такташ җитми", "Такташка гашыйк якташ", Г. Әхтәмова "М. Җәлилгә", "Таҗи Гыйззәт", Л. Абдуллина "Тукайга", Д. Каюмова "Тукай анасына" һ.б. шигырьләр шундыйлардан.

Җирле шагыйрьләрнең шигырьләрен күбрәк тел дәресләрендә бирем башкару өчен текст итеп файдаланып була, өстәмә материал дәрес структурасына кушылып китә, ә инде текст буенча әңгәмә тәрбияви максатны күздә тота. Экологик тәрбия бирү өчен, Т. Кәримова шигырьләре отышлы булса, Ф. Шәех шигырьләре уйланырга, тормышка аек акыл белән карарга өйрәтә, Г. Әхтәмова исә әхлакый тәрбия бирә... Өзек буенча шигырьнең исемен фаразлау, стиле буенча авторын билгеләү кебек эшләрне укучылар яратып башкара.

Туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү, әлбәттә, үткәннәргә дан җырлау, гел мактау характерында гына була алмый. Республикабыз – борынгы төрки шәһәрләрне үз эченә алган дисәк тә, төрки-татар чыгышлы истәлекләрнең аз булуы укучыда сорау тудырмый кала алмый. Элеккесе югалтылган, юкка чыгарылган дисәк, бүгенгеләргә дә тиешле игътибар җитми. Укучыны болар турында да уйланырга өйрәтергә кирәк, чөнки бүгенге укучы – республикабызның иртәгәсе. Туган җиргә мәхәббәт аның өчен сызлану, әрнү аша да формалаша, аны үзгәртү, яхшырту теләге уята. Туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү – укучыны уйларга, һәрнәрсәгә аек акыл белән карарга өйрәтү дә, матурлыкка соклану белән беррәттән ямьсез күренешләргә битараф булмаска чакыру да ул.

Йомгаклап әйткәндә, һәр халыкның үз теле, үз тарихы бар, ул үз тамырларын аңларга, белергә тели. Шушы җәһәттән татар халкының җирле географик терминнарын тикшерү дә халыкның телен, тарихын һәм тамырларын белү-өйрәнүдә үзеннән шактый зур һәм мөһим өлеш кертә.

**Әдәбият**

1. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан: "Раннур"нәшр., 2000. – 214 с.

2. Саттаров Г.Ф. Мәктәптә туган як ономастикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 286 б.

3. Татар лексикологиясе. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 214 б.
4. Харисов Ф.Ф. Хәзерге шартларда татар лексикасына өйрәтү мөмкинлекләре // Международная научно-практическая конференция «Тюркская ономастика: от истоков до современности. – Казань: КФУ, 2018. – С. 23–27.

## ФЛҮС ЛАТЫЙФИНЕҢ «ХЫЯНӘТ» РОМАНЫНДА ТЕЛ-БИЗӘКЛӘҮ ЧАРАСЫ БУЛАРАК ИСКЕРГӘН СҮЗЛӘР

*Гәрәев А., Казан, 7 нче интернат лицей, XI сыйныф*
*Җит. – Ф.К. Гәрәева*

Безне чолгап алган дөнья искиткеч бай. Һәр көн, һәр сәгать, һәр мизгел әйләнә-тирәдә әллә нинди вакыйгалар була, яңа ачышлар ясала, яңа әйберләр уйлап табыла. Ниндидер әйберләр инде бу тормышта вазифаларын тулысынча башкарып тарихка күчә. Кайный тормыш казаны: яңа сүзләр барлыкка килә, кайберләре искереп кулланылыштан төшеп кала. Ләкин вакытлар үтеп, вакыйгалар алмашынгач, алар мәгънәләрен үзгәртеп яңадан да әйләнеп кайтырга мөмкиннәр. Шулай тормыш үзгәрү белән бергә сүзләр дә үзгәрәләр.

Без дә бу фәнни хезмәтебездә искиткеч мавыктыргыч һәм бер үк вакытта шактый катлаулы сүзләр дөньясына сәяхәт итәргә уйладык. Төп өйрәнү объекты итеп Флүс Латыйфиның "Хыянәт" романыннан Казан ханлыгы чорын тудыру өчен хезмәт итүче сүзләрне өйрәнергә булдык.

Халык тормышындагы үзгәрешләр иң беренче чиратта телнең сүзлек составында чагылалар. Бер әйбер яки күренеш искереп юкка чыга икән, аларны белдергән сүзләр дә төшеп кала; аерым очракларда, әйбер яки күренеш үзе калса да, аны атаган сүз урынына яңасы барлыкка килә. Искерүе аркасында хәзерге татар телендә сөйләшүчеләргә бөтенләй таныш булмаган сүзләрне очратырга мөмкин. Алар я телдән инде төшеп калганнар, я аерым сүзнең тамыр өлешендә генә сакланып торалар, я фразеологик берәмлекләр составында гына кулланылалар. Мәсәлән, *чирү* (гаскәр), *икән* (и - тамыр), *сөмсере коелган*. Кайбер төшеп калган сүзләрне инде хәзер белгечләрдән башка берәү дә белми. *Бикасап* (тукыма), *арзу* (теләк), *балпан* (лачын), *барымт*а (талау походы), *барнагыл* (акча берәмлеге), *иге* (яхшы), *багбан* (бакчачы), *баек* (һичшиксез), *балга* (хәрби балта), *бетек* (язу) кебек сүзләр хәзерге татар телендә, мәсәлән, бөтенләй кулланылмыйлар. Аерым сүзләр халык тарихына, аның мәдәниятенә, язма әдәбиятына бәйле булганга, үткән чор язучылары әсәрләрендә, халык авыз иҗатында, фразеологик берәмлекләрдә, географик атамаларда, истәлекләрдә сакланып калган. Флүс Латыйфиның "Хыянәт" романы беренче битләреннән үк, безне Казан ханлыгында барган кызыклы һәм гыйбрәтле маҗаралар дөньясына алып кереп китә. Әсәр татар тарихының гаять катлаулы бер дәверен чагылдыру белән бергә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең сафлыгын, мәхәббәт һәм

дуслыкның тирәнлеген, хыянәтнең ачылыгын тасвирлаудагы осталыгы, тормышчанлыгы белән дә игътибарны җәлеп итә.

Әсәрнең мавыктыру көче – аның сәнгатьчә эшләнешендә. Әсәрдә автор уңышлы кулланган алымнар күп. Милли гореф-гадәтләрне, яшәү рәвешен, кием-салым, сөйләшү үзгәлекләрен оста бирүе сокландыра. Автор чорның үзенчәлекле колоритын сурәтләү өчен тел-бизәкләү чарасы буларак искергән сүзләрдән файдалана. Без бу искергән сүзләрне түбәндәгечә классификацияләдек:

1. Сәяси тәртипләрне чагылдыручы сүзләр (карачы, мәмләкәт, пайтәхет, биләмә, диван, канун, шанлы, һ.б.)

2. Социаль катламны чагылдыручы сүзләр (аксөяк, биләр, морзалар, ыру, углан,бүз, нөгәр, шаһзадә, һ.б.)

3. Кием-салым, тукыманы белдерүче сүзләр (камка, дагалы итек, калфак, киндер, хөллә, сәхтиян, постау һ.б.)

4. Савыт-саба, эш кораллары, йорт-кирәк яраклары, ризыкларны белдерүче сүзләр (чәркә, ташаяк, көлчә, нан һ.б.)

5. Сәүдә, экономика өлкәснә караган сүзләр (базарбашы, базаркән, тамгачы, бәлиш, малтабар, рибачы, пул, дирһәм, һ.б)

6. Йорт-төзелмәләр, юлларны белдерүче сүзләр (гөмбәз, дивар, утар, хөҗрә, сәйфия, кирмән, һ.б.)

7. Дини өлкәгә караган сүзләр (әҗер, басурман, кяфер, дисбе, диндар кеше, әүлия, вөҗүд, дәрвиш, хәрамзадә, хасият, фәтва бирү, һ.б.)

8. Музыка уен коралларын белдерүче сүзләр (дум-думбак, давылбаз, чаң-кубыз, сорнай-кәрнай, саз һ.б.)

9. Географик атамаларга караган сүзләр (Чин, бәхр, Каф тавы һ.б.)

10. Гаскәр, хәрбиләр, сакчылар, сугыш коралларын аңлатучы сүзләр (айбалта, алай, арбакәш, ясавыл, хәнҗәр, чагдавыл, саклаубашы, мәргән, шигавыл, алай, яугир, көбә, гаярь, төмән башы, тоткавыл, һ.б.)

11. Суд, хөкем, хокук өлкәсенә караган сүзләр (чапкылык, сөаль, мөһер).

12. Авырлык үлчәмен белдерүче сүзләр (батман, мыскал һ.б.)

13. Һөнәрчелек өлкәсенә караган сүзләр (зәргәр, ширбәтче, мөһәндис, шам корычы һ.б.)

14. Уку-укыту өлкәсенә караган сүзләр (әсбап, белкевар, әл-җәбр, мөгаллим, гыйльме симия вә гыйльме кимия, гыйльме тыйб, һ.б.).

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: искергән сүзләр безнең телебезнең бер катламы, алар безнең тарихны, үткәнебезне саклый. Ә аларны бөртекләп җыю, саклау хәзерге көн кешеләрнең, ягъни безнең төп бурычыбыз. Флүс Латыйфиның бу өлкәдәге эшчәнлеге бәяләп бетергесез.

**Әдәбият**

1. Латыйфи Ф.Ф. Хыянәт: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 286 б.

2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда I том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 476 б.

3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда II том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 726 б.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, III том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 832 б.

## ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИК ТЕКСТЛАРНЫҢ СТИЛИСТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Гәрәева А., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – пед. фән. докт., проф. Ф.Ф. Харисов*

Дөнья күләмендә социомәдәни процессларның үсү-үзгәрүе, мәдәният феномены һәм тел шәхесе кебек проблемаларга игътибарның артуы фәндә тел-мәдәният мөнәсәбәтләрен өйрәнүче махсус тармак һәм мәктәпләр оешуга этәргеч бирде. Сүз лингвокультурология турында бара.

“Лингвокультурология” термины хәзерге көндә төр төшенчәсе буларак киң мәгънәдә кулланыла, ул тел белеме, этнопсихолингвистика, этнография өлкәләрендәге төрле тикшеренүләрне берләштерә, билгеле бер тел һәм этномәдәният материалында теге яки бу телнең милли, идиоэтник үзенчәлекләрен башка телләр һәм мәдәниятләр белән чагыштырып ачыклый.

Димәк, лингвокультурологик текст дигәндә, без билгеле бер халыкның мәдәниятен, йолаларын, әдәбиятын, дин үзенчәлекләрен чагылдырган текстларга әйтәләр. Мондый текстлар еш кына массакүләм мәгълүмат чараларында, әдәби әсәрләрдә урын ала.

Теманы без “Ватаным Татарстан” битләрендә урын алган лингвокультурологик текстлар ярдәмендә ачыкларга булдык, чөнки биредә стилистик чаралар үзенчәлекле итеп бирелә. Мәсәлән: *“Ә менә Кукмарада балалар итек эченнән чыга”* [4: 3]. Биредә сүз Сабантуйларындагы Кукмара утары күргәзмәсе турында бара. Алар балаларны кайберләрен торна алып килсә, бакчада тапсалар, безнекеләр итектән табыла, дип юмор чарасы белән аңлаталар.

*Сабантуйлар ае – июнь башлангач, җәйнең беренче шимбәсендә республикабызда барлык юллар да Миңгәргә илтте* [4: 3]. Биредә, юлларның Миңгәргә илтүе – арттыру, ягъни гипербола була, чөнки республикабыздагы барлык юлларның да Миңгәргә илтмәвен беләбез.

*Ел саен шушы кечкенә генә авыл Татарстаныбызның тамаша сөючеләрен үзенә тарта торган магнитка әйләнә дә куя* [4: 3]. Биредә, *кечкенә авыл* – эпитет, тапталган эпитет булса да, сурәтләү чарасы.

Авылның магнитка әйләнүе – метафора, автор биредә чагыштыру үткәрә: авыл магнит белән яшерен чагыштырыла. Күренешләр һәм төрле предметлар арасындагы бәйләнешләр ярдәмендә күчерелмә мәгънә барлыкка килә. Бу образлы фикерләү тудыруга, зур һәм катлаулы күренешләрне җыйнак кына бер сүз белән әйтеп бирергә ярдәм итә. Мондый сүзләрнең иң уңышлылары – метафоралар. Әдәби әсәрләр, төрле

язмалар метафорадан башка бик ярлы булырлар иде, чөнки алар образлы сурәтләү өчен хезмәт итәләр. Мәсәлән: *Театрга килгән тамашачы **өч көн ураза тотып киләме соң инде**: спектакль башлану белән чыштыр-чыштыр кабаланулар, нидер йотып, ашап куюлар күренгәли* [4: 4].

*Үткәреләчәк уеннар, ярыш төрләре, сәхнә йолдызларының исем-фамилияләре интерактив плакатка чак сыеп беткән иде. Менә шушы программа әкренләп "сүтелә" башлагач, Миңнәхмәтовларның кечесе Радик Сабантуйны ачып, халыкны котлап, һәркемгә сәламәтлек, уңышлар юлдаш булуын теләде* [4: 3].

Метонимия – билгеле бер күренеш яки әйбер үз исеме белән түгел, бәлки шул әйбердә күзгә бәрелеп торган иң зур үзенчәлекле ягы белән яки ул әйбернең икенче бер әйбер белән бәйләнештә торуы аркасында шул әйбер исеме белән аталу күренеше [3: 80]. Мәсәлән: *"Совет әдәбияты"нда басылып чыкканнан соң, **югарыдагылар** дер селкенде* [4: 4].

Лингвокультурологик текстларда еш кына чагыштырулар очрый. Чагыштыру – сүзне күчерелмә мәгънәдә куллануның иң гади төре. Чагыштыруны эченә алган әйтелмә ике кисәктән тора: чагыштырылган әйберне (күренешне) белдергән сүз һәм чагыштыру өчен файдаланылган әйбер исеме [3: 78]. Мәсәлән: *Дөньясында тамчы да **әше юк сыман** ята бирә йокымсырап* [4: 3]. *Тегесе дә **"әйбәт" дигән күк** мияулап аваз биргәч, янә **тынычлана төшкәндәй** атлый бирә* [4: 3]. *1962 елда ул аны язды һәм бу повесть өчен аңа **кандалалар кебек** ябыштылар* [4: 4].

Һәр журналист чагыштыруларны яратып куллана. Газета битләрендә аларның шактый үзенчәлекләрен очратырга була, чөнки чагыштырулар вакыйгаларны җанлырак итеп сурәтләргә мөмкинлек бирәләр. Мәсәлән, алдагы мисалда Тайфун кушаматлы ат турында сүз бара. Автор *аның йоклавын әше булмаган кешенең ятып торуы белән* чагыштыра.

Лингвомәдәният – тел белеменең телдә миллилекне, мәдәниятне чагылдыру мәсьәләләрен өйрәнә торган юнәлеше [1: 21]. Алда карап узган мисалларда без язмалардагы милләткә, мәдәнияткә кагылышлы сүзләр, гыйбарәләр, стилистик чараларның бирелешенә күзәтү ясадык. Күргәнебезчә, лингвокультурологик текстларда метафора, эпитет, гипербола, метонимия, чагыштыру кебек стилистик чаралар еш очрый. Язма авторлары аларны татар халкының тормышын, күңел дөньясын, иманын, милләт буларак яшәү рәвешен, бөтен нечкәлекләренә кадәр аңлап сурәтләү өчен кулланганнар.

**Әдәбият**

1. Вежбицкая А. Язык. Культура. Познание. – М.: Языки славянской культуры, 1997. – 792 б.

2. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.

3. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

# ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЙ КОМПОНЕНТ В ПРЕПОДАВАНИИ ИНОСТРАННОГО ЯЗЫКА С ПОМОЩЬЮ СОЦИАЛЬНЫХ СЕТЕЙ

(на примере инстраграм)

*Гетманская С., КФУ, студент III курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, ст. преп. А.Ф. Мухамадьярова*

Мы живем в эпоху глобализации и научно-технического прогресса, когда большое количество людей считают обязательным условием своего образования изучение иностранных языков. Очень важным аспектом в изучении иностранного языка является знакомство с культурой и традициями народа. В ходе применения культуроведческого подхода обучающиеся увеличивают свой уровень информированности о знаменитых личностях, традициях, праздниках страны изучаемого языка, объем фоновых знаний. «Лингвокультуроведческий анализ при этом позволяет осмыслить явления культуры своего народа в зеркале культуры других народов, понять общечеловеческие ценности, что важно для формирования мировоззрения» [1: 72].

Для усиления интереса и мотивации обучающихся изучать иностранный язык, наряду со старыми подходами, следует использовать новые технологии, онлайн-сервисы. Одной из распространённых социальных сетей, использующейся в процессе обучения иностранному языку, является Instagram, созданный в 2010 году фотографом-любителем К. Систром [2: 30]. Instagram – бесплатное приложение, позволяющее снимать фотографии и видео, применять к ним фильтры, а также распространять их через свой сервис и ряд других социальных сетей. Данное приложение является одним из самых популярных приложений в мире среди молодежи. Неоднократно оно удостаивалось звания «Приложения года», а его разработчики возглавляют рейтинги «Тридцатки, которой нет еще 30».

Наше исследование посвящено изучению немецкого языка и культуры с помощью социальной сети. В рамках всероссийского марафона 2019 года «Путешествовать и исследовать: создавая будущее с Александром фон Гумбольдтом / Reisen und Forschen: Mit Alexander von Humboldt die Zukunft mitgestalten» нами была создана Инстаграм-страница, посвященная жизни и творчеству Александра фон Гумбольдта. Для студентов 3 курса по направлению 44.03.05 «Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)», профили Иностранный (немецкий) и второй иностранный (английский) язык и Иностранный (английский) и второй иностранный язык разработана викторина, которая проводилась в течение недели, каждый день в постах приводились интересные факты из жизни и творчества ученого, задавались вопросы, на кото-

рые обучающиеся должны были ответить полно и максимально быстро. Интересным аспектом страницы является то, что она велась от лица самого ученого и была оформлена в виде квиза. Суть данной страницы заключается в том, что ежедневно в определенное время, оглашенное участникам, выкладывался один пост с необходимой информацией о том или ином событии, связанном с жизнью «главного героя». Например, первый пост был ознакомительным и предоставлял участникам возможность узнать основную информацию. Далее посты были оформлены таким образом, чтобы в дальнейшем обучающиеся могли ответить на заданные в Инстаграм-историях вопросы. Количество вопросов варьировалось от сложности и емкости предоставленной темы. Текст постов и вопросов был написан как на русском, так и на немецком языках для лучшего восприятия и усвоения информации.

В качестве примера проанализируем одну из публикаций на тему «Маршрут путешествия Гумбольдта по России». Вначале был выложен пост с маршрутной картой и описание самого путешествия, из которых участники должны были найти и проработать необходимую для дальнейших ответов информацию. После этого были заданы тематические вопросы, оформленные различным образом для повышения вовлеченности и статистики ответов.

Основная цель обучения иностранному языку – это умение адекватно применить язык в любой коммуникативной ситуации. Поэтому в ходе ответов на вопросы была поставлена задача не просто содержательно изложить полученную информацию, но и грамотно ее оформить. Следует отметить, что созданный квиз способствует совершенствованию не только навыков общения на немецком языке и закреплению коммуникативной компетенции, то есть способности и готовности осуществлять общение как в форме говорения и понимания собеседника, так и в форме опосредованного общения. Именно поэтому был выбран путь оформления страницы от первого лица. Участники могли задавать интересующие их вопросы как по содержанию текста, так и по грамматике в комментариях или же сообщением в Директ.

Таким образом, социальные сети могут быть использованы при интеграции культурологического компонента, лингвострановедческой информации на занятиях по иностранным языкам. Инстаграм делает знакомство и изучение культуры страны изучаемого языка увлекательным путешествием.

**Литература**

1. Егорова Т.Н. Лингвокультурологический аспект в обучении иностранным языкам студентов младших курсов неязыкового вуза // Известия РГПУ им. А.И. Герцена. – 2008. – №63-2. – С.71–73.

2. Ивкина М.И. Функциональность социальной сети Instagram при обучении иностранному языку // Высшее образование сегодня. – 2019. – № 11. – С. 30–35.

## ТАТАРЛАРДА СӘЕР ИСЕМНӘР

*Гилмутдинова Ә., М. Акмулла ис. БДПУ, II курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. И.С. Насипов*

Ни өчен без татар исемнәре белән кызыксынабыз? Чөнки татар телен яратабыз, халык мәдәниятен хөрмәт итәбез, милли гореф-гадәтләрне саклыйбыз.

Хәзер баланың нинди җенестән булуын әти-әни булырга әзерләнгәннәргә алдан, ана карынында чакта ук билгеле була. Шуңа күрә күпләр исемне сабый туганчы ук сайлап, төгәлләп куя. Берәүләр исемен җисеменә туры китерергә тырышса, икенчеләре модага ияреп яки үзләре уйлап тапкан ят, сәер исемнәр белән аерылып торырга омтыла. Саф татар баласына шәһәр, тау, елга, акча берәмлеге һәм техника кебек теләсә нинди предмет исемнәренә кадәр кушучылар бар. Урыслашуны да кичерде безнең халык [2: 3].

ЗАГС хезмәткәрләре сәер исемнәр белән халыкны даими таныштырып тора. Узган ел Феодосия исемле бала туган. Ә күптән түгел Аналь исемле бала теркәлгән. Кыргызстаннан килгән гаилә яңа туган ир балага шундый исем кушкан [4].

Ниндиләре генә юк бу сәер исемнәр рәтендә: *Дурдона, Женевьева, Ахиллес, Багратион, Хусайба, Мухожира, Гликерия, Амадис, Анабель-Мария, Евангелина, Дельфина…* Зур үскәч инде, исемнәрен ошатмаучылар аны алмаштыра ала. Соңгы вакытта *Ангела, Готела, Джессика, Риана* булып үзгәрүчеләр дә шактый. Закон буенча исемне күпме телисең, шулкадәр тапкыр үзгәртергә ярый.

Тарихта хәтта *Счастье, Алоэ һәм Боль* кебек исем йөртүчеләр булуы да ачыкланган. Россиянең “Евро-2008”дә уңышлы чыгыш ясавыннан соң, илебездә яңа туган балаларга җиңүче булган *Гус* исеме кушу модага керде. Мондый очраклар Түбән Новгород, Екатеринбург, Новосибирск якларында теркәлгән.

Исемнәр турында сөйләшү һәрвакыт актуаль. Мәсәлән, бүген берәр танышыңның баласы туа икән, “нинди исем куштыгыз?”, дип сорамасаң да була. Кыз булса – *Камилә*, егет булса – *Кәрим*. Калганнары – искәрмә! Шундый мода. Шундый тенденция [1].

Татарларда сәер исемнәр шактый күп. Аларның кайберләренә игътибар итик: *Атлас Гафиятов*, “Татарстан яшьләре” журналисты; *Луара Шакирҗан*, Камал театрының музей мөдире. *Анурбик Гобәйдуллин*, “И.М.”ның актив укучысы; *Маузер Гыйниятуллин*, “Агыйдел” татар-башкорт дуслыгы оешмасы рәисе иде. *Маузер* – немец фамилиясе, пистолет исеме буларак та билгеле; *Вилен Касыймов*, Югары Ослан районының мәгариф бүлеге җитәкчесе; *Вилен* – Владимир Ильич Ленин сүзтезмәсеннән ясалган; *Реканс* – реконструкция сүзеннән [7].

Игътибар итсәң, ирләр арасында хатын-кызлар исемнерен дә очратырга мөмкин: *Гүзәл Әхмәтҗанов*, Зәй районының “Гидромонтаж” оешмасының бригадиры. Һәм, киресенчә, хатын кызлар арасында да ир-ат исемен йөртүчеләр дә бар: *Фирдәвис Якупова* – минем авылдашым.

Россия Федерациясе территориясендә гадәти булмаган исемнәр белән мавыгу СССР чорында ук башланды. Балаларның исемнәре арасында бәйрәм атамалары, билгеле тарихи шәхес исеме яисә эшчәнлек өлкәсен тәшкил итә торган бик катлаулы аббревиатуралар күзгә ташлана: *Владлен* – Владимир Ленин, *Гертруда* – герой труда, ягъни хезмәт герое, *Ленор* – Ленин – безнең корал, *Ким* – Комминстический интернациональ молодежи, ягъни Яшьләрнең коммунистик интернационале һ.б. Әмма Россиядә халкының исем кушуда сәер һәм мәгънәсез сүзләр белән мавыгуының яңа дулкыны булды (мәсәлән, *Христамрирадос, Дельфин, Апрель, Принцесса Даниэлла, Заря-Заряница, Алёша-Каприна, Океана, София-Солнышко* һ.б.) [5].

Мондый башбатаклык яңа туган балага рөхсәт ителгән яки рөхсәт ителмәгән исемнәр турындагы яңа законны гамәлгә кертү зарурлыгына китерде. Россия Президенты В.В. Путин 2017 елда балаларга сәер мәгънәсез исемнәр бирүне тыючы законга кул куйды [5]. Хәзер “Галилә кодексына” кертелгән үзгәрешләргә ярашлы, баланы символ, сан, хәреф-сан кушылмасыннан торган исем белән атап булмый (мәсәлән, Иляс беренче, БОЧ рВФ 260602 – Биологический объект человека рода Ворониных-Фроловых, родившийся 26 июня 2002 года). Шулай ук сүгенү сүзләрен, дәрәҗә, рангалар яисә титул атамаларын исем итеп кушып булмый. Исемнәрдә “дефис”тан башка тыныш билегеләрен дә куллану тыела [6].

Соңгы чорда татарлар арасында тарихи-традицион ата-бабаларыбыз кушкан исемнәргә әйләнеп кайту сизелә. Күпләр исемдә дә хикмәт барлыгын аңлый хәзер. Чыннан да, кеше үз аты өчен оялып, кыенсынып, язмышлардагы ялгышларда әллә исемемнең дә өлеше бармы, дип шикләнеп, үзенә тагылган теләсә нинди исем-кушаматларга риза булып йөрергә тиеш түгел. Киресенчә, ул үзенең, эти-әнисенең һәм ата-бабасының исеме белән горурланырлык булсын иде.

**Әдәбият**

1. Исемең матур, кайсы матчтан//URL. https://matbugat.ru/news/?id=334 / – 2008. – 26 июнь (мөрәҗәгать итү датасы: 16.12.2019).

2. Мәгънәле исем – ярты бәхет // Татарстан яшьләре. – 2017. – 9 январь.

3. Народные артисты СССР, РФ, РТ. – Казань: Мәгариф-Вакыт, 2011.

4. Сәер исемнәр // URL. https://tuylar.ru/. Первый сайт о татарских свадьбах. Казань, 2009-2011 (мөрәҗәгать итү датасы: 16.12.2019).

5. Путин подписал закон о запрете называть детей нелепыми именами // https://ria.ru/20170501/1493442235.html (дата обращения 06.01.2020).

6. Федеральный закон "О внесении изменений в статью 58 Семейного кодекса Российской Федерации и статью 18 Федерального закона "Об актах гражданского состо-

яния" от 01.05.2017 N 94-ФЗ // http://www.consultant.ru/document/cons_doc_LAW_ 216079/ (дата обращения: 06.01.2020).
7. Чакмагышта яңа башлык // Кызыл таң. – 2017. – 11 март.

## ТАТАР ТАҖЫНА ЛАЕК ОЛУГ ШӘХЕСЛӘР

*Гыйздәтуллина Н., Яр Чаллы педагогия көллияте, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд. Р.Ә. Миңһаҗева*

Сүзебез язучы Ркаил Зәйдулланың «Без тарихта эзлебез» циклы белән Казанның меңьеллыгына багышлап нәшер ителгән «Татар таҗы» (2004) [2] исемле китабы хакында. Әлеге хезмәт милләтебезнең X-XVIII гасырда яшәгән һәм татар тарихында тирән эз калдырган шәхесләр тормышына багышланган.

Китапта автор барлыгы утыз өч шәхес турында гади, балалар һәм яшүсмерләргә аңлаешлы итеп, шул ук вакытта тарихи фактларга таянып, фәнни төгәллекне саклап, кечкенә генә хикәяләр иҗат иткән. Укучы алар аша Кол Гали, Бату хан, Нурсолтан, Үзбәк хан, Сәйф Сараи, Туктамыш, Идегәй, Олуг Мөхәммәд хан, Мөхәммәдьяр, «Сөембикә», Мөхәммәд Әмин, Кол Шәриф, Җангали батыр, Мәүлә Колый, Морат Солтан, Сәетбатыр, Алдар Исәнгилде, Батырша, Бәхтияр Канкай һ.б. күренекле шәхесләрнең тиңдәшсез образлары белән таныша ала.

Р. Зәйдулла аларны тыйнак кына «нәни» хикәяләр дип атаса да бу басманың балалар өчен тәрбияви әһәмияте бик зур. Катлаулы тарихыбызны үтемле итеп, патриотлык, милли үзаң тәрбияли торган якларына басым ясап, шул ук вакытта менталитетыбызга хас тискәре сыйфатларыбызны да яшермичә, автор төрле заманнарда «татар таҗы»н горур йөрткән шәхесләрнең тулы образын ача, алар яшәгән тарихи чорга үз бәясен бирә.

Һәр хикәядә мөһим канатлы сүз урын алган, гыйбарә булырдай үзәк фикер ассызыкланган. Әйтик, Алмыш ханның Болгарны исламлаштыруга керткән өлешен тасвир кылгач, Алмыш ханның Ислам кабул итәргә этәргән төп сәбәбен аңлатырлык: *«Халык бер йодрык булып укмашса, ил беркайчан да җиңелми»* дигән фикерне чыгарып куйган.

*Кешеләрнең йөрәге*
*Сөенечтән кысылган,*
*Дөньяга хәбәр киткән:*
*«Без барыбыз мөселман!»* [2: 6].

Китапта барлык хикәяләрнең дә эчтәлеге, шәхесләрне тулырак күзаллар өчен, Рушан һәм Рэм Шәмсетдиновлар тарафыннан тудырылган төсле сурәтләр белән баетылып бирелгән. Шулай ук, автор Ркаил Зәйдулла геройларының һәрберсенә атап, алар рухына изге дога булып барырлык шигырьләр дә иҗат иткән. Әлеге багышлауларының фәлсәфи-эстетик вазифалары, образны танып-белүдәге роле зур. Монда Ркаил Зәйдулланың

чичәнлеге, үткерлеге, милләтпәрвәрлеге дә, җан сыкравы, тарих турындагы уйлары, фәлсәфияте дә ярылып ята.

Әйтик, «Нәһҗел – фәрадис»не язган Мәхмүд Болгари хакындагы юллар поэманың Алтын Урта чорыннан алып бүгенгәчә яшәвен, киләчәктә дә үлемсезлеген, мәңгелеген раслап киләләр:

*Каш өстенә кулын куеп.*
*Иле өчен юл карый,–*
*Ничә гасыр гаделлеккә*
*Өнди Мәхмүд Болгари* [2: 24].

*«Коллыктан да зур хурлык юк!»* дигән шигарьне югары күтәргән милли каһарманыбыз Сәет батыр турындагы хикәя ахырындагы дүртьюллык, гомумән, милләтебезне күз карасыдай сакларга өнди, Рәсәйнең мәкерле сәясәте алдында, үзеңне богаулаттырмаска куша:

*Азатлык юлы газаплы.*
*Тик татлы да бу газап.*
*Чигенсәң, Сәетләр рухы*
*Алыр кебек бугазлап* [2: 90].

«Татар таҗы» китабында автор түбәндәге афористик фикер-гыйбарәләрне укучылар күңеленә ирештергән: *Җиңүчеләр җиңелгән халыкны һәрвакыт ялчы итә / Тезләнеп яшәгәнче, аягүрә үлүең мең мәртәбә артык! / Дәүләтле халыкның бөек шагыйрьләре дә була / Хан белән шагыйрьнең сүзе беркайчан да уртак булмый / Кадерсез йорттан кот (җан) кача / Без бердәм булсак, дошман куркып торыр! / Ызгышлы ил бәхетле булмый /Атлы ир-ат җәяүлегә юлдаш булмас! / Имин йортта ил бәхетле булыр! / Азатлыкны теләнеп, соранып түгел, яулап, даулап алалар! / Татарга татардан башка ярдәм итүче булмас! / Коллыктан да зур хурлык юк / Гыйбрәт өчен халык үз сатлыкларын да онытмаска тиеш һ.б.* Авторның бу гыйбәрәләрне, канатлы сүзләрне каһарманнары образына нисбәттә оста үреп бирүе аның педагогик сәләте, яшь укучыларны милли рухта, кыю шәхесләр итеп тәрбияләүдә сүз сәнгатенең әһәмиятен, кадерен белеп, каләм көчен туры юнәлтеп эш итүен күрсәтә.

Тарихка күз салсак, XVIII гасыр урталары милләтебез елъязмасына татарларның бәйсезлеге өчен көрәшкән атаклы каһарманыбыз – Батырша исеме белән кереп калган Баһадиршаһ (Габдулла Галиев) бар. Ул халкыбызның газаплы, хокуксыз тормышы, үз илендә тоткын булып яшәвенә протест йөзеннән 1755 елда халыкка ялкынлы мөрәҗәгате белән чыга – изге көрәш – җиһадка чакыра [1: 6].

Ркаил Зәйдулла «Татар таҗы» китабында иң әүвәл Батыршаның сынмас рухына игътибар иткән, төрмәдән аның патшага: «Без әле бетмәдек. Безнең көчебез әле бар» – дип хат язу күренешен дә бик урынлы керткән [2: 99]. Алты ел төрмәдә утыргач, Батыршаның сакчыларга каршы һөҗүм оештырган вакытта

һәлак булуын бәян иткәннән соң, ахырда, хикәясен «Батырша! Син безнең йөрәгебезгә янә батырлык чаткысы сал!» − дигән өндәү-мөрәҗәгать белән тәмамлап, киләчәк буыннарны тел һәм милләт сагында торырга өнди.

Мәгълүм булганча, шәхесләр халык эчендә формалашалар, җитлегәләр. Халык һәм шәхес мәсьәләсен Р.Зәйдулла «татар таҗы» на лаеклы каһарманнарыбыз мисалында бик үтемле итеп тасвирлап биргән.

**Әдәбият**


1. Бәйрәмова Ф. Баһадиршаһ»: әдәби-документаль роман. − Казан: «Аяз» нәшр., 2006. – 304 б.
2. Зәйдулла Р. Татар таҗы: X-XVIII гасырларда яшәгән олуг кешеләр турында нәни хикәяләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – 103 б.


## ЗӨЛФӘТ ХӘКИМНЕҢ «ТЕЛСЕЗ КҮКЕ» ДРАМАСЫНДА СИМВОЛИК ОБРАЗЛАРНЫҢ ӘДӘБИ ФУНКЦИЯСЕ


*Гыймадиев Б., Казан, 144 нче мәктәп, X сыйныф*

*Җит. – Л.Һ. Җиһангәрәева, Л.Р. Төхвәтуллина*


Матур әдәбият – сәнгатьнең иң матур төре. Язучы төрле алымнар, чаралар ярдәмендә үз фикерен укучыга җиткерә. Шулар арасында символлар аерым урын алып тора. Алар язучыга әйтергә теләгән фикерен яшерен рәвештә бирергә ярдәм итәләр. Укучы уйлана, фикерли, нәтиҗәләр ясый. Символлар беркайчан да искермиләр. Яңадан-яңа мәгънәләр белән генә байыйлар. Бүгенге көндә актив тормыш позициясендәге укучыга фикерне маңгайга бәреп түгел, үзе уйланырлык итеп җиткерергә кирәк. Шунлыктан символларны табу, күрү, алар аша фикерләү бүгенге көндә актуаль булып тора. Фәнни эшнең максаты: Зөлфәт Хәкимнең “Телсез күке” драмасында кулланылган символларның әсәрдә башкарган мәгънәви әһәмиятен ачу. Фәнни эшнең теоретик әһәмияте: Зөлфәт Хәкимнең “Телсез күке” драмасы культурологик аспектта анализлана. Фәнни эшнең практик әһәмияте: Зөлфәт Хәкимнең “Телсез күке” драмасы татар әдәбиятында беренче тапкыр яңа күзлектән анализланып, укучыларга, туган тел укытучыларына тәгъдим ителә.

Символ термины, бер яктан, әдәби образ, икенче яктан, билге сыйфатларын үзенә туплый. Автор “Телсез күке” пьесасының жанрын “театраль роман” дип билгели. Театр сәхнә әдәбияты өчен яңа жанр. Ретроспектив алым ярдәмендә бүгенге тормыш белән үткәндәге хәл-вакыйгалар чиратлашып, Бөек Ватан сугышы алды чорыннан алып XX гасыр ахырына кадәрге вакытны үз эченә алган тормыш күренешләрендә авторның милләт язмышы турындагы уйланулары алгы планга чыга. Безнең күз алдыннан Күке Зарифының гаять каршылыклы, интригалар белән тулы гыйбрәтле язмышы үткәрелә. Зариф образы Зөлфәт Хәкимнең, һичшиксез, зур табышы. Татар әдәбиятында мондый образ юк иде әле. Без әсәрләрдән һәрвакыт үзебезгә үрнәк булырдай ир-егет образларын эзлибез.

Безнеңчә, ул – Туфан Миңнуллинның Әлмәндәр бабае, Мәхмүт Хәсәновның Иргалие, Нурихан Фәттахның Албугасы белән беррәттә торучы, чөнки анда тормышчанлык көчле. Автор аның гади-гадәти татар егете булып үсүенә кат-кат басым ясый. Иң мөһиме – яхшылыкны, изгелекне аңлый белү, шуны яшәү принцибы итү Зарифның бөтен асылын билгели. Шуның белән бергә әсәрдә Зыятдин образы да мөһим урынны алып тора. Әсәрнең идея-кыйммәтен ачуда Күке, җыр, пәке символлары бик уңышлы файдаланылган. Беренчедән, Телсез Күке символы әсәрнең исеменә үк чыгарылып, үз эченә зур мәгънә туплаган. Иң беренче чиратта, ул – туган як, туган табигать матурлыгын аңлата. Икенчедән, ялгызлык билгесе. Төрки-татар мифологиясенә мөрәҗәгать итсәк тә, анда күкенең нигезендә аерылу, ялгызлык, сагыну символлы булуы өстенлек ала. Зариф карт та урманда ялгыз яши, вакыт-вакыт өянәге тотып ул телсез дә кала. Телсез булу – тарихыңны, хәтереңне җую да. Сугышта винтовканы телсез иткән тел яшәргә тулы хокуклы.Тел ул – дуслык коралы, тормыш ачкычы. Күбрәк аралашып, дуслашып, ярдәмләшеп яшәсәк, котырына-котырына кораллану кирәк тә булмас иде.Тагын шуны да истән чыгармаска кирәк: телсез булып, үзебезнең, илебезнең язмышына битараф булмыйк. Хокукларыбызны да яклый белик. Күзәтүләрдән чыгып, шуны билгеләп үтәсе килә: күке символы әсәрнең идеясен ачуда бик мөһим әдәби функция үти. Әсәрнең эчтәлеген ачудан символик образлар бик әһәмиятле роль уйныйлар. Шуларның берничәсенә тукталып үтәсе килә. Әсәрнең исеменә үк чыгарылган Күке образы. Төп геройның кушаматы Күке Зарифы. Ул бу турыда үзенең бала чагы белән бәйле вакыйганы сөйли һәм кушаматын шуның белән бәйли. Безнең фикеребезчә, Күке кушаматының мәгънәсе киңрәк. Иң беренче чиратта, ул – туган як, туган табигать матурлыгын аңлата. Күз алдына китерү дә кыен: күке тавышы яңгырамаса, урман-кырларның матурлыгы булыр идеме икән? Икенчедән, ялгызлык билгесе. Зариф карт та урманда ялгыз яши, вакыт-вакыт өянәге тотып, ул телсез дә кала. Төрки-татар мифологиясенә мөрәҗәгать итсәк тә, анда күкенең нигездә, аерылу, ялгызлык, сагыну символик булуы өстенлек ала. Бәетләрдә исә күке образы турыдан–туры үлем белән бәйле. Әле күке кычкыруның кайгы-хәсрәт, елау, күз яше символлары булуы татар халык җырларында да чагылыш таба.

Җыр символы күпкырлы төсләрне, төсмерләрне үз эченә алган һәм иң зур гомумиләштерү куәтенә ия булган үтә дә көчле традицион һәм символик образ. Татар җыры – безнең тарихыбыз да, хәтеребез дә, өмет-хыялларыбыз да, халыклар арасындагы күперләр дә, күңел матурлыгының тышкы чагылышы да, рухи дөньябыз да. Авторның “Винтовканы телсез калдырган җырны ничек үтереп булсын икән?!”– дигән сүзләрендә зур

мәгънә ята. Автор җыр, пәке символларын уңышлы куллана, драманың идея-эстетик кыйммәтен арттыра, укучыга уйланырга урын калдыра.

Драмада кулъяулык – сөю, вәгъдә, мәхәббәт билгесе буларак кулланыла. Пәке символына килсәк, бу очракта очлы, үткен корал буларак түгел, ә истәлек, көч-акыл, намус символы буларак кулланыла. Пәке кем кулында бит?! Туган илен яклап көрәшкә күтәрелгән, туган халкының иң матур сыйфатларын үзендә туплаган Зарифта. Сөйгәненең бүләген югалтырга, якыннарының өметләрен акламаска хакы юк аның.

Димәк, "Телсез Күке" драмасында кулланылган символлар гомумкешелек дөньясын чагылдыручы элементлар булып торалар. Язучы символлар белән бик иркен эш итә, һәм алар әсәрнең идеясен ачуда мөһим функция үтиләр. Бу исә Зөлфәт Хәкимнең чын каләм остасы булуын күрсәтә.

**Әдәбият**


1. Заһидуллина Д. Каһкәле елмаю // Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. – 124 б.

3. "Татар исән чакта аның язучылары да булачак" (Зөлфәт Хәким белән Илфак Ибраһимов әңгәмәсе) // Казан утлары, 2015. – № 1.

4. Хәким З.З. Телсез Күке: пьесалар / Зөлфәт Хәким. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2007. – 480 б.


## СЫНЛЫ СӘНГАТЬТӘ БАКЫЙ УРМАНЧЕ


*Гыйниятуллина Д., Казан, 124 нче мәктәп, XI сыйныф*

*Җит. – К.У. Мөслимова*


Татарстанның һәм Россия Федерациясенең халык, Казахстанның атказанган рәссамы, Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе (1967) Бакый Идрис углы Урманче озын һәм күп төрле эшләр башкарган гомер юлы кичте. Габделбакый кече яшьтән үк рәсем ясау белән мавыга. Армиядә чагында студиягә йөреп, азмы-күпме һөнәри белем ала. Аннары сәнгать училещесына укырга керә. Сәләтле студент буларак, анны укырга 1920 нче елда Мәскәүгә җибәрәләр. Шунда ул ВХУТЕМАСта югары белем алу бәхетенә ирешә. Берьюлы ике факультетта укып, нәкыш (живопись) һәм уем-сын (скульптура) һөнәрләрен ныклап, гомерлеккә үзләштерсә дә, белемгә сусаган Бакый моның белән генә чикләнми, өстәмә рәвештә чит телләр институтына йөреп, француз телен өйрәнә.

Казанда һәм, бигрәк тә, сәнгатьнең авангард юнәлешләренең үзәге булган Мәскәү Югары сәнгать-техник остаханәләрендә белем алуы, соңрак хөр фикерле иҗат атмосферасы хөкем сөргән Казан сәнгать-педагогика техникумында укытуы, 1920 елларда Ф. Таһиров, Ш. Мөхәммәтҗанов, М. Кәримов кебек графика өлкәсендә – китап һәм журнал бизәлеше юнәлешендә эшләгән башка рәссамнар шикелле үк, Урманченың да нәкыштә новаторлык юлын сайлавына этәргеч бирә. Урманченың новаторлык өлкәсендәге эшчәнлеген ике чорга бүлеп карарга мөмкин:

беренчесе – 1920 елларда һәм икенчесе – 1950 еллар ахырында Казанга кайтуыннан алып, гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәвам итә.

*Жантасова Н., Батыс Қазақстан инновациялық-технологиялық университеті, IV курс студенті*

*Ғыл. жет. – филол.ғыл. канд., доц. А.Н. Бекмашева*


Қазақстан Республикасының Ұлттық Ғылым Академиясының академигі, филология ғылымдарының докторы, профессор, Қазақстан Республикасына еңбек сіңірген ғылым қайраткері, Қазақстан РеспубликасыМем*лекеттік сыйлығының және Ш.Уәлиханов атындағы сыйлықтың иегері Рәбиға Сыздықтың қазақ тіл біліміне ғана емес, ұлтымыздың әдебиетіне, мәдениетіне, психологиясына, этнографиясына қосқан еңбегі орасан зор. Ғалымның ғ*ылыми-зерттеу еңбектері, негізінен, қазақ әдеби тілінің тарихы, Абайдың поэтикалық тілі, қазақ тілінің поэтикасы, XV – XIX ғасырлардағы ақын-жыраулар тілі, ортағасырлық жазба ескерткіштер тілінің тарихы мен лексика-грамматикалық құрылымы, текстологиясы, тарихи лексика, лингвостилистика, тіл мәдениеті салаларына арналған.

Қазақ лингвистикасы ғылымы өзінің даму тарихында түрлі көзқарастар мен ғылыми тұжырымдардың, теориялар мен зерттеулердің куәсі болған. Сондай дәйекті тұжырымдар мен ғылыми зерттеулердің авторы Р. Сыздық тіл ғылымының өзекті мәселелері қатарында аталатын әдеби тіл нормалары мен олардың қалыптасу ерекшеліктері, тіл мен сөйлеу мәдениетінің нормативті қалыптары, жазу мен емле заңдылықтары, Қ. Жұбановтың қазақ тіл біліміндегі орны, А. Байтұрсынов және тіл білімі мәселелері, Абай тілінің ерекшеліктері, түркітану мәселелері, тарихи лексикологияның негізгі қырлары, көркем мәтін лингвистикасы және оны талдау, тіл білімінің жаңа бағыттары, қазақ тілінің синхрондық және диахрондық жағдайы, тілдегі мақсатты-стильдік саралану секілді тілдік проблемаларды арнайы зерттеп, өзіндік соны тұжырымдар айта білген. Оның тіл мәдениеті мәселелеріне арналған еңбектерінде қазақтың ұлттық әдеби тілінің қолданыс аясы, тілдік норма проблемалары, тіл мәртебесі, ұлттық мәдениет пен тіл арақатынасы жан-жақтары зерттелген. Тілдік норма мен оның кодификациясы мәселесі академиктің «Тілдік норма және

оның қалыптануы» деген еңбегінде алғаш рет сөз болған еді. Ғалым қазақ әдеби тілінің нормативті негіздерін айқындап, қалыпқа түскен тілдік нормалардың теориялық, практикалық негіздерін көрсетіп берген [1: 38].

*Қазақ сөзінің даму тарихы мен мағынасын саралау – ғалым зерттеулерінде басымдыққа ие бағыттардың бірі.* Ғалымның еңбектерін қарастырып отырған шақта кез келген адам өзінің ана тіліне, оның құдіретіне деген сүйіспеншілік сезімін сезінеді. Ғалымның «Сөз құдіреті», «Сөздер сөйлейді», «Сөз сазы», «Абайдың сөз өрнегі» деген еңбектері тарихи лекикология, көркем мәтін тілінің, соның ішінде, қаламгер, жазушы тілінің көркем шеберлігі мәселесіне, сөз қызметінің көркемдік-эстетикалық қызметіне арналған. Ол өзінің 1997 жылы жарық көрген "Сөз құдіреті" атты еңбегінде М. Әуезовтің 20жылдардағы әңгімелері тілінен бастап, Шерхан Мұртаза, Әбіш Кекілбаев, Мұхтар Мағауин, Сейдахмет Бердіқұлов, Оралхан Бөкеев, Асқар Сүлейменов, Тахауи Ахтанов, Қабдеш Жұмаділов, Кәдірбек Сегізбайұлы тәрізді қазақ көркем сөзінің қас шеберлері қаламынан шыққан туындыларға лингвостилистикалық тұрғыдан талдау жасап, олардың сыры мен сымбатын ашып береді. Сөз шеберлерінің шығармаларын сөз таңдау, сөз қолданыс, сөз әрлеу тұрғысынан зерттейді. "Сөздер сөйлейді" еңбегі ғалымның аса бір зеректікпен орындаған жұмысы болды. Тілшінің өзі айтқанындай: «Белгілі бір сөздің, не сөз тіркесінің бұрынғы және қазіргі қолданысына, яғни сөз мағынасының өзгерісіне, даму эволюциясына назар аудару. Бұл ана тіліміздің барша байлығын айқындай түсуге жол ашады» [2: 159].

Рәбиға Сыздықтың бірқатар зерттеулері қазақ әдеби тілінің тарихы сан ғасырға тереңдеп, тамырын әріден алатынын дәлелдеп берді. Ғалым Асанқайғыдан бастап, Махамбетке, Бұқарға, Дулатқа дейінгі бес ғасыр өкілдерінің бізге жеткен сөз үлгілерін әдеби мұра деп қарастырып, оларды әдеби тілдің аспектісі ретінде зерттеді. Бұл дәуір мұраларының фольклордан бөлек, әдебиеттік шығармалар екенін дәлелдей келіп: «Қысқасы, қазақта халық әдебиетінен өзге, бірақ оған едәуір ұқсас келетін профессионал әдебиет өмір сүріп келді, оның тілі әдеби тіл санатына кіреді», – деп, бұл дәуірлерге тиесілі мұраларды *ауызша әдеби тіл* терминімен атауды ұсынды. Сөйтіп, Р. Сыздық ауызша әдеби тіл ұғымы мен терминін ғылыми айналысқа енгізді, уақыт өте келе мұндай таным-түсінік қазақ әдеби тілі теориясының негізгі постулаттарының біріне айналды; көпке дейін әдеби тіл деген ұғымға тиянақты анықтама берілмей келсе, енді қазақ жазба әдеби тілі, қазақ ауыз әдебиеті тілі, қазақтың жалпыхалықтық тілі деген категориялар бір-бірінен ажыратылып, әрқайсысы өз алдына саралана бастады. Осылайша ғалымның әдеби тіл туралы ойлары кең арналанып, қазақ әдеби тілі белгілі бір зерттеу нысаны бар, онысы көпаспектілі, әрқайсысы дербес,

бірақ бір-бірімен сабақтасып жатқан бағыт-бағдары бар ғылым саласы ретінде нақтылана түсті. Қазақ әдеби тілі әр қырын функционалдық тұрғыдан тануға болатын іргелі ғылым саласы аталып, жоғары оқу орындарындағы басты пән санатына енді, бір сөзбен түйіндей айтқанда, қазақ әдеби тілі біртұтас филологиялық проблематика деңгейіне көтерілді. Сондықтан біз академик Р. Сыздықты әдеби тілдің тарихи аспектісін айқындаған, қазақтың ұлттық тілдік тұлғалар ұғымын әдебиетте де, тілде де қалыптастырып, тұрақтандырған, ауызекі сөйлеу тілі мен әдеби тілдің айырмашылығын ашып-ажыратқан, қазақ әдеби тілінің тарихи дамуының күре жолдарын хронологиялық тәртіппен түзіп берген *ғалым*.Оның теориялық тұжырымдары арқылы қазақ тіл білмінде жаңа бағыттар ашылып, жаңа мектептер қалыптасты.

Қазақ атты ұлттың тілінің көркемдігін, ұлылығын айқындап, тілдің өзінің мәдениеті болатынын, қазақтың әр сөзін сөйлетуге болатынын еңбектері арқылы дәлелдеп көрсетіп берген академик Рәбиға Сыздықтың ұлттық руханият сахнасында алар орны ерекше болмақ.

**Әдебиет**

1. Сыздық Р. Тілдік норма және оның қалыптануы. – Астана: Елорда, 2001. – 230 б.
2.Сыздық Р. Сөздер сөйлейді (Сөздердің қолданылу тарихынан). Толықтырылған 3-басылымы. – Алматы: Арыс, 2004. – 232 б.

## М. АУЭЗОВ И О ПЕРЕВОДЕ КАЛМЫЦКОГО ГЕРОИЧЕСКОГО ЭПОСА «ДЖАНГАР»

*Жаскайратова А., Сарсенгалиева А., ЗКИТУ, студенты I курса*
*Науч. рук. – магистр филол. наук С.А. Бекетаева*

В творческом наследии великого писателя Мухтара Ауэзова особое место занимает художественный перевод. Свое мнение к литературному переводу М. Ауэзов рассказал в статьях «Некоторые теоретические проблемы художественного перевода», «Практика перевода Пушкина на казахский» [1: 5]. Переводческие труды Ауэзова всегда публиковались в виде отдельного издания или в различных сборниках. В том числе, Мухтар Ауэзов успешно перевел и издал книгу калмыцкого героического эпоса «Джангар» («Зәngjr»). В докладе проанализирован аспекты художественного перевода и восприятие творчества Мухтара Ауэзова за рубежом.

Героический эпос «Джангар» – величайшее устно-поэтическое творение монгольских народов занимает достойное место в сокровищнице мировой культуры. Эпос «Джангар», представляя вершину устно-поэтического слова калмыков, служил надежным способом сохранения и передачи богатейших народных знаний, нравственно-эстетических ценностей народа, являлся свидетельством высокой культуры и героической истории народа, отражением многовековой памяти народа о своих древних корнях, традиционных верованиях, обычаях и обрядах [2: 177].

Героический эпос «Джангар» был переведен на несколько языков, в том числе в 1940 году и на казахский язык, главным редактором был М.О. Ауэзов. Перевод эпоса «Джангар» («Зəngjr») был напечатан 17 апреля 1940 года в типографии г. Алма-Ата на латинской графике, так как в Казахстане в период с 1929 по 1940 гг. использовалась данная графика [3: 195].

Перевод калмыцкого героического эпоса «Джангар» на казахский язык осуществили М. Ауэзов, А. Токмаганбетов, Ж. Сайын, А. Жумагалиев, Х. Бекхожин и К. Аманжолов. На наш взгляд, переводчики пользовались поэтическим переводом С. Липкина «Джангар. Так как, после удачного дебюта с переводом "Джангара" большой знаток народного творчества, писатель Мухтар Ауэзов лично встретился с Семеном Липкином.

Казахский перевод «Джангара» был издан в юбилейный 1940 год отдельной книгой, то есть к 500-летию калмыцкого эпоса. Перед переводчиками стояла не простая задача: сделать перевод и точно передать содержание эпических глав, семантику калмыцкой эпопеи. Переводчикам также удалось отразить специфику национальной культуры, особенности кочевого быта и военного прошлого. Казахские литераторы перевели две главы: "О походе против лютого хана Хара Киняса" («Қаныпезер хан Қара Қинасқа қарсы жорығы») (1-26 стр. К. Аманжолов, 26-60 стр. Ж. Сайын, 60-81стр. Х. Бекхожин, 81-91стр. К. Аманжолов) и главу "О поражении свирепого хана шулмусов Шара Гюргю" («Шара Гүргу деген қатал ханның жеңілгені») (92-119 стр. Х. Бекхожин, 119-134 стр. А. Жумагалиев, 134-147 стр. Ж. Сайын, 147-170 стр. К. Аманжолов, 170-195 стр. А. Токмаганбетов). Как мы видим, две главы были разделены между пятью литераторами. Надо отметить, что в книге «Зəngjr»/«Жəңгір» («Джангр») на казахском языке имя А. Жумагалиева, который не был указан в списке переводчиков на второй странице издания. Определить имя переводчика, не указанного на титульном листе издания позволило то, что после каждого поделенного отрезка перевода указывается данные переводчика. Соответственно, информация о А. Жумагалиеве была представлена в конце перевода, осуществленного им.

Таким образом, казахские переводчики М. Ауэзов, А. Токмаганбетов, Ж. Сайын, А. Жумагалиев, Х. Бекхожин и К. Аманжолов удачно справились со стоящей перед ними задачей. Но особенностью старой латинской графики были буквы, которые не совсем точно отражали звуки живого казахского языка. Поэтому две главы из эпоса «Джангар» на латинской графике 1940 г. трудно поддаются чтению, что вызывает некоторое неудобство для современного казахстанского читателя.

М. Ауэзов обогатил казахский народ своим произведением, и переводчики проделали большую работу по переводу, перевод героического эпоса «Джангар» позволил как казахстанским ученым, так и казахскому

народу в целом ближе соприкоснуться с культурным наследием братского калмыцкого народа.

**Литература**

1. Энциклопедия Мұхтар Әуэзова. – Алматы: изд-во «Атамура», 2011. – С. 5.

2. Хабунова Е.Э., Корнусова Б.Э. Эпос "Джангар" как источник сохранения и развития современной духовной и материальной культуры калмыков. – Элиста, 2004. – 177 с.

3. «Зəngjr» («Джангр») / □almag galgьnьƞ olь eposь = Джангр: Калмыцкий народный эпос. – Алма-Ата: Казахстанское изд-во худ. лит., 1940. – 195 с.

## ЮРИДИК ЛЕКСИКАДА ГАРӘП АЛЫНМАЛАРЫ

*Җамалетдинова Д., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., доц. Э.В. Гафиятова*

Татар теле үсешенә зур йогынты ясаган телләрнең берсе – гарәп теле. Дини, мәдәни, сәүдә-икътисадый мөнәсәбәтләрнең озакка сузылган үсеше нәтиҗәсендә, әлеге көнчыгыш телнең лексемалары татар теленең төрле семантик-функциональ төркемнәренә күп санда үтеп керәләр һәм аларда ныклап төпләнәләр һәм кайвакытта, хәтта грамматик һәм фонетик яктан төрки чыгышлы сүзләрдән аерылмыйлар.

Татар һәм гарәп телләре арасындагы әйтелеш үзенчәлекләрендә, лексик-грамматик төзелешендә, грамматикасында зур аерма булуга карамастан, гарәп алынмаларының күпчелеге татар телендә озак яшәеш нәтиҗәсендә нык үзләштерелгән һәм татар теленең лексик-грамматик нормаларына буйсынган.

Юридик лексикада гарәп сүзләрен куллану гарәп илләре дөньясында үзенчәлекле хокук системасы белән бәйле. һәм ул Идел Болгары дәүләтендә ислам дине кабул ителгәннән соң барлыкка килә.

Билгеле булганча, ислам динен тотучы халыкларда суд эшчәнлеге шәригать кануннары (дини нормалар һәм күзаллаулар нигезендә кануннарның үзенчәлекле җыелмасы) нигезендә алып барылган. Ләкин тарихи-сәяси үсешнең объектив фактлары аркасында, шәригать татарларның суд системасында үзенең төп ролен югалткан. Вакыт узу белән төрле объектив фактлар аркасында, дини төшенчәләрне билгеләгән төрле терминнар пассив лексикага күчкән.

Шуңа да карамастан, хәзерге татар теленең юридик лексикасында гарәп алынмалары шактый зур роль уйный. Вакытлы матбугат, радио-телевидение, эш кәгазьләрен башкару системасында аларны еш күрәбез һәм ишетәбез. Мәсәлән:

*Варис* – кулында мирас булган, кем дә булса мирас калдырган яки мираска хокукы булган кеше, мирасчы (Судта аның варислары булу-булмау белән кызыксындылар).

*Гариза* – нәрсә дә булса сорап язылган үтенеч язуы (Кооператив әгъзалары Федераль законда каралган хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап судка гариза белән мөрәҗәгать итә алалар).

*Җәза* – гаеп эш яки җинаять эшләгән кешегә карата кулланыла торган йогынты ясау чарасы (14 майда Казанның Вахитов районы мәхкәмәсе узган ай татарны яклап митинг оештырган Фәрит Зәкиевкә ун мең сум җәза бирде).

*Җинаять* – җәмгыятьтә закон тарафыннан тыелган куркыныч (яман) гамәль: коточкыч җинаять, җинаятьне яшерү, җинаять кылу, җинаятьне ачу, җинаять эшләү (Татарстанда табигатька карата җинаятьчел гамәлләр өчен 35 җинаять эше кузгатылган).

*Зыян* – матди югалту, матди каза, зарар: әхлакый зыян, матди зыян (Әлеге чара алимент бурычы булганнарга, сәламәтлеккә зыян салыну яки тәрбияләүченең үлеме белән бәйле зыян салыну, шулай ук милек яки мораль зыян буенча бурычларга кагылмый).

*Канун* – югары хакимият органы кабул иткән һәм югары юридик көчкә ия норматив акт (кагыйдә) (Татарстан Республикасы кануны нигезендә татар һәм рус телләре, дәүләт телләре буларак, татар һәм рус әдәбияты мәктәпкәчә, гомуми, башлангыч һәм урта һөнәри белем учреждениеләрендә бертигез күләмдә өйрәнелергә тиеш).

*Карар* – махсус тикшерү яки киңәшләшүдән соң туган нәтиҗә, эш планы яки йөкләмә (Бу карарны хөкүмәтнең мәгариф өлкәсендәге яңа идеологик доктринасы башлану дип әйтергә була).

*Мирас* – хуҗа (башлыча ата-ана, якын туган) үлгәч, башка берәүнең хосусый милкенә күчә торган мал-мөлкәт, байлык: *мирас алучы, мирас калдыручы, мираска калган* (Мирасны варисларга дөрес итеп бүлеп калдыру мөһим).

*Мөлкәт* – кемнең дә булса карамагында булган мал, байлык: *күчемсез мөлкәт* (Арест, мөлкәтне шикле затның, гаепләнүченең җинаять гамәлләре аркасында алынуын җитәрлек нигезләгән очракта, башка затлар мөлкәтенә дә салынырга мөмкин).

*Нәкәс-ниятләр* – нәрсә дә булса эшләр өчен алдан корылган уй-план, теләк (Нәкәс-ниятләр кешене шул юлга бастыра түгелме?).

*Ришвәт* – берәр максатка ирешү өчен кемне дә булса сатып алу, үзе өчен берәр законсыз эш эшләтү нияте блән бирелә торган акча яки әйбер: *ришвәт алу, ришвәт бирү* (Соңгы айларда гына берничә ришвәт алу очрагы теркәлгән).

*Хаким* – судья, хөкем итүче хөкемдар (Үзен хакимнәрнең хакиме итеп тойган бу бәндәгә дә көн җитте).

*Хөкем* – 1. җинаять эшләрен карау, суд эше: хөкемгә тарту, хөкем бара; 2. суд карары, җәза карары: хөкем чыгару (Бу эшкә карата иң кискен хөкем карары чыгарылды).

*Хокук* – иҗтимагый мөнәсәбәтләрне тәртипкә сала торган дәүләт тарафыннан билгеләнгән һәм сакланган кагыйдәләр җыелмасы һәм шул

кагыйдәләрне өйрәнә торган фән (Россия Федерациясе Конституция судының 2004 елгы 16 ноябрендәге 16 карарында Татарстанның мондый хокукы расланды).

*Шаһит* – 1. берәр эш яки вакыйганы күрүче, шуны раслаучы кеше: шаһит җавабы; 2. берәр эш, күренеш яки эшне расларлык дәлил: җинаятьнең әйберләтә шаһите (Аның эш кабинетында тикшерү үткәрәләр, Дәүләтъяров аңа шаһит буларак катнаша).

*Шикаять* – 1. берәр гаделсезлекне хәл итүне сорап язылган гариза: шикаять язу; 2. кемнең дә булса өстеннән бирелгән әләк, аны гаепле итеп күрсәткән сүз яисә язу; жалоба (Әлеге Кодексның 316 статьясы нигезендә чыгарылган хөкем карарына әлеге Кодексның 379 статьясы 1 пунктында каралган нигезләр буенча апелляция һәм кассация тәртибендә шикаять бирелә алмый).

Татар теленә гарәп теленнән күчкән сүзләр арасында исемгә *-намә* кушымчасы ялганып ясалганнары да очрый. Мәсәлән:

*Васыятьнамә* – васыять кәгазе; мирасчыга калдырылган мирас турында таныклык кәгазе (Васыятьнамә булу эшне бөтенләй башка якка борды).

*Хөкемнамә* – хөкем карары язылган кәгазь, суд карары язмасы (Алар хөкемнамә белән танышып чыктылар).

*Шикаятьнамә* – кем өстеннән дә булса шикаять язылган рәсми кәгазь, жалоба (Өлкәннәр советы, шикаятьнамә алгач, район күзәтчесе белән элемтәгә керер).

Татар телендә гарәп юридик алынмаларының бер өлеше сүз ясалышы ягыннан үзгәрешләргә дучар булган. Алар арасында, кушымчалау ысулы белән исемнән исем барлыкка килгән. Мәсәлән:

*-ла/-лә*: *гаепләү* («Мәскәү эше» нигезендә яңа гаепләү белдерелгән программист Айдар Гобәйдуллин Русиядән киткән); *мәсхәрәләү* (хатын-кызны) (Газетаның 1 сентябрь санында «Ахырзаман галәмәтләре» рубрикасында балаларны һәм хатын-кызларны мәсхәрәләү очраклары турында әйтелә).

*-лык/-лек*: *әхлаксызлык* (Әхлаксызлык чәчәк аткан бу дәвердә кемнән игелек көтәргә?); *вәхшилек* (Ау инспекторларын да шаккатырган вәхшилек! Лаеш урманында 3 поши, 2 кыр кәҗәсе һәм бер кабанны атып үтергәннәр); *гаделлек* (Гаделлек өчен көрәшнең мәгънәсезлеген һәммәбез беләдә бит); *иминлек* (дәүләт иминлеге, шәхси куркынычсызлык, җәмәгать куркынычсызлыгы, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы); *хокуклылык* (юридик хокуклылык); *хәвефсезлек* (Хәвефсезлеккә ышану һич мөмкин булмаган август ае якынлаша иде шул); *хәрәкәтсезлек* (җинаятьчел хәрәкәтсезлек); *шаһитлык* (шаһитлык бирү) һ.б.

*-чы/-че*: *мирасчы* – мирас алырга хокукы булган кеше; *хөкемче* – хөкем итүче, судья; *ришвәтче* – ришвәт алучы; *җинаятьче* – җинаять эшләүче, закон бозучы (җинаятьчеләр урындыгана эләгү – җавапка тартылу, судка эләгү).

Гарәп теленнән алынган сүзләр катнашында, сүзтезмәләргә кушымча ялгану юлы белән катлаулы исемнәр барлыкка килгән. Мәсәлән: *зыян күрүче* (Зыян күрүченең, аның вәкиленең, шаһитның аларның якын туганнарының, туганнарының һәм якын затларының иминлеген тәэмин итү өчен кирәк булганда, зыян күрүче, аның вәкиле яисә шаһит катнашкан тикшерү гамәле беркетмәсендә тикшерүче аларның шәхесе турында белешмәләр кертмәскә хокуклы); *җәмәгать яклаучысы* (Милли Мәҗлес карарларына ясалган экспертиза белән Фәүзия Бәйрәмованың җәмәгать яклаучысы Тәлгать Әхмәдишин риза түгел).

Гарәп алынмалары катнашындагы катлаулы конструкцияләргә түбәндәге исемнәрне кертергә мөмкин: *шикаять язуы* (Сабиров шикаять язуы белән дә керергә исәпли иде); *үлем җәзасы* (Мәскәү мэры Юрий Лужков наркотик таратучыларга үлем җәзасы кертергә тәкъдим иткән иде).

Татар телендә гарәп алынмаларына *булу, итү, китерү, бирү* фигыльләре ялганып фигыль нигезле юридик сүзләрдән барлыкка килгән. Мәсәлән: *балигъ булу* (Бары балигъ булганнарга гына язылышу мөмкинлеге бирелә); *мәҗбүр итү* (Суд алимент түләргә мәҗбүр итә ала); *тәэмин итү* (Хәрәкәт курканычсызлыгын тәэмин итү; матди тәэмин итү; дәгъваны тәэмин итү); *дәлил китерү* (Андыйларга бер дәлил китерү җитәдер); *җәза бирү* (Җәза бирү белән куркытылган балалар дөресен сөйләмиләр).

Күргәнебезчә, татар телендәге юридик терминнарның һәм төшенчәләренең шактый өлеше гарәп алынмаларыннан гыйбарәт. Бу, һичшиксез, татарларның гарәп чыгышлы мөселманнар белән күп гасырлык мәдәни-дини, тел, сәүдә элемтәләре белән элемтәдә булуы белән аңлатыла.

**Әдәбият**

1. Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексы: I-V өлешләр / Тәрҗ.: М.Р.Әмирова, Н.Г.Хәйруллина.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 287 б.
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 2005. – 848 б.
3. matbugat.ru сайты.

## ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНЫҢ ПОЭТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Җиһаншина М., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Л.Ф. Җамалиева*

Җыр – сүз-текст белән көй-музыканың үзара үрелүенә нигезләнгән, җырлап башкаруны күздә тотып иҗат ителгән әсәр. Ул – халык лирикасында һәм язма поэзиядә аеруча киң таралган жанр. Татар халкының бу төр шигъри – музыкаль хәзинәсе ике өлештән тора: халык җырлары һәм профессиональ җырлар [4: 3]. Мәкаләбездә халык җырларында тукталырбыз.

Фольклор әсәрләрендә халыкның тормыш тәҗрибәсе, рухи дөньясы. Алар шушы байлыкны саклап, безнең көннәргә кадәр китереп җиткергәннәр. Болар, әлбәттә, халык җырларына да карый һәм аларның кыйммәтен арттыра. Кеше кайда гына булмасын,ниләр генә эшләмәсен,

җыр һәрвакыт аның белән бергә яши. Халык җырларында тормышның иң әһәмиятле мизгелләре чагылыш таба [5: 3].

Тикшерүнең методологик нигезе. Җырның тарихын, аңа бәйле проблемаларны Х. Ярми, И. Надиров, М. Мәһдиев, Ф. Урманче, М. Бакиров, К. Миңнуллин, Л. Җамалиева кебек галимнәребез өйрәнгән һәм бүгенге көндә дә актив тикшерә.

Тема актуаль, чөнки халык җырларының сюжеты, поэтикасы кызыклы һәм бик үзенчәлекле, традицион образлар, символ, метафораларга бай, аларны җентекләп анализлау, аерым образларны карау телнең, татар халкының мәдәниятын, менталитетын тулырак өйрәнү өчен бер адым булып тора, булган хезмәтләрне тулыландыра.

Тикшерүнең объекты – татар халык җырлары, предметы – халык җырларының поэтик үзенчәлекләре.

Мәкаләбездә түбәндәге җырлар каралды һәм анализланды: “Каз канаты”, “Иске кара урман”, “Сөембикә китеп бара”, “Көзге ачы җилләрдә”, “Көймә генә килә генә”.

Сугышка киткән газиз баш
Туган илләргә кайтмый [“Каз канаты”].
Кемнәр сиңа ясин укыр
Газиз җаның чыкканда... [“Каз канаты”].

Әлеге җыр аша без төп геройларның аерылышу ачысын тоябыз. Сугышка киткән егетләр үзләренең исән-сау кайта алмау өметен, кызларның сөйгәннәрен югалтуын күрәбез, аны җыр ярдәмендә җиткерүләре бу күренешне тагын да моңсуландырып җибәрә, кешеләрнең хисләрен ачык күрсәтә. Музыка, җыр мәхәббәт хисен дә, сөйгәнеңнән аерылу фаҗигасен дә көчәйтү өчен кулланыла.

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк лә үтәргә;
Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк гомер итәргә [“Иске кара урман”].

Урман ул – кара көчләр яши торган урын. Урманны кеше үзе өчен ят, куркыныч урын буларак кабул иткән. Җырда кара урман әкиятләрдәге кебек ят, куркыныч урынны гына белдерми, ә авыр тормышны аңлатучы метафора буларак кулланыла. Димәк, кара урман образы татар халык җырларында авыр, михнәтле тормыш, кайгы-хәсрәт символы булып килә.

Сөембикә ак яулыгын
Тоткан учлап кулына;
“Хуш, Казаным, каласың”, – дип
Үкереп елый буена [“Сөембикә китеп бара”].

Әсәрдә XVI гасыр уртасында татар халкы кичергән тирән фаҗигане үзендә туплаган Казанның соңгы ханбикәсе – Сөембикә образы күрсәтелгән.

Бардым күлгә, салдым кармак,
Безгә балык эләкми шул;
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам.
Көзге ачы җилләрдә лә,
Туган-үскән илләргә [“Көзге ачы җилләрдә”].

Төп образ – җил – гомер агышын, ә ачы сүзе ул гомернең төрле кыенлыклар аша узуына ишарәли. Лирик герой тормышның авырлыгына ишарә итә (“безгә балык эләкми шул”), туган авылын сагынуын искә ала, илдән бер чыгып киткәч, тиз кайтып булмавын ассызыклый. Мондый зар төрле кешедә: эш эзләп, чит илгә китүчедә дә; репрессия елларында сөргенгә озатылган шәхестә дә була ала.

Мәк чәчәкләре коела
Былбыл кагынган саен;
Мәк чәчәкләренә карыйм
Сезне сагынган саен [“Көймә генә килә генә”].

Уен һәм кыска җырларда сөйгән ярлар, ерактагы якын дуслар мәк чәчәгенә яки мәк орлыгына тиңләштереләләр. Җырларда гөл-чәчәкләр, аларның матурлыгы, төс-күренешләре кешенең хис кичерешләренә дә тәэсир итә. Алар туган җир матурлыгын, гүзәл яшьлекне, шул ук вакытта гомер агышын, сагыш-моңны гәүдәләндерүгә дә хезмәт итә.

Нәтиҗә ясап, шуны ассызыклап үтәргә кирәк: җыр – теләсә кайсы милләтнең олы хәзинәсе. Халык җыры, халык көе – ул, халык авазы, халык тойгысы һәм фикеренең турыдан-туры чагылышы, аның музыкаль теле. Алар кешенең бар кайгыларын, шатлыкларын, ара-тирә була торган шаян-шуклыкларын чагылдыра.

**Әдәбият**

1. Миңнуллин К. М. Һәр чорның үз җыры. – Казан: Мәгариф, 2003. – 400 б.
2. Миңнуллин К. Җырларның шигъри табигате. – Казан: Мастер лайн, 1999. – 250 б.
3. Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. – Казан, 1988. – 488 б.

## К ПРОБЛЕМЕ ИССЛЕДОВАНИЯ КОНЦЕПТА «ХЛЕБ» В РАЗНЫХ ЛИНГВОКУЛЬТУРАХ

*Закирова А., КФУ, магистрант I курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Р.С. Нурмухаметова*

Безусловно, хлеб занимает исключительное место в жизни любого народа. Именно поэтому написано множество диссертационных исследований, посвященных хлебу, рассматриваемых в разных ракурсах. Среди таких трудов можно выделить работу А.С. Котельниковой, выполненную в русле комплексного исследования концепта «хлеб» в русской языковой картине мира в рамках концептологического подхода В.В. Колесова [6: 25]. В ней прослеживается развитие «хлеба» во времени.

Появившись как общеславянская лексема со значением *'жертвенный хлеб'*; *'хлеб, сохраняющий форму, сделанный из специального (кислого) теста'*, потом постепенно приобретал новые содержательные формы и значения: *'пропитание', 'продовольствие'; 'печеный хлеб, пища'* (XI век); *'зерновой хлеб', 'просвира'* (XII век); *'хлеб на корню', 'кушанье, угощение'* (XV век); *'заработок, средства к существованию'* (XVI век).

Что касается семантического анализа, отмечается, что производные слова с корнем *хлеб* образуют несколько семантических парадигм, актуализирующих различные значения концепта «хлеб». *Хлеб-соль – хлебосольный-хлебосольство,* передает важные составляющие концепта *'пища'* и *'угощение'*. *Хлебосольство* обозначает глубоко национальное свойство русского народа и передает символическое значение концепта.

Также выделяется еще один ряд слов: *нахлебник – нахлебнический – нахлебничать – нахлебничество*. Лексемы передают значение *'жить за чужой счет'* и актуализируют одно из наиболее важных значений концепта «хлеб»: *'средства к существованию'*.

Работа Л.С. Зинковской выполнена в русле лексико-семантического анализа [5: 12]. В своем труде «Репрезентация концепта хлеб в народно-разговорной речи XIX–XXI вв.» Л.С. Зинковская приходит к выводу, что в формировании семантической группы *утварь*, используемая для приготовления хлеба, принимает участие лексика севернорусского, южнорусского происхождения (квашня – дежа), а также других славянских языков (чиринъ), что связано с историей заселения исследуемого региона. Каждому этапу выпечки хлеба соответствует специальная посуда: для приготовления *опары, квашни (квашня, квашонка, квашоночка, квашница, заквашёнка*), для выскребания квашни (*квашенник, квашенный нож*), для посадки хлебов в печь (*хлебная лопата*).

Так же концепт «хлеб» реализуется посредством лексико-семантического поля *хлебобулочные изделия*, которое формируют лексико-семантические группы: *пироги и выпечка, состоящая из подгрупп шаньга, сковородное, хворост*. В каждой лексико-семантической группе содержатся единицы, известные всем западносибирским говорам (*шаньга, курник, розанцы, стружки*), а также фиксируемые только в говорах Среднего Прииртышья (*розочки, ризцы, драшки*), которые репрезентируют уникальность диалектной концептосферы. В исследуемых говорах бытует лексема *курник* и однокорневые образования *куринка, куренёк, акурник, курень* для обозначения *'пирога с начинкой'*, на севере области в качестве начинки выступают сало, мясо, капуста, на юге – курица. В говорах курник сохраняет свое обрядовое значение (Ежели свадьба курник стряпают).

Л.Х. Самситова в своей работе «Культурные концепты в башкирской языковой картине мира» останавливается и на концепте «икмәк/хлеб» [7:

105]. Делая акцент на том, что концепт «хлеб» несет в себе не только смысл естественного жизнеобеспечения, но и символ духовного образа жизни башкирского народа, Л.Х. Самситова излагает понятия данного концепта: 1) продукт; 2) родовое понятие для зерна; 3) средство жизнеобеспечения; 4) духовная пища. Та кже приводятся лексемы, через которые репрезентируется концепт «икмәк»: *он* (мука), *ашлык* (зерно), *иген* (хлеб, зерно). Делается акцент на том, что башкиры испокон веков поклонялись хлебу, и что у них наблюдается бережное отношение к хлебу.

Если говорить о работах, в которых концепт «хлеб» рассматривался и сравнивался в языковом сознании представителей разных культур, то можно выделить статью Е.В. Гачма, где концепт «хлеб / bread» рассматривается в языковом сознании представителей русской, английской и американской лингвокультурных общностей [4: 93].

Исходя из того, что для анализа концептосфер различных языков целесообразным представляется обращение к ассоциативному эксперименту. В данной работе в целях научного исследования был проведен ассоциативный эксперимент с регистрацией цепи ответов, в котором приняли участие русские, английские и американские студенты в возрасте от 20 до 28 лет (в каждой группе по 50 человек). Испытуемым предлагалось реагировать на слово-стимул «хлеб / bread» таким количеством ответов, которое они успеют воспроизвести за 1 минуту. В данном эксперименте у русских студентов самой частотной ассоциацией был фразеологизм – *хлеб всему голова* (12), у англичан и американцев – *масло* (20) и *вода* (15) соответственно.

Концепт «хлеб» является более значимым для носителей русской культуры, в их языковом сознании закрепилось отношение к хлебу как к чему-то главенствующему, первостепенному, основополагающему. С хлебом связываются представления о жизни, труде, гостеприимстве (*хлеб-соль*). В представлении русских хлеб, прежде всего, *черный* (у англичан и американцев – *белый и французский*), а потом уже *ржаной и белый*.

Реакция «еда» явилась второй по частоте у русских (8), англичан (15) и третьей у американцев (7). Так же у английских и американских студентов «хлеб» (bread) ассоциируется *с сырьем*, из которого он производится. В их представлении хлеб также связан *с деньгами* (англичане – 3 реакции, американцы – 5).

Что касается татарской языковой картины мира, изучена тема “пища / еда” Ю.А. Ахметзяновым [1: 79], [2: 464], Ф.С. Баязитовой [3: 480]. Но тщательного исследования концепта “хлеб”, к сожалению, не наблюдается.

Рассмотрев, изученность данного концепта у представителей других культур, можно прийти к выводу о том, что созрела необходимость исследования концепта «хлеб / икмәк» в татарской языковой картине мира.

**Литература**

1. Әхмәтҗанов Ю.Ә. Икмәк кадере. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 79 б.

2. Әхмәтҗанов Ю.Ә. Татар халык ашлары. – Казан: Раннур, 1999. – 464 б.
3. Баязитова Ф.С. Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы / Ф.С. Баязитова. – Казан: “Дом печати” нәшрияты, 2007. – 480 б.
4. Гачма Е.В. Концепт «хлеб / bread» в языковом сознании представителей русской, английской и американской лингвокультурных общностей // Общество: философия, история, культура. – 2012. – №2. – С. 91–94.
5. Зинковская Л.С. Репрезентация концепта ХЛЕБ в народно-разговорной речи XIX - XXI вв.: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Омск, 2006. – 26 с.
6. Котельникова А.С. Концепт «Хлеб» в русской языковой картине мира: дис. … канд. филол. наук. – Санкт-Петербург, 2016. – 100 с.
7. Самситова Л.Х. Культурные концепты и их реализация в сказочном тексте (на материале башкирских народных сказок о животных) // Вопросы когнитивной лингвистики. –2011. – №4. – С. 103–110.

## «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНДА СӘЛАМӘТЛЕК ТЕМАСЫНА БАГЫШЛАНГАН МӘКАЛӘЛӘРНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

*Закирова Ә., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Р.К. Сәгъдиева*

Хәзерге җәмгыятьтә сәламәтлекне саклау мәсьәләсе мөһим проблемага әйләнеп бара. “Сәламәтлек – иң зур байлык”, диләр. Сәламәтлек – кеше бәхетенең нигезе. Исәнлек булганда гына кеше үзенең максатларына ирешә, тирә-юньне танып белә, җәмәгать тормышында актив катнаша, хезмәттән, физик күнегүләрдән, күңел ачулардан ямь таба. Сәламәт булырга теләү – һәр кешенең табигый омтылышы.

Үсеп килүче яшь буынның да сәламәтлеген саклау һәм ныгыту һәр шәхес өчен, тулаем җәмгыять өчен зур әһәмияткә ия. Шуның өчен вакытлы матбугат битләрендә сәламәтлек темасына караган язмаларның, рубликаларның саны елдан-ел арта. Әлеге язмалар укучыларда кызыксыну уята, сәламәтлекләре турында уйланырга мәҗбүр итә.

Фәнни эшебезнең төп максаты – вакытлы матбугатта сәламәтлек темасына багышланган мәкаләләрнең атамаларына күзәтү ясау. Фактик материал “Ватаным Татарстан” газетасыннан тупланды. Әлеге газетада сәламәтлеккә багышланган кушымта эшләп килә, язмалар аерым рубрика итеп урнаштырыла.

Язманың исеме – аның иң мөһим күрсәткече. Ул мәкаләгә алып кереп китәргә, аны ачып бирергә тиеш. Мәкалә исемендә авторның ни турында язганы, мәкаләнең эчтәлеге чагылыш таба. “Ватаным Татарстан” газетасының сәламәтлек кушымтасында урнашкан мәкаләләрнең атамалары кешеләрнең организм һәм саулык турында күзаллауларын киңәйтүгә, дөрес туклану белән сәламәтлекләренең ныклы бәйләнештә булуын аңларга булышу, иҗади күзаллауларын үстерүгә нигезләнгән. Мәсәлән: *“Холестерин төерчекләреннән ничек котылырга?”, Алма инфарктан саклый”, “Суган-сарымсак кына булышмый”* һ.б. язмалар.

Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләренә игътибар итсәк, язмаларда күбрәк сорау җөмләләр өстенлек ала: “*Статиннар: файдасы күбрәкме, зыянымы?”, “Бәйрәм табыныннан туп-туры хастаханәгә юлыкмас өчен нишләргә?”, “Һава торышының тискәре тәэсиреннән ничек котылырга?!”, “Даруның файдасы тисен өчен, кайчан, ничек эчәргә”* һ.б.

“Ватаным Татарстан” газетасында мәкалә исемнәре структур яктан 2 төрле тәкъдим ителә: гади җөмләләр һәм кушма җөмләләр ярдәмендә. Гади җөмләгә мисаллар: *“Гөмбәле җәй саташтыра”, “Имән себеркесе сөякләрне ныгыта”, “Белгечләр кавынны кемнәргә ашарга ярамаганлыгын әйтте”, “Чәч буявы яман шеш үсешенә йогынты ясый”* һ.б. Кушма җөмләгә мисаллар: *“Кабак – һәр чирдән дәва, куллана белергә генә кирәк”, “Муенга җил бәрсә, нишләргә?”, “Яшьләр белә, картлар шикләнә”, “Гриптан прививка ясатуның файдасы бар: беребез дә авырмый”* һ.б.

Мәкаләләрнең язылу стилен, тел-сурәтләү чараларын, җөмлә төзелешләрен тикшерү өчен, аерым бер язмага күзәтү ясыйк. “*Кыш көне тән тиресен ничек сакларга?”* дигән мәкаләдә косметолог киңәшләре урын алган (30 нчы ноябрь, 2019 нчы ел).

Язмада күбрәк хикәя җөмләләр. Алар косметолог киңәшен гәҗит укучысына җиткерә, чынбарлыкта булган күренешләр, әйберләр турында хәбәр итәләр. Автор тарафыннан сорау һәм тойгылы җөмләләр бик аз кулланылган: сорау җөмлә – бер, тойгылы җөмлә – ике тапкыр. Әлеге күренеш язманың темасына һәм жанрына туры килә, чөнки мәкалә сорау-җавап, интервью форматында түгел һәм эмоциональлеккә корылмаган.

Җөмләдә сүзләрнең гомумхалык телендә тарихи урнашып киткән гадәти тәртибе була һәм ул – сүзләрнең туры тәртибе дип атала. Сүзләр гадәти тәртиптә урнашканда, ия хәбәрдән алда килә. Мәкаләдә кире сүз тәртибенә мисаллар шактый: *“Дымга сусаган чәч төпләренә су сипкәндәй булыр ул”, “Кышкы салкында да иң беренчеләрдән булып корый, ярыла алар”.*

Җөмләләрдә кабатланулар еш күренә. Әлеге күренеш авторның сөйләм байлыгы сай, контекстуаль синонимнар кулланылмавы турында хәбәр итә. *“Бит тиресе майлы булган кешеләр дә майлы кремнар кулланудан курыкмасын! Кыш көне теләсә кайсы бит тиресе шактый гына майлылыгын югалта”.*

Әлеге абзацтагы җөмләләр бер-берсенә чылбырлы бәйләнеш юлы белән бәйләнгән. “Бит” сүзе һәр җөмләдә кабатлана һәм сөйләмдә фикернең эзлекле хәрәкәтен, үсешен чагылдыра.*“Аны юынганнан соң бераз дымлы бит тиресенә сөртү хәерле. Болай эшләгәндә, бит тиресендә өстәмә дымлылык пәйда булачак. Кремны сөрткәндә, битегезне җиңелчә генә чәбәкләп тә алыгыз. Бит кремын урамга чыгарга ким дигәндә 40 минут кала сөртергә кирәген күпләр беләдер инде. Артык җылы бүлмәдә утырганда, бит тиресе корымасын өчен, пульверизатордан су сиптереп алу да комачауламас”.*

Лексик кабатлау ярдәмендә төзелгән жөмләләр фәнни-публицистик стильдә күп кулланыла. Шуның өчен әлеге алым язма стильгә туры килә.

Язманың йомгак өлеше гади сөйләм төренә мисал булып тора: кыска җөмләләрдән гыйбәрәт, "алмаш-тилмәш", "шундук"сүзләре кулланылган. Китерелгән абзац тулаем әдәби тел нормасына туры килми дип фикер йөртергә мөмкин. "*Көн саен чәч юып булмый бит. Күптән түгел җаен таптым мин моның. Бик яхшы рецептка юлыктым. Ике төрле катнашманы алмаш-тилмәш кулланам. Файдасын шундук сиздем".*

**Әдәбият**

1. Ватаным Татарстан. Кыш көне тән тиресен ничек сакларга? [Электронный ресурс]. URL: https://vatantat.ru/2019/11/kysh-k%D3%A9ne-t%D3%99n-tirese-nichek-saklarga-kosmetolog-ki%D2%A3%D3%99she/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 15.01.2019).

2. Мирзаhитов Р.Х., Сәгъдиева Р.К. Хәзерге татар теле: Синтаксис. Лекцияләрнең тулы конспекты. – Казан: Казан федераль университеты, 2013. – 288 б.

## ПРОБЛЕМЫ ПЕРЕКЛЮЧЕНИЯ КОДА ПРИ ОБУЧЕНИИ АНГЛИЙСКОМУ ЯЗЫКУ (татар и русских)

*Зарипова З.Х., КФУ, студент V курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. А.Х. Ашрапова*

При обучении английскому языку больше трудности возникают с говорением и грамматикой английского языка. Одним из главных причин в этом – влияние родного языка. Каждый язык имеет свои особенности, и правило, присущее для одного языка, может быть не подходящим для другого. Это объясняется с несовпадением грамматических систем иностранного и родного языков обучающегося в целом. В грамматике иностранного языка есть феномены, которые в родном языке отсутствуют.

На начальном этапе обучения английскому языку учащиеся часто переходят в родной язык. Эти переходы в лингвистике мы называем кодовые переключения. Это процесс попеременного использования единиц двух языков на естественных границах высказывания. Переключения кода обусловлены рядом причин: либо ребенок не знает перевод какого-нибудь слова или же забывает, либо не знает грамматику. Кодовым переключением может быть любая часть речи, но больше всего встречается имя существительное и имя прилагательное. Переключение кода происходит на естественном потоке речи: это может быть и в начале, и в конце фразы.

Для детей характерно наличие некоего языкового опыта, так как учащиеся, как правило, используют навыки родного языка в рамках явлений иностранного. С одной стороны, уже имеющийся языковой опыт является хорошей основой для изучения второго языка, так как это выступает как комплекс дополнительных временных связей, обогащающих личный опыт учащихся. Данный языковой опыт создает хорошие условия для изучения иностранного языка. Но с другой стороны эти условия должны быть

управляемыми. Имеющийся языковой опыт следует правильно использовать и направлять в положительную сторону, иначе он может оказать негативное влияние, которое может сказаться и на чтении, и на произношении. Поэтому учет специфики русского или татарского языка имеет важное значение в обучении иностранному языку. Так, например, при изучении английского языка возникает интерференция, иначе говоря, перенос навыков из родного языка на изучаемый.

Проблема переключения года при обучении языку всегда остается спорным вопросом. Некоторые будут утверждать, что иностранный язык нужно изучать без учета родного языка, так как это позволит обучающимся вникать в атмосферу изучаемого языка, что ведет за собой активизацию коммуникативной компетенции. Другие же, наоборот, уверены, что постоянное сопоставление двух языков позволяет обучать учащихся более экономно и эффективно, ведь та или иная путь помогает учащимся легко понять материал. Для того, чтобы английский язык действительно стал средством общения, учитель с каждым годом должен стремиться создать одноязычную среду на занятии, т.е. свести использование родного языка к минимуму.

Употребление родного языка на начальном этапе обучения является больше хорошим знаком. Ведь ребенок начинает говорить, так у него развивается коммуникативный навык. На начальном этапе обучения у ребенка маленький словарный запас. Он не может оформить полноценное английское предложение, поэтому он использует только те слова, которые уже укладывались в его голове.

Рассмотрим несколько примеров у русскоговорящих детей:

Ребенок говорит: *«А моя name Маша»* вместо «My name is Masha». На примере видно, что ребенок в своей речи употребляет помимо слов английского языка и русские. Это естественный закономерный этап. Это означает, что у обучаемого еще не сформировалась структура данного предложения.

*«I not watch TV in the afternoon»* вместо «I don’t watch TV in the afternoon». Здесь ребенок переводит предложение с русского языка «Я не смотрю телевизор днем».

*«What you want for your birthday?»* вместо «What do you want for your birthday?» В этом вопросе обучаемый упускает вспомогательный глагол. Это объясняется тем, что в русском языке нет такого вспомогательного глагола. Ребенок составляет английское предложение дословно с русского языка.

Рассмотрим несколько примеров у татароязычных детей:

*«Let’s go theaterга»* вместо «Let’s go to the theater». Здесь мы видим, что ученик забыл предлог to, поэтому он использовал родной, в этом случае татарский язык для объяснения своего намерения. Но не только предлог, он также не употребляет артикль. Неправильное использование артиклей или не употребление их – это типичная ошибка у изучающих иностранного языка.

«It yellow» вместо «It is yellow». Ученик не употребляет форму 3-го лица, так как в татарском языке это предложение состоит только из 2 слов «Ул – сары». Ребенок не хочет понять, зачем нужно употреблять еще одно слово.

«I two cats have» вместо «I have two cats». В данном предложении ребенок допустил ошибку в построении предложения. Он переводил дословно с татарского языка «Минем 2 песием бар», поэтому слово «have» использовал в конце предложения.

На начальном этапе обучения использование в речи родного языка допустимо, так как у ребенка нет необходимого словарного запаса. Ребенок может использовать свой родной язык до того момента, как у него будет базовый запас слов.

Следовательно, с целью повышения эффективности обучения английскому языку необходимо: учитывать влияние родного языка на изучаемый, проводить систематическую работу по учету особенностей родного (русского и татарского) языка в целях преодоления кодовых переключений. При понимании причин использования родного языка, можно избавиться от них. В этом случае все зависит от учителя.

Таким образом, кодовые переключения на начальном этапе обучения английскому языку возможны, так как на начальном этапе полностью исключить использование родного языка невозможно.

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ АУДИОВИЗУАЛЬ ЧАРАЛАР

*Зәйнетдинова Р., КФУ, V курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Ф.Р. Сибгаева*

Дәрестә кулланыла торган иң отышлы заманча технологияләрнең берсе электрон дәреслекләр һәм ярдәмлекләр. Аларны компьютер һәм видеопроектор ярдәмендә эшләп, укучыларга зур күләмдә мәгълүмат бирергә мөмкин, бүгенгесе көндә CD-дискларга яздырылган электрон белешмәләр, “Татар телле заман”, “Мин татарча сөйләшәм” һ.б. компакт-дисклардан файдалану мөмкин. Шулар арасыннан “Сәләт” фонды чыгарган TATAR TELLE ZAMAN электрон дәреслекне аерып әйтергә була. Анда 50 темага 2000 сүз, 2500 рәсем, фотографияләр, 3 төрле дәрәҗәдәге күнегүләр, диалоглар, уеннар тупланган. Татар телен рус телле балаларга укытуда, укучыларның эшчәнлеген активлаштыруда бу чыганаклар укытучылар өчен зур хәзинә. Шулай ук без дәресләрдә Хайдарова Р.З. Галиева Н.Г җитәкчелегендә чыккан “Күңелле татар теле” электрон дәреслекләрен, кушымталарны бик уңышлы кулланабыз. Әлеге дәреслекләр һәм ярдәмлекләрдәге материаллар укучыда тел өйрәнүгә кызыксыну тудыра. Аларның зәвыклы бизәлеше, биремнәр һәм текстларның сәнгатьчә бизәлеше, бизәлештә төсләрне урынлы куллану, тәкъдим ителгән текстларның һәм өзекләрнең балалар өчен кызыклы булуы, яшь үзенчәлекләренә туры килүе, биремнәр һәм сорауларның

укучы башкарып чыга алырлык катлаулылыкта булуы, аудирование өлешләре булу бик тә яхшы.

Татар теле дәресләрендә дә аудиовизуал чараларны куллануның өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек, әлеге технология – шәхескә юнәлтелгән, ныклы һәм вариатив булуы белән аерылып тора. Дәресләрдә аудиовизуаль чаралар куллануның юллары һәм ысуллары күптөрле.

Аудиовизуаль чараларның берсе буларак компьютер куллану татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә күнекмәләр булдыру өчен күнегүләр күләме арта, катлаулылык ягыннан дифференсация барлыкка килә. Моннан тыш мәгълүмати компьютер технологияләрен куллану дәресләрдә уңай эмоциональ фон һәм һәр укучы өчен уңыш ситуациясе барлыкка китерә.

Хәзерге вакытта дәресләрдә мультимедиа чаралары еш кулланыла. Мультимедиа технологияләрен куллану яңалыклар белән кызыксыну теләге уята. Беренчедән, укучыларның белемнәре формалаштырыла, икенчедән, сөйләм һәм мультимедиа чаралары белән эшләү күнекмәләре барлыкка килә. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә мультимедияле уен формасындагы күнегүләр телнең лексикасын, грамматикасын һәм структурасын җиңелрәк үзләштерергә ярдәм итә. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларына электрон уку-укыту ресурсларын, электрон кушымталарны файдалану, телне үстерү һәм саклау, дәрес укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү, дәрес эчтәлеклеген баерак һәм кызыклырак итү өчен зур ярдәмлек булып тора.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә аудиовизуаль чараларны куллануның түбәндәге уңай яклары бар: уку процессы эчтәлегенең индивидуальләшү, күләмле материалның тиз үзләштерелүе; укучыларның танып белү активлыгы үсү; укучыларның психологик мөмкинлекләренең исәпкә алынуы һәм белемнәрнең объектив бәяләнелүе; укытучының эш характеры үзгәрү.

Татар теле укытучыларына укыту-тәрбия процессында куллану өчен интернет белем чыганаклары да ярдәмгә килә: http://belem.ru/ сайты – татар телендә белем бирүче укытучылар өчен зур ярдәм. http://www.rusedu.ru/, http://metodisty.ru, http://nsportal.ru/ төрле презентацияләрне шул сайтлардан алырга була; http://www.openclass.ru/node/224468 сайтында кроссвордлар. http://ggulnaz.jimdo.com/, http://ras2203.narod.ru/ – татарча мультфильмнар, спектакльләр алырга мөмкин.

«АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбендә бирелгән күнегүләр дә укытучылар тарафыннан яратып кулланыла. “Ана теле” проекты 2013 елның 1 гыйнварыннан эшләп килә. Әлеге проект ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов кушуы буенча Мәгариф һәм фән министрлыгы белән EF (Education First) компаниясе тарафыннан гамәлгә куелды. Анда берьюлы 10 000 кеше теркәлеп,

бер ел дәвамында татар телен түләүсез өйрәнә ала. Шушы вакыт эчендә башлангыч дәрәҗәдән югары дәрәҗәгә барып җитеп була. Онлайн-мәктәпнең төп максаты – татар телен шәхесара һәм мәдәниятара аралашу чарасы буларак өйрәтү, тел өйрәнүчеләрнең сөйләм осталыгын үстерү. Мәктәпкә теркәлгән һәр кеше көндәлек тормышта аңлашу-аралашу күнекмәләренә ия була, шулай ук татар дөньясы турында кызыклы мәгълүмат та ала.

Аудиовизуаль чараларның бер төре буларак мультимедиа чаралары белән эшләү дәрес формаларын төрләндерү мөмкинчелеге бирә һәм аны дәреснең төрле этапларында кулланырга була: проблемалы ситуация тудыру өчен; яңа материалны аңлату өчен; өй эшен тикшерү өчен; дәрес барышында белемнәрен тикшерү өчен.

Видео-аудио һәм текст материалын берләштерү теманы комплекслы ачарга, аны иҗади кабул итәргә, укучыларның активлыгын күтәрергә булыша. Дәресләрдә мәгълүмати-компьютер технологияләрнең төрле формаларын куллану, югарыда ассызыклап кителгәнчә, укучыларның белемнәрен тирәнәйтә, күззаллауларын үстерә. Предмет буенча өлгерешләрен арттыра. Мөстәкыйль эшләргә өйрәтә. Үз уңышларын күреп, сөенү, куану хисләрен тудыра. Әгәр укытучы үзе үзләштергән методлар, алымнар белән генә эшләсә, аның хезмәте бик чикләнгән булыр иде. Андый укытучы белем бирүдә югары нәтиҗәләргә ирешүдән генә туктап калмый, ә шәхес буларак та үсүдән туктый. Шулай итеп инновацион эшләү педагогның информацион культурасы үсүенең төп чыганагына әверелә.

**Литература**

1. Фәтхуллова К.С. Туган телләрне заманча укыту // Совершенствование методики обучения языкам: площадка обмена прогрессивной практикой: материалы III Международного научно-методического онлайн-семинара. – Казань: Изд. Каз. ун-та, 2019. – С. 442–445.

2. Фатхуллова К.С. Интерактивные средства обучения татарскому языку // И.А.Бодуэн де Куртенэ и мировая лингвистика. – Казань: Изд. Казан.унив., 2019. – С. 229–232.

## ФОРМИРОВАНИЕ РЕЧЕВЫХ КОМПЕТЕНЦИЙ НА ИНОСТРАННОМ ЯЗЫКЕ

*Зиннурова Э., КФУ, студент V курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. А.Х. Ашрапова*

Формирование речевых компетенций на иностранном языке представляет собой обучение говорению как виду речевой деятельности. Содержанием говорения является выражение мыслей в устной форме. При говорении возникает сложная мыслительная деятельность с опорой на речевой слух, память, прогнозирование и внимание. В зависимости от степени участия мышления и памяти, говорение может обладать различной сложностью: от отдельных слов и коротких фраз, употребляющихся для выражения ответной реакции, до использования развернутых высказываний, выражающих самостоятельную идею. Самой совершенной речью считают речь инициативную [3: 45, 47].

Формирование речи обусловлено следующими этапами речевых действий:

1) планирование (мысленно строится скелет высказывания, отбирается нужная информация и отсеивается второстепенная);

2) формулировка текста (строится синтаксическая структура предложения, отбирается правильный лексический материал);

3) артикуляция текста (воспроизведение речи);

4) самоконтроль (производится моментный контроль правильности своего высказывания как грамматически, так и по смыслу, который выявляется после ответной реплики собеседника).

Эти этапы тесно взаимодействуют между собой, могут перекрывать друг друга и повторяться во время разговора. Каждый из этапов выполняет определенные функции, и при правильной организации способствует достижению коммуникативных целей говорящего. Результат говорения проявляется в ответной реакции слушающего и реализуется в его практической деятельности.

Для обучения говорению используются следующие технологии:

• **речевая ситуация** – создание реальной жизненной ситуации в пределах учебной аудитории (в магазине игрушек, экскурсия в Лондоне и т.п.);

• **технология когнитивного диссонанса** – создание неожиданной картины мира, противоречащая ожиданиям аудитории, вызов у аудитории широкого спектра реакций (обсуждение снимка черной дыры, обсуждение массового убийства дельфинов в Китае и т.п.);

• **технология информационного неравенства** – работа с недостающей информацией, которая восполняется путем обмена материала с другими участниками;

• **технология логического тупика** – столкновение мыслей с препятствием в форме аргументации, обсуждение вопросов, не имеющих ответа (переселение в другие планеты, построение пирамид Египта и т.п.).

Общеевропейская система определения уровней владения иностранным языком (CEFR) подразумевает осуществление речевой деятельности человека в различных сферах общения, которые там представлены как общественная, личная, образовательная и профессиональная. А формирование навыков говорения осуществляется через обучение следующим формам: монологу и диалогу.

Диалог – разговор двух лиц, высказывания которых образуют реплики диалога. Диалогическая речь считается успешной лишь тогда, когда реплики в совокупности формируют единое тематическое целое. Особенность диалога – его краткость, спонтанность и экспрессивность. Поэтому для обучения диалогической речи особо успешными методами являются методы, основанные на ролевой игре. К таким относятся: *сюжетно-ролевая игра; интервью; дискуссия; драматизация; дебаты; круглый стол.*

Монолог – выступление одного лица, обращенного к публике. Главная цель говорящего в монологе – воздействие на эмоции и чувства слушающих или информирование слушателей. Обучение монологу требует, прежде всего, овладение лексико-грамматическими структурами языка. Более того для корректного изложения своей мысли говорящий должен обладать правильной интонацией, уметь эмоционально окрашивать свою речь и использовать невербальные средства – все это в комбинации приведет к созданию единого смыслового текста.

Обучение монологической речи, как правило, начинают с овладения приемами описания. Объектами описания могут являться окружающие предметы (аудитория, квартира, город, портрет человека и т.п.). Следующим этапом развития навыков монологической речи является обучение повествованию и постепенно добавляется обучение говорящего рассуждать об актуальных темах и проблемах, исходя из собственного жизненного опыта. Поэтому при обучении монологу очень важно учитывать возрастные особенности обучающегося. Популярными методами обучения монологу являются: *приветственная речь*; *описание ситуации; описание картины; пересказ текста; ответ на вопросы по прочитанному тексту; выступление в форме доклада; характеристика* и т.п.

Международная система оценивания знаний CEFR предполагает оценку речевых умений по следующим критериям: *диапазон, точность, беглость, взаимодействие, связность*. Каждый критерий имеет свои дескрипторы на все шесть уровней владения языком. При обучении говорению необходимо с самого начального этапа обучения (A1) базироваться на данных критериях.

При этом важно применять нетрадиционные, новые методы обучения, способствующие развитию зоны ближайшего развития ребенка. К таким можно отнести следующие методы: *проектный метод, деловая игра, мозговой штурм, круглый стол, игровая методика и коммуникативный метод*.

Таким образом, говорение является важнейшим аспектом при изучении иностранного языка, позволяющий свободно осуществлять общение на изучаемом языке, поэтому формирование речевых навыков требует стабильной и тщательной работы, раскрывающие все аспекты и соответствующие всем критериям оценивания говорения.

**Литература**

1. Common European Framework of Reference for Languages Learning, Teaching, Assessment. – Strasbourg, 1986.

2. Пассов Е. И. Основы коммуникативного метода обучения иноязычному общению. – М., 1989.

3. Kainz F. Psychologie der Sprache / F. Kainz. – Bd. 3, Stuttgart, 1951.

# ТАТАР ПАРЕМИЯЛӘРЕНЕҢ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИК ПОТЕНЦИАЛЫ

*Ибраһимова А., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Ф.Х. Габдрахманова*

Хәзерге вакытта глобализация и интеграция дөнья масштабында бара торган көчле процесслар буларак танылалар һәм, бер яктан, чит мәдәниятләргә, этнографик үзенчәлекләргә карата кызыксыну уянуга алшарт булып торсалар, икенче яктан, капма-каршы процесс – милли үзаң, милли үзенчәлекләрне саклп калу омтылышына сәбәп булып киләләр. Билгеле булганча, мәкальләр һәм әйтемнәр халыкның дөньяны күзаллавын, көнкүреш үзенчәлекләрен калку гәүдәләндерәләр, бүгенге көндә күп кенә паремиологлар мәкальләр – дөнья тел картинасының фргаментын тәшкил итәләр, дигән фикердә торалар. Әлеге эшебездә без, паремия дигәндә, “ситуацияләрнең яки реалияләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең маркерлары булган ябык һәм тотрыклы фразалар”ны күздә тотабыз [1: 112]. Паремияләр рәтендә әлеге эштә без мәкаль һәм әйтемнәр, кайбер фразеологик берәмлекләрне тикшерәбез. Мәкаль дип, телдән-телгә күчеп йөрүче, халыкның зур тормыш тәҗрибәсен туплаган дидактик эчтәлекле, кыска һәм образлы сөйләмнәргә әйтәләр. Хәзерге телебездә актив кулланылган йөзләрчә мәкальләрнең VIII – X гасыр истәлеге булган бик борынгы төрки язма чыганакларда теркәлгән булуы аларның күп гасырлар элек тууын күрсәтә. Мәкаль кебек үк, әйтем дә тотрыклы текстка ия, сөйләмнең эмоциональ көчен арттыру өчен хезмәт итә. Мәкальләрдән аермалы буларак, әйтемнәрдә фәлсәфи-дидактик хөкем чыгару, нәсихәт-киңәш бирү функциясе дә юк. Фразеологик берәмлек дигәндә исә, чынбарлыктагы күренешләрне тәэсирле, сурәтле һәм сәнгатьле итеп чагылдыручы, семантик һәм синтаксик яктан таркалмый торган тотрыклы сүз тезмәсен күздә тотабыз. И. Горбань язуынча, “паремияләр, менталь репрезентациянең бер формасы буларак, үзендә кешенең үзен һәм чынбарлыкны кабул итүенең нәтиҗәсен туплый” [1: 174]. Шуңа күрә алар эшебез темасы контекстында гаҗәеп бай материал булып торалар. Паремияләрнең үзенчәлекләре шунда: алар укучыга (тыңлаучыга) үзенчәлекле тәэсир итәләр: алар яңа мәгълүмат бирә алалар, бәялиләр, эмоциональ һәм прагматик мөнәсәбәтне белдерәләр, ситуацияне тавирлап бирә алалар. Р.С. Аликаев һәм С.К. Башиева паремияләрнең бер төре булган фразеологик берәмлекләрне этноспецифик мәгълүматны тапшыручы берәмлекләр буларак тикшерәләр. М.Л. Ковшованың диссертацион хезмәтендә фразеологизмнар семантик һәм прагматик яктан тәфсиле өйрәнеләләр, хезмәтнең авторы мондый нәтиҗәгә килә: фразеологизмнарга тел мәгънәсе генә түгел, мәдәни коннотация дә хас. Мондый үзенчәлекләр татар галмнәре тарафыннан да

ассызыклана. Р.Р. Җамалетдинов әйтүенчә, “фразеологизмнар яралганда һәм тел системасында ныгып урнашканда ук, милли-мәдәни стереотиплар һәм эталоннар катнаша” [1: 123]. Тарихи яктан фразеологизмнар чынбарлыкны турыдан-туры чагылдырганнар. Фразеологизмның реаль прототибы әкренләп онытылган, югалган, сүзтезмәләрнең мәгънәсе үзгәргән, һәм алар билгеле бер типик ситуациянең тамгасы буларак кына сакланып калганнар. Мәсәлән, “*акчага чукынган*” фразеологик берәмлеге турында галимнәр түбәндәге мәгълүмат җиткерәләр: “XVII – XVIII йөзләрдә патша хөкүмәте чукынган татарга мул гына акча түли, чукынмаганның җир-суын тартып алып, чукынганга бирә, үзен солдат итә, лашман итә” [2: 238].

Нәтиҗә ясап, шуны ассызыклау әһәмиятле: паремияләр телдәге тамгаларның милли-мәдәни семантикасы, халкыбызның мәдәнияте, гореф-гадәтләре турында күбрәк мәгълүмат алырга мөмкинлек бирә, аларның эчке формасында милли-мәдәни коннотация ачык чагылыш таба. Болар барысы да лингвокультурологик юнәлештә язылган хезмәтләрнең паремияләргә (мәкальләргә, әйтемнәргә, клише, фразеологизмнарга) карата булган тирән кызыксынуын аңлата.

**Әдәбият**

1. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.

2. Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш: Югары уку йорларының филология факультеты студентлары өчен дәреслек – Казан: ТаРих, 2001. – 383 б.

## ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ НӘЗАРИ ТӨШЕНЧӘЛӘРНЕ ӨЙРӘНҮ

*Ибраһимова Д., КФУ, V курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Л.Ф. Җамалиева*

Әдәбият белеме күп еллар дәвамында бик зур үзгәрешләр кичерә. Билгеле булганча, әлеге үзгәрешләр әдәбият укыту методикасында да үз эзен калдыралар. Мәктәптәге әдәбият курсы кысаларында өйрәнелә торган нәзари төшенчәләрне 4 блокка бүлеп карыйлар:

1. Тарихи-әдәби процесс белән бәйле булган нәзари төшенчәләр;
2. Әдәби әсәргә анализ ясау белән бәйле булган нәзари төшенчәләр;
3. Тедән һәм язма сөйләм үсеше белн бәйле булган төшенчәләр;
4. Этик, эстетик, философик һәм дини категорияләр.

Филолог, сәнгать тарихчысы Ф.И. Буслаев – рус теле һәм әдәбиятын укытуның методикасына фәнни нигез салучы. Методика фәненә карашлары аның «О преподавании отечественного языка» (1844) хезмәтендә урын тапкан. Әдәби әсәрне өйрәнү индукция методына нигезләнә: классик әдәби әсәр мөстәкыйль укыла һәм аңа филологик анализ ясала. «Филологик анализ, үз чиратында, теоретик төшенчәләрне

өйрәнүгә нигез була. Алар язмача күнегү башкарганда үзләштерелә (тәрҗемә, инша, реферат һ.б.)» [2: 29].

Нигездә, күп гасырлар дәвамында әдәбият дәресендә әдәби әсәрне идея-сәнгати яктан тикшерүгә өстенлек бирелә. Мисал өчен, В.И. Водовозов әдәби әсәрне өйрәнгәндә филологик анализны бөтенләй кире кага. Аның фикеренчә, әдәбиятны укучылар «реаль» күзалларга тиешләр, ягъни әдәби әсәргә реаль чынбарлыктан һәм анда чагылган чорның проблемаларыннан чыгып бәя бирелә. Ләкин теге яки бу әсәргә бәя биргәндә, «фәнни фикер формалаштырыр өчен укучы конкрет теоретик материал белән эш итә һәм тиешле нәзари төшенчәне куллана белергә тиеш» [1: 89].

XX гасырда әдәбиятны өйрәтү методикасы яңа дәвергә аяк баса, һәм күпмедер күләмдә нәзари төшенчәләрне өйрәтүгә дә игътибар юнәлтелә. «XX гасырның 20 нче елларында совет методикасында сорау методы, лаборатор метод, лаборатор һәм хезмәт методы терминнары киң таралыш ала» [3: 15].

Нигездә, алар бер үк мәгънәгә ия була һәм укучының сораулар ярдәмендә әдәби текст өстендә эшләүне күз алдында тота. Лаборатор методның төп кимчелеге язма характерда булуы. Ләкин әлеге метод белән укытканда, укыту процессыннан җанлы сөйләмне кысрыклап чыгара.

Бүген дәүләтебез тарафыннан телне укыту һәм яклау буенча законнар кабул ителгән. Ул законнарны тормышка ашыру максатыннан министрлык тарафыннан мәктәпләр өчен уку планнары эшләнгән һәм ул уку планнарында туган телләрне укыту дигән өлеш бар. Әдәби әсәрләрне уку гына балаларны эрудиция ягыннан үстерергә сәләтле түгел. Укучыларга, һичшиксез, әдәбият дәресләрендә фәнни белем дә бирелергә, аларда әдәбият теориясе буенча нигез белемнәр формалашырга тиеш.

Элегрәк укытучы яңа теманы бик матур итеп сөйли, ә укучы бары гади үзләштерүче ролен үти иде: бүген исә, укучы яңа теманы үзе эзләүче, тикшеренүче сыйфатында үзләштерергә тиеш дип карала. Хәзерге шартларда, мәгълүматның күләме тиз үскән вакытта, кирәген сайлап ала белергә, тәртипкә китерергә, кечкенә генә ачыш ясап куана белергә өйрәтү, юл күрсәтү – уку-укыту өчен авыр эш. Укучы теманы уйлап, фикерләп, эзләнеп аңлый икән, әлбәттә, аның белеме ныклырак, төплерәк була.

Мәктәптәге традицион, бер төрле үткәрелгән дәресләр арасында, гадәти булмаган дәресләр үткәрү укучыларның хәтерендә ныграк кала. Ялкыткыч эш төрләрен һәр дәрестә кат-кат башкаруга караганда кызыклы ачышлар булганы укучының күңеленә тәэсир итә, аң-белемен киңәйтә, иҗади эзләнүгә теләк тудыра. Шуңа да соңгы вакытта укучының белем сыйфатын күтәрүдә, иҗади сәләтләрен үстерүдә яңа технологияләрне өйрәнү һәм дәрестә куллану турында күп сөйләнелә, языла.

Шуңа күрә, заман таләпләре буенча, укучыларны булдырган кадәр максималь дәрәҗәдә дәрес материалы белән кызыксындыру һәм аларны үзләштерүне тәэмин итү максаты куела. Соңгы унъеллыкта җәмгыятебездә барган үзгәрешләр белем бирү системасын да читләтеп үтмәде. Укучыга булган мөнәсәбәт белән бергә, укытуның эчтәлеге дә үзгәрергә тиеш. Мәктәпләрдә, белем бирүнең традицион формалары белән беррәттән, укытуның сыйфатын сизелерлек дәрәҗәдә күтәрүче яңа (инновацион) технологияләр дә уңышлы файдаланыла. Укытучы яңадан яңа технологияләр, эш алымнары булдыру өстендә эш алып барырга тиеш була. Заманча технологияләрнең түбәндәге төрләрен күрсәтеп була: шәхескә юнәлтелгән технологияләр, уен технологиясе, проблемалы укыту, белем бирүнең компьютер технологияләре, интенсив белем бирү технологиясе.

Шулай ук дәресләрдә Интернет ресурсларны куллану гаять зур мөмкинлекләр бирә. Интернет челтәре укучыга һәм укытучыга кирәкле мәгълүматны җир шарының төрле ноктасыннан эзләп табу шартларын тудыра.

Белем бирүдә заманча технологияләрне куллану ул – әхлаклы кеше тәрбияләү, педагогик технологияләр булдыруда фәннең роле арту, өйрәнгәнне тормышта куллана белү һәм башкалар. Инновацион технология буенча татар әдәбиятына өйрәтү – уку-укыту процессын яңача оештыруны аңлата. Бу вакытта укыту процессы төп нәтиҗәгә – укучының актив коммуникатив эшчәнлеккә омтылуын алдан сизүгә, баланың хисси һәм интелектуаль мөмкинлекләрен файдаланып аралашуга юнәлтелә.

**Әдәбият**


1. Закирҗанов Ә.М. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре: Укытучылар өчен методик кулланма. – Казан: Мастер Лайн, 1997.
2. Коханова В.А. Технологии и теория обучения литературе: учеб. пособие / под.ред В.А. Кохановой. – М: ФЛИНТА: Наука, 2011. – С.11–32.
3. Романичева Е.С., Сосновская И.В. Введение в методику обучения литературе: учеб. пособие. – М.: ФЛИНТА: Наука, 2012. – С.14–34.


## РАБИТ БАТУЛЛА ИҖАТЫНДА ТУКАЙ ОБРАЗЫ


*Ибраһимова Р., Яр Чаллы педагогия көллияте, IV курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд. Р.Ә. Миңнаҗева*


Яшәеше һәм иҗаты белән үз халкының тарихында «игү ат» калдырган шәхесләр бар. Халкыбызның күпкырлы шәхесе Габдулла Тукайның тормыш сәхифәләре, иҗат мирасы – төрки халыкларның уртак хәзинәсе, горурлыгы. Әдәбиятның барлык жанрларында да диярлек каләмен тибрәткән Г. Тукай халык күңелен иң әүвәл милләтпәрвәрлеге, азатлыкка омтылышы, халык идеалларын чагылдыруы белән яулый.

Халык мәнфәгатьләрен яклаган Тукай образы әдәбиятта үзәк темаларның берсе булып кала бирә. Билгеле, чорның иҗтимагый-сәяси вәзгыятенә, әдәби барышына бәйле рәвештә, һәр каләм иясе Тукай шәхесен ачуга үзенчә якын килә.

Бүгенге көндә Габдулла Тукай иҗатын һәрьяклап өйрәнүче замандашыбыз − Рабит Батулла. Аның Г.Тукайга багышланган беренче күләмле әсәре – «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» (1995) кыйссасы. Соңрак ул аңа нигезләнеп «Сират күпере» драмасын иҗат итә, ә инде XXI гасырга чыккач, «Күк капусы ачылганда могҗиза», «Зәйтүнәкәй» пьесаларын, «Тукай − Апуш» повестьларын яза.

«Кылдан нечкә, кылычтан үткен» [2] повестенда автор Г.Тукай тормышының соңгы көннәрен яктырта. Повестьта Г.Тукай образы дуслары Ф.Әмирхан, Х.Ямашев, С.Рәмиев һ.б; хатын-кызлардан Зәйтүнә туташ һәм Гәүһәршад ханымнарга мөнәсәбәттә; Шәүлә кебек дошманнарына каршы көрәштә ачыла төшә. Әсәрнең беренче битләреннән үк без Тукайның якын дуслары белән танышабыз. Габдуллаҗанның хәлен белергә беренчеләрдән булып килгән дусты − Хөсәен Ямаш. Ул да «революция» дип янып йөрүче, татар халкы өчен ихластан кайгыручы ил каһарманы. Полиция тарафыннан эзәрлекләнсә дә, беренчеләрдән булып авыру дусты Тукайның хәлен белергә килгән.

Тукайның янәшәсендә генә яшәүче дусты − Фатих Әмирхан. Ул шагыйрьнең кайгысын да, шатлыгын да уртаклашучы, аның киләсе көненә үзенчә көч бирүче. Соңрак, без Тукайның сагышлы Бикчура һәм серле Сәгыйть Рәми исемле дуслары белән танышабыз. Аларның барысын да Габдуллаҗанның авыру хәбәре Болгар кунакханәсенә дәшкән.

Югарыда әйтеп узган образ-персонажлар мөһим вазыйфа башкарып киләләр: шагыйрьнең милләт язмышында нинди роль уйнавын, аның дөньяга карашын гәүдәләндерергә булышалар. Тукайның алгы көннәренең санаулы һәм караңгы икәнен ишарәләп шом салучы – «ике башлы зур Каракош» образы. Каракош гадәттә Тукайның төшләрендә пәйда була.

Кешеләргә һөҗүм итүче ике башлы зур Каракош – инсаннарның иреген чикләүче буларак үлем белән янәшә куелган. Ул әсәрдә Тукайга берничә тапкыр янаячак. Шагыйрь: «Канатларын җәя каракош. Каплый дөньяны каракош», дип авыр сулап куйса, икенче бер тапкыр, ул үзенең терелә алмаслык авыру икәнен белгәнгә күрә, Зәйтүнәсенең мәхәббәтен кире кагарга мәҗбүр. Гомеренең үлем белән очлануын Тукайның төше аша да абайлап алабыз: анда, шагыйрь аландагы чәчәкләрне сөйгәненә җыеп, бүләк итәргә генә тели, каяндыр ике башлы каракош килеп чыгып, канатлары белән давыл чыгарып, сәйләннәрне коеп төшерә. Әйе, алдан күрүчәнлек, пәйгамбәрлек сәләте Тукайга сөйгәненең хисләрен кире кактыра, «мин сезне сөймим» дип ялганларга мәҗбүр итә. Бу ике гашыйкның өзгәләнүләрен, мәхәббәт газапларында януларын күрү укучыны тетрәндерергә мәҗбүр итә.

Тукайны әдип горур һәм туры сүзле итеп тасвирлый. Рабит Батулла Зәйтүнә туташ һәм бай хатыны Гәүһәршад ханым образлары ярдәмендә

Тукайны XX йөз башы хатын-кызларына мәгърифәт нуры чәчүче, милли үзаң хисләре бүләк итүче, рухи дөньяларын баетучы идеал каһарман икәнен күрсәтә. Тукай әлеге әсәрдә милләт өчен җан атучы гына итеп түгел, ә һәр кешегә хас мәхәббәт утында янган гашыйк буларак та сурәтләнә. Аның күңелен яулап алган, мәхәббәт шигырьләренең алиһәсе – ул Зәйтүнә туташ. Аларның үзара серләшүләре, бер-берсенә булган хисләрне чәчәк аша аңлатулары – алар арасында искиткеч олы һәм чиста мәхәббәт булуын раслый.

Повестьта Тукай дошманнарының иң хәйләкәре, иң куркынычы, мөгаен, Шәүләдер. Шагыйрьнең Шәүлә белән конфликты аерата калкулаштырып бирелгән. Вакыйгалар барышында Шәүлә образы, полиция шымчысына хас булганча, төрле образларга керә. Аның багучыга әверелеп, Тукайга мәхәббәт килүен юраганда, аны Тукайга теләктәшлек белдерүче дусты дип тә уйлап куясың. Әмма ул үз тозагына Тукайның дусларын бер-бер артлы эләктереп, юк итеп торучы, Тукай әймешли, «революцияне буучы палач» булып чыга. Шәүлә патша жандармериясенең астыртынлыгын, мәрхәмәтсезлеген, икейөзлелеген һәм акыл көчен гәүдәләндерә. Әмма әсәрдә Тукай Шәүләне үзенә илтифатлык күрсәтергә, хөрмәт белән карарга мәҗбүр итә. Тукай белән тартышыында ул рухи яктан җиңелә төшә һәм үзенең җиңелүен хәтта танырга мәҗбүр була. Шул сәбәпле, повесть финалында Тукайның физик үлеме рухи үлемсезлек, халык күңелендәге мәңгелелеге белән алышына.

Шулай итеп, Рабит Батулла Г. Тукайның соңгы көннәренә мөрәҗәгать итеп, тарихи һәм биографик фактларга нигезләнеп, сәнгати-эстетик яктан укучыга олугъ шәхес тормышының сәхифәләрен үзенчәлекле итеп тасвирлап бирә алган. Гомумән, Р. Батулла иҗат дәверендә Тукай темасына тугрылыклы булып кала. Әсәрдән әсәргә Тукай образын тирәнрәк һәм төрлерәк яктыртуга ирешә.

**Әдәбият**


1. Әхмәдуллин А.Г. Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе: Монография. – Казан: Мәгариф, 2007. – 223 б.
2. Батулла Р. Кылдан нечкә, кылычтан үткен: Кыйсса. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1996. – 143 б.


## КАБАТЛАУЛЫ ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ ЭМОЦИОНАЛЬ-ЭКСПРЕССИВ МӘГЪНӘЛӘРЕ


*Ибраһимова Э., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Г.Р. Галиуллина*


Хәзерге татар телендә эш-хәл үтәүнең төрле төсмерләрен тапшыруда редупликация юлы белән барлыкка килгән фигыльләр куллану отышлы алым булып тора. Редупликация – төп сүзне кабатлап әйтеп, грамматик мәгънә һәм сүз ясаудан гыйбарәт фономорфологик күренеш (мәс., кызыл-кызыл, бара-бара) [5: 139].

Фигыль формаларының кабатлануын башка аналитик сүзләрдән аерырга кирәк. Әгәр соңгылары ике төрле сүз кушылмасыннан алынган берәмлекләр булса, редупликация бер үк фигыль нигезенең кабатлануын үз эченә ала.

Кабатлаулы фигыльләр хәзерге татар телендә тарихи планда барлыкка килгән модельләр буенча башкарыла. Галимнәр күрсәткәнчә, татар телендә кабатлаулы фигыльләрнең түбәндәге төркемнәрен аерып чыгарырга мөмкин:

1. *-а, -ә, -ый, -и* кушымчаларына тәмамланган кабатлаулы фигыльләр (*бара-бара, укый-укый*);

2. *-ып, -еп, -п* кушымчаларына тәмамланган кабатлаулы фигыльләр (*сузып-сузып, сугып-сугып*);

3. затланышлы фигыльләрнең кабатлануы (*ага да ага*);

4. киләчәк заманның уңай һәм тискәре аспектында асиндетик чагыштыру (*ашар-ашамас*) [3: 55].

Фигыль формаларының кабатлануы эш-хәл үтәүнең характерын үзгәртә, аның дәрәҗәсен белдерә. А.Т. Кайдаров фикеренчә, «аларның ясалуы, барыннан да элек, фикернең төрле стилистик төсмерләрен тапшыру, сөйләмгә аерым экспрессивлык, эмоцияләр бирү, хәрәкәтнең интенсивлыгын чагылдыру, сыйфатны көчәйтү максатларында барлыкка килә» [4: 56]. Нигездә бу кабатлауның әһәмиятен билгеләү дөрес булса да, төгәл түгел, дип искәртә Ф.Ә. Ганиев. Аның фикеренчә, стилистик төсмерләр кабатлаулы фигыльләрдә икенчел, алар өчен иң мөһиме – эш-хәл үтәүнең характерын, аның озынлыгын, интенсивлыгын һ. б. чагылышын күрсәтү, һәм алар бары тик шуннан гына контекстка бәйле рәвештә теге яки бу стилистик буяуларга ия була алалар [2: 160-161].

Ф.Г. Галләмов фикеренчә, морфологик күренеш буларак, фигыльләр редупликациясе озынлыкны (*сөйләшә-сөйләшә* бару, *бара-бара* сөйләү), шулай ук кабатлануны (бала *егыла-егыла* егылмаска өйрәнер, *таеп-таеп* китү) белдерәләр. Синтаксик күренеш буларак фигыльләр редупликациясе *да/дә/та/тә* кисәкчәсе белән интенсивлыкны (бүрене *кыйнаган да кыйнаган*) һәм озынлыкны (*бардым да бардым, утырырга да утырырга*) белдерәләр, дип саный [1: 220].

Редупликация күренеше татар теленең төрле катламнарына киң таралыш тапкан. Без сөйләм теле үрнәкләре тупланган аудиоязмаларыбызны анализлап, сүзләр кабатланып килү очракларында күзәтелгән түбәндәге кабатлаулы фигыльләрнең эмоциональ-экспрессив үзенчәлекләрен аердык:

1. Кабатлаулы фигыль төркемнәренең берсе – *-а, -ә, -ый, -и* кушымчаларына тәмамланган кабатлаулы фигыльләр. Бу төр фигыльләр

татар сөйләм телендә төрле мәгънә белдереп киләләр. Шуларның киң таралыш тапканнарына тукталабыз:

а) дәвамлылыкны белдерү: *Берзаманны* ***тарта-тарта*** *яр кырыена кадәр китердем (сөйләм теленнән). Шул никах көнне яшьләр безнең әйткәннәрне* ***тыңлый-тыңлый*** *кич буе утырдылар, менә шулай булды ул (сөйләм теленнән).* Әлеге мисалларда ***тарта-тарта***, ***тыңлый-тыңлый*** кебек фигыльләр кабатланып килеп, эш-хәлнең, процессның бер тапкыр булу белән генә бетми-тукталмый торганлыкны, ягъни дәвамлылыкны белдерәләр.

ә) кабатлануны белдерү: *Шуннан аяк белән капшап, куллар белән, аяклар белән* ***тибә-тибә***, *бәрәңге, калган бәрәңге юк микән дип* ***карый-карый***, ***җыя-җыя***, *җыеп үзебезнең өйдәге мал-туарлар өчен, ни инде, ризык була алар өчен (сөйләм теленнән).* Мисалларда кабатлаулы фигыльләр бер үк эш-хәлнең, процессның кабатлануын, бер эшне нәкъ шул рәвештә икенче тапкыр яисә күпкә артык башкаруын күрсәтәләр.

2. Кабатлаулы фигыль төркемнәренең икенчесе – *-ып, -еп, -п* кушымчаларына тәмамланган кабатлаулы фигыльләр. Бу төр фигыльләр татар сөйләм телендә эшнең кабатланып килүен белдерәләр, мәсәлән, *Киенергә инде әниләр Казанга барып, шуннан инде саткан әйберләрне* ***җыеп-җыеп***, *алып кайтып үзләре дә, безгә дә шулай киендереп җөрделәр (сөйләм теленнән).* ***Эзләп-эзләп*** *булса да инде, әчкә үлгән балалар булмады безнең семьяда (сөйләм теленнән).* Бирелгән мисалларда редупликация юлы белән барлыкка килгән фигыльләр эш-хәлнең, процессның берничә кат эшләнүен күрсәтү өчен кулланылалар.

3. Редупликация юлы белән барлыкка килгән затланышлы фигыльләр дәвамлылык, даимилек яки кабатлануны белдерәләр: ***Катнаша-катнаша***, *бигрәк тә балалар һәм яшьләр инде (сөйләм теленнән). Ул вакытта күршеләр безгә* ***сөйләп тордылар-тордылар*** *да, үз өйләренә киткәннәр иделәр (сөйләм теленнән).* Әлеге мисалларда кабатлаулы фигыльләр озак дәверле процессның бер башкару белән чикләнмәвен, һәрвакыттагыча үзгәрешсез даими эшләнүен белдерәләр.

4. Киләчәк заманның уңай һәм тискәре аспектында асиндетик, ягъни теркәгечсез чагыштыру юлы белән барлыкка килгән кабатлаулар эш-хәл үтәүнең аз дәрәҗәсен күрсәтәләр: ***Ашар-ашамас*** *кешегә ризык әзерләү юк иде инде, ашаса гына шул (сөйләм теленнән). Алар инде* ***килер-килмәс*** *борын безгә сүз әйтми торганнар иде инде, әйтсәләр, каты түгел, төрттереп кенә (сөйләм теленнән).* Әлеге мисалларда ***ашар-ашамас***, ***килер-килмәс*** кебек фигыльләр кабатланып килеп, эш-хәлнең, процессның аз дәрәҗәдә үтәлүен чагылдыру өчен кулланылалар.

Шулай итеп, редупликация юлы белән барлыкка килгән фигыльләр эш-хәлгә, процесска теге яки бу эмоциональ төсмер бирү өчен дә,

эмоциональ-экспрессив лексика булдыру ысулы буларак та файдалана алалар. Кабатлаулы фигыльләр эш-хәл үтәүнең характерын, аның озынлыгын, кабатлануын, даимилеген, аз дәрәҗәдә үтәлүен һ. б. чагылышын күрсәтәләр. Алар төрле эмоциональ-экспрессив мәгънәләр белдереп, сөйләүченең эмоциональ һәм киеренке халәтенең күрсәткечләре булып, аның чынбарлыкка мөнәсәбәтен ачыклыйлар. Татар телендә әлеге борынгы күренеш озак еллар дәвамында өйрәнелеп килгән, әмма хәзерге татар теленең редупликация күренешенең төрләре һәм типлары алга таба тикшерүләрне таләп итә.

**Әдәбият**


1. Галлямов Ф.Г. Повторы и однородные члены предложения / Наука, образование, общество: Филологические науки. – 2016. – №1(7). – С. 216-223.
2. Ганиев Ф.А. Видовая характеристика глаголов татарского языка. – Казань: Татар. кн. изд–во, 1963. – 180 с.
3. Ганиев Ф.А. Вопросы морфологии татарского языка. – Казань, Татар. кн. изд-во, 1980. – 81 с.
4. Кайдаров А.Т. Парные слова в современном уйгурском языке. – Алма-Ата: Изд-во АН Каз. ССР, 1958. – 168 с.
5. Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – 248 с.


## БАШКОРТОСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ШАРАН РАЙОНЫ КҮГӘРЧЕН-БҮЛӘК АВЫЛЫ ТОПОНИМИКАСЫ


*Исламгареева Г., М. Акмулла ис. БДПУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. И.С. Насипов*


Билгеле бер төбәкнең яисә торак пунктның ономастик берәмлекләрен өйрәнү зур әһәмияткә ия. Мондый тикшеренүнең нәтиҗәләре туган якның һәм аерым авылның тарихын торгызуда ярдәм итә. Мәсәлән, Шаран районы Таулар авылы янында “Тугыз кыз” дигән тау тишеге (мәгарә) бар. Бу төбәккә Акай явы килгәндә, анда тугыз кыз качып калган, дип сөйлиләр. Бу яу XVIII гасырның утыз бишенче елында булган.

Һәр авылның үз тарихы, үз атамалары бар. Халык авылның коечишмәсенә, елга-күленә, чокыр-басуларына, урман-болыннарына бик матур исемнәр биргән. Географик атамалар белән без балачактан ук очрашабыз. Туган йортыбыз урнашкан авыл, урам исемнәре, авылыбызның тирәягындагы тау, чокыр, басу, болын, елга, күл һәм башка географик объектларның атамалары кечкенәдән үк безне үзенә тартып тора.

Күгәрчен-Бүләк авылының якынча 350 елдан артык тарихы бар. Картлар сөйләвенчә, ул XVIII гасыр азакларында барлыкка килгән. Риваятьләрдән билгеле булганча, авылга нигез салучылар Пугачев явы башлангач, эзәрлекләүчеләрдән качып килгән Ык буендагы Чәкән тавы битендә яшәгән татарлар була. Алар, урман аша бау сузып бик озак барганнан соң, якты һәм ямьле акланга киолеп чыгалар. Бу акланда чишмә

агып ята, ә мәһабәт агачларның берсенә күгәрченнәр оялаган була. Борынгы ата-бабаларыбыз шушы урынны яратып, анда төпләнергә уйлый. Авылга нигез салгач, аңа исем үзеннән-үзе туа: “Бу авылны безгә күгәрченнәр бүләк итте”, – дип, алар авылны *Күгәрчен-Бүләк* дип айтыйлар [2: 98].

Аңлашыла ки, авылның барлыкка килү турында материаллар тарихи чыганкларда да тупланган [1]. Ләкин бу кечкенә хезмәттә без төрле чыганаклар нигезендә Күгәрчен-Бүләк авылының топонимнар системасын тасвирлауны максат итеп куйганлыктан, игътибарны җирле географик атамаларга юнәлтик.

Күгәрчен-Бүләк авылында күп санлы географик атамалар бар. Оронимнардан түбәндәгеләрне билгеләп була.

*Күчем чокыр.* Бу чокыр авылыбыздан ике чакрым ераклыкта урнашкан. Картлар сөйләвенчә, аның тарихы мондый. Бик борын заманда Заит авылында яшәүче кешеләр беренче тапкыр бу чокыр янына күченеп киләләр. Монда төзелешкә яраклы ташлар күп була. Ярлы халык аларны сатып, акча эшләргә уйлый. Шуңа да алар шушы кыядай текә һәм биек яр буенда төпләнеп калалар. Алар үзләренең авылына Күчем дип исем бирәләр. Ләкин кыш көннәрендә су алу монда бик кыен була. Хатын-кызларга биек кыядан төшеп, чишмәдән су алырга туры килә. Һәр төшкән саен алар: “Ник күчтек монда?” – дип сукрана торган булганнар. Озакламый кешеләр авылны ташлап китәргә мәҗбүр була. Авыл кырында төзелеш өчен алынган ташлардан чокыр гына кала. Картлар сөйләвечә, бу чокырның исеме барлыкка килү *күчем* сүзенә бәйле була.

*Салкын чишмә чокыры.* Ташлы һәм Күгәрчен-Бүләк авыллары арасында урнашкан зур чокырга шундый исем биргәннәр. Чөнки бу чокырның тәмамланган җирендә *Салкын чишмә* бәреп чыга.

*Беренче сыза чокыры.* Зирекле белән Күгәрчен-Бүләк авыллары арасында сай гына тип-тигез булып сузылып киткән уйсулык чокырлар булган. Аларга *Беренче сыда, Икенче сыда, Өченче сыда* дип исем биргәннәр. Бу исемнәр сызылып киткән уйсулык чокырлар тигез булганга бирелгән. Күгәрчен-Бүләк авылы халкы ***з*** авазын ***д*** (*d* – интердентaль тел-теш) авазы белән алыштырып сөйләшкән: *кыдыл бодау, Тәндилә кыдым* һ.б.).

*Бохара чокыры.* Бу зур чокыр урман эчендә урнашкан Бохара дигән авыл янында урнашкан. Атамасы шуңа бәйле.

Авылда гидронимнардан тик чишмә атамалары гына теркәлде, чөнки анда елгалар, күлләр юк.

*Олы чишмә.* Авыл уртасында урнашкан мул сулы, көчле чишмә. *Сәпәр чишмәсе.* Сәфәргалиев Камалетдиннарның бакчалары башында чыккан чишмә: *Сәпәр > Сәфәр > Сәфәргалиев. Салкын чишмә.* Авылдан читтәрәк, көтүлекләр янында, еракка сузылган чокырларның берсендә кечкенә генә бик саф һәм салкын сулы чишмә ага.

Авылда микротопонимик берәмлекләрдән басу атамалары да кызыклы.

*Фатыйма кабере басуы.* Бу урын Күчем авылы белән бәйле. Авыл таралып, кешеләре күчеп киткәч, монда тик зират кына торып кала. Еллар үтә, колхозчылар ул зиратны сөреп бетерәләр. Тиздән басу уртасында бердәнбер кабер кала. Ул Фатыйма исемле апаның кабере була. Балалары аның каберен калдыруны үтенеп сорыйлар. Алар каберне рәшәткәләр белән уратып алып, чәчәкләр һәм ак каен утырталар. Ел саен әниләренең каберенә килеп, аны карап китә торган булганнар. Хәзер ул балалар да дөньяда юк, ләкин халык Фатыйма каберен онытмый. Басу уртасында ак каенлы кабер һаман да тора. Аның истәлегенә басуны да Фатыйма кабере басуы дип йөртәләр.

*Торна тавы басуы. Ул* Күгәрчен-Бүләк һәм Ташлы авыллары арасында урнашкан. Элек бу торналар күпләп кайта торган урын булган.

*Ялгыз нарат басуы.* Күгәрчен-Бүләк һәм Түбән Ташлы авыллары арасындагы басу уртасында мең еллык тарихы булган бер язгыз нарат үсә.

*Калмия басуы.* Ул бик еракта - Ташлы авылы янында ук урнашкан. Атамасына “Колымага барган кебек ерак” мәгънәсе салынган.

Күгәрчен-Бүләк авылы өч яктан урманнар белән уратып алынган.

*Фиткә урманы.* Бу урман бик матур. Аның исеменең дә тирән тарихы бар. Картлар сөйләвенчә, элек Зирекле, Ташлы, Күгәрчен-Бүләк авыллары янындагы барлык урманнар бик бай барин Сафронов кулында була. Ул үзе Уфа шәһәрендә яши. Ә аның эшләрен монда күчере Федор алып бара. Ул бик эшчән, җитез, эше өчен җанын бирергә әзер кеше була. Намуслы эше өчен боярин Сафронов Күгәрчен-Бүләк авылы янындагы урманны Федорга бирергә була. Яңа хуҗа урман буенда үзенә зур йорт салдыра. Күп тә үтми, ул нык баеп, авыл халкыннан налог җыя башлый. Октябрь революциясеннән соң Федьканы “раскулачивать” итәләр. Урманнары халыкка кайтарыла. Өен сүтеп, Күгәрчен-Бүләк авылына күчереп, мәктәп итеп салалар.

*Нәҗеле урманы.* Авылының уң ягында урнашкан. Бу урман дәүләт карамагында булган. Урманны матрос (лесник) саклаган, халыкка агачны хөкүмәт вәкилләре рөхсәте кәгазе буенча гына биргән. Шуңа бәйле урман атамасы “надел” сүзеннән килеп чыккан дип фаразлана. Халык инде аны Нәҗеле урманы дип йөртә.

*Паруж урманы*. Бу урман уртасында элек *Красная горка* дигән урыс авылы булган. Совет союзы герое Леонид Цыбизов шушы авылда туып үскән. Ләкин урман ни өчен *Паруж урманы* дип аталуы билгеле түгел.

Бу мәкаләдә без тик Күгәрчен-Бүләк авылының микротопонимнарыннан тик өч төр (чокыр, чишмә, урман) атамаларын гына карап уздык. Ләкин авылның топонимик системасы болар белән генә чикләнми, әлбәттә. Аларның кайберләре үз әһәмиятен югалтса да, халык телендә һәм күңелендә һаман да яши, кыйммәтле тарихи ядкяр санала, яшь буынга авыл тарихын өйрәнү өчен

бик кирәкле чыганак булып тора. Ә иң мөһиме – алар буыннар бәйләнешен тәэмин итеп, ата-бабаларыбызның рухи мирасы булып яши.

**Әдәбият**

1. Асфандияров А.З. История сел и деревень Башкортостана и сопредельных территорий. – Уфа: Китап, 2009. – 744 с.

2. Башкортостан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төз., кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы И.К. Фазлетдинов. – Уфа: Китап, 2018. – 344 б.

3. Гәрәй Йосыф. Сүз асылы: Тел хикмәтләре. – Уфа: Мәгърифәт, 2001. – 186 б.

4. Камалов А.А. Башкирские географические термины и топонимия. – Уфа: Китап, 1997. – 384 с.

5. Камалов А.А., Шакуров Р.З. Словарь топонимов Республики Башкортостан. – Уфа: Китап, 2002. – 256 с.

## ТАТАР ҺӘМ КАЗАХ ТЕЛЛӘРЕНДӘ СОМАТИЗМНАР

*Исламова Л., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Г.Ф. Җамалетдинова*

Тел мәдәниятнең әһәмиятле компонентларының берсе санала. Чөнки аерым кеше яисә билгеле бер җирлектә оешып яшәүче кешеләр төркеменең дөньяны, тирә-ягын кабул итүе, үзенчәлекле күзаллавы, мәдәнияте телдә чагылыш таба. Шул юнәлештә фәнни эзләнүләр барлыкка килү, дөнья процессларының үсү-үзгәрүе, фәндә тел һәм мәдәният мөнәсәбәтләрен өйрәнә торган махсус тармак – лингвокультурология оешуга этәргеч бирде. Әлеге фән гуманитар фәннәрнең мәдәният һәм тел чигендә тора һәм турыдан-туры өйрәнә [1: 37].

Телдә фразеологик берәмлекләрне кешенең фикерләү һәм күзаллау нәтиҗәсе буларак өйрәнү халыкның лингвомәдәни үзенчәлекләрен ачарга ярдәм итә. Шуңа бәйле рәвештә, кеше әгъзаларын белдерә торган лексик-тематик төркемне өйрәнү лексикологиядә мөһим урын алып тора.

Соматизмнар – кеше әгъзалары атамалары. Алар фразеологик берәмлекләрнең бер компоненты санала. Бу төркем сүзләрнең күпчелеге бөтен төрки телләр өчен дә уртак: күз, баш, кул, арка һ.б. Соматизмнардагы күпмәгънәлелек аларның борынгы лексик катлам икәнен күрсәтә. Бу төр сүзләр кеше сөйләменең әһәмиятле бер элементы. Шуңа бәйле, фразеологизмнар составында соматизмнар актив кулланыла [3: 14].

Д. Б. Рамазsecurityованың «Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика» хезмәте Татарстан Республикасы һәм Россиянең татарлар яшәгән өлкәләрендә үткәрелгән экспедицияләрдә тупланган материаллар нигезендә язылган. Бу китапта соматизмнар төрле яссылыкларда тикшерелә.

«Баш» соматизмы нәрсәнең дә булса очын, иң югары баштагы өлешен белдерә: «Баш бетү», «Башына җитү», «Башы күккә тию». Казах телендә бу сүз акыл һәм зиһенне формалаштыручы корал буларак яши: «Сау басыңа сақина тілеме» (Башыңа маҗаралар эзләмә) , «Басты қатыру» (Башны

катыру), «Басымен жауап бересіз» (Башың белән җавап бирерсең), «Бас жоқ, аяқ жоқ» (Ни башы ни ахыры юк), «Басынан сөз асырмау» (Җавап бирә белү).

«Йөз» соматизмы кешенең күңел матурлыгын, аның намусын чагылдыручы корал. «Йөзен фаш итү», «Йөз карасы китерү», «Йөз сыту» «Йөзгә кара китерү», «Жүзбе-жүз» (Йөзгә йөз). Татар теленнән аермалы буларак, «Жүзі сынық» фразеологизмы исә казах телендә «намуслы, яхшы» белән беррәттән «кәефсез, төшенкелектә» мәгънәсендә дә кулланыла.

«Маңгай» сүзен шулай ук «намус» белән бәйләп карыйлар: «Маңгай тире белән», «Маңгайга язылган», «Маңдайға жазған» (Маңгаена язылган). Мисаллардан күренгәнчә, ике тел өчен дә уртак фразеологик берәмлекләр шактый.

«Муен» (Мойын), «Иңсә» (Ийин), «Арка» (Арка) соматизмнары авырлыкларны күтәрү мәгънәсен җиткерәләр: «Муенына күрә камыты», «Муенында утыру», «Аркага арка терәп», «Арка сөяксез», «Иңгә - иң куеп», «Аркага пычак кадау», «Мойнына алу» (Гаепне үз өстеңә алу), «Мойнымен кәтеру» (Баш белән җавап бирү). «Мойнына ала коржын» (Хәер сорашу) фразеологизмын казах телендә генә таптык. Шулай ук «Мойнын бұру» казах телендә «Игътибарны җәлеп итү»не аңлатса, татар телендә «Нинди дә булса начар эш өчен җәза» мәгънәсендә кулланыла.

«Борын» – ис сизү органы. Фразеологик берәмлекләрдә «якынлык» мәгънәсен белдерә: «Борын астында гына». Кайбер очракта исә «мактану», «үзеңне башкалардан өстен кую»ны аңлата. Бу ике телдә дә шулай: «Борынын чөйгә элү», «Борын күтәрү», «Мұрнымды кесіп берейін» (Үз-үзенә ышану). «Мұрнына су жетпеу» (Буш вакыт булмау) фразеологик берәмлегенең эквиваленты татар телендә шулай ук очрамады.

«Күз» соматизмы дөньяны танып белү, тирә-юньдә ориентлашуда катнашучы корал буларак билгеле. Күзләр кешенең рухи матурлыгын, психологик халәтен, эмоцияләрен дә чагылдыра: «Күзне ачып йомганчы», «Күзе акаю», «Күз карасы кебек». Казах телендәге «Көзі ілігіп кету» (Күз салу), «Көз тиді» (Күз тию), «Көз тастау» (Күз салу), «Көз көрген» (Күз күргән), «Көз ілмеу» (Күз элмәү) кебек фразеологизмнар шул ук мәгънәдә татар телендә дә бар.

«Кул» сүзе турыдан-туры «корал», «эш башлау» мәгънәсен җиткерә: «Кулында ут уйната», «Кулыннан ычкындырмау», «Қол қағысты» (Килештек), «Кол артар адам» (Ышанычлы кеше), «Қол қою» (Эш башлау), «Қол тимеу» (Буш вакыт булмау), «Қолы аллдына сыймау» (Эшсезлек).

Билгеләп үткәнчә, фразеологизмнар халыкның милли аңын, аның характерын, яшәеш үзенчәлекләрен, дөньяга карашын чагылдыручы берәмлекләр. Соматизмнарның фразеологиядә кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү ике халыкның үз-үзен, тән төзелешен ничек кабул итүен ачыкларга, алар арасындагы аермаларны билгеләргә ярдәм итә. Чөнки һәр халык дөньяны ничек күрә – шул рәвешле телдә чагылдыра. Соматик органнарга төрле

халыкларның универсаль функцияләре беркетелгән, бу шушы органнарны белдерүче лексемаларга билгеле бер символик мәгънә дә бирә.

Күзәтүләребезгә нәтиҗә ясап, шуны әйтә алабыз: «Баш» компоненты белән түбәндәге группаларда охшашлыклар бар: фикерләү эшчәнлеге, акыл эшчәнлеге, кешенең характеры, холкы, кешенең үз-үзен тотышы; «Кул» компоненты белән: хезмәт процессында кешенең осталыгына характеристика; эшне башкарып чыгу манерасы, актив эшкә физик каршылык; эшне башкаруга теләк булу-булмау; эшсезлек; «Күз» компоненты белән: күрү; күрүнең интенсивлыгы; кешенең күрү белән бәйле эшчәнлеге; эмоция; физик халәт; кешенең холкы, теләге.

Казах һәм татар телләре фразеологизмнарында соматизмнарның кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерү түбәндәге фикергә китерде: бу ике тел, кардәш булу сәбәпле, соматик органнарның телдә бирелеше, образлары, дөньяви һәм мәдәни карашлары, фразеологик берәмлекләрнең төзелеше охшаш.

**Әдәбият**

1. Букулова М.Г. Соматическая фразеология как отражение национально-культурной специфики языкового сознания: Автореф. дисс. … канд. фил. наук. Алматы, 2007.

2. Кожахметова Х.К., Жасакова Р.Е. Казахско-русский фразеологический словарь. Алматы: Мектеп,1988 – 219 с.

3. Рамазанова Д.Б. Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика. – Казан, 2013. – 364 б.

4. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001. – 335 б.

## ГРАММАТИЧЕСКИЕ ПЕРЕВОДЧЕСКИЕ СООТВЕТСТВИЯ В ПЕРЕВОДАХ СТИХОТВОРЕНИЙ А. АХМАТОВОЙ НА ТУРЕЦКИЙ ЯЗЫК

*Исхакова Г., КФУ, магистрант II курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. З.Н. Кириллова*

Поэтический перевод – это перевод поэтического текста, созданного на одном языке, с помощью поэтического текста на языке перевода [2: 11].

Методологическая основа исследования. Вопросами поэтического перевода задавались А.А. Потебня, Л.С. Бархударов, В.Н. Комиссаров, В.С. Виноградов. Проблемами перевода с русского на турецкий и наоборот активно занимаются Я. Тунч, И.А. Батанова, А.А. Евсеева и другие.

Поэзия начала XX века совпала с периодом борьбы женщин за равноправие. Поэтический голос женщины обрели в лице Анны Ахматовой, поэтому выбор пал на произведения именно этого великого автора и их переводы. Сегодня ее стихотворения переведены на многие языки мира. Атаол Бехрамоглу, Азер Яран, К.А. Мизиев – переводят ее турецкий язык, на которых мы подробно остановимся.

Тема актуальна, так как перевод ее произведений интересен и своеобразен с точки зрения грамматики и лексики. Сопоставление выразительных средств русского и турецкого языков и анализ приемов перевода способствуют приобретению и закреплению навыков перевода и помогает глубже проникнуть в особенности языка.

В рамках данной работы более подробно будет рассмотрена классификация, предложенная Л.С. Бархударовым. Здесь переводческие трансформации различаются по формальным признакам на: перестановки, замены, добавления, опущения.

В процессе перевода замене могут подвергаться как грамматические единицы – формы слов, части речи, члены предложения, типы синтаксической связи и др. [1: 194].

**Замена части речи**

1) Когда человек умирает, // Изменяются его портреты. - Biriцlьnce//İmgeleri değişir artık [https://www.siir.gen.tr/siir/a/anna_ahmatova/biri_olunce.htm]. Сказуемое, выраженное глаголом настоящего времени переведено деепричастием в турецком варианте.

2) Мне любви и покоя не дав, // Подари меня горькою славой. – Aєk ve huzur vermedin, bu sefer // Acı bir şöhret ver, hiç değilse [https://www.siir.gen.tr/siir/a/anna_ahmatova/ne_cok_istegi_var_tatli_yarin.htm]. В оригинале не дав является деепричастием, который переведен глаголом в прошедшем времени.

3) Показалось, что много ступеней, // А я знала – их только три! – Bitmez tьkenmez gibi geldiler bana // Oysa topu topu ьз taneydi basamaklar [https://www.siir.gen.tr/siir/a/anna_ahmatova/son_karsilasmanin_sarkisi.htm]. Наречие много переводится парным прилагательным bitmez tьkenmez (неиссякаемый).

**Замена главных членов предложения**

1) Откинув покрывало, // Внимательно взглянула на меня. - Ve takılıp kalıyor gözlerine gözlerim (я взглянула) [https://www.siir.gen.tr/siir/a/anna_ahmatova/esin_perisi.htm]. Налицо перемещение действующего лица: если в оригинале подлежащее – сама муза, то в переводном варианте лирический герой сам взглянул на музу.

2) Между кленов шепот осенний // Попросил: «Со мною умри! - "Benimle öl.." diye fısıldadı // Akçaağaçların arasından sonbahar [https://www.siir.gen.tr/siir/a/anna_ahmatova/son_karsilasmanin_sarkisi.htm]. В оригинале грамматическая основа – шепот попросил, а в переводе – fısıldadı sonbahar (прошептала осень).

**Замена формы слова**

1) Все тебе: и молитва дневная, - Her єey senin iзin: Gьn boyunca dualarım[https://www.siir.gen.tr/siir/a/anna_ahmatova/bilmiyorum_yasamakta_misin_oldun_mu.htm]. На языке оригинала молитва в форме единственного числа, а переводчик использовал множественное число с аффиксом притяжательности – ım - dualarım (мои молитвы).

2) Здесь же встречается еще один пример: смех и поруганье - gьlьєlere sцvьєlere [https://lyricstranslate.com]. Если оригинал представлен

существительными в единственном числе, то в ПЯ –ler – показатель множественного числа.

3) В серые глазки ее погляжу. – Küçük gri gözlerine bakacağım [https://www.siir.gen.tr/siir/a/anna_ahmatova/gri_gozlu_kral.htm]. Глазки в оригинале предаются в турецком варианте как kьзьk gцzlerine (в маленькие глаза).

4) Чтоб отчетливей и ясней – Açık, apaçık olman için ve [https://www.siir.gen.tr/siir/a/anna_ahmatova/ne_cok_istegi_var_tatli_yarin.htm]. Прилагательное в сравнительной степени (отчетливей) в оригинале дается двумя словами – прилагательными в исходной и превосходной степенях (açık, apaçık).

Рассмотрев и проанализировав стихотворения, можно сделать вывод, что переводчики больше всего использовали замены форм слова. То есть изменения прослеживаются больше на морфологическом уровне.

**Литература**

1. Бархударов Л.С. Язык и перевод (Вопросы общей и частной теории перевода). – М.: Междунар. отношения, 1975. – 240 с.
2. Гиривенко А.Н. Поэтический перевод в России первой трети XIX века: дис. … д-ра филол. наук: 10.02.20. – М., 2000. – 300 с.

## ҚАЗАҚ ТІЛ БІЛІМІНДЕГІ ГЕНДЕРЛІК ЗЕРТТЕУЛЕР

*Кабдрашова М., «Тұран-Астана» университеті, II курс магистранты*
*Ғыл. жет. – филол. ғыл. канд., доц. В.А. Шнайдер*

Кез келген халықтың гендерлік болмысы ғасырлар бойы қалыптасады, дамиды. Қазақ халқының гендерлік болмысы да ғасырлар жемісі. Қазақ тіл білімі қалыптасқанға дейін, қазақ тіліндегі гендерлік бірліктер (единицалар) бірден гендерлік лингвистикалық сипат алған жоқ, халықтану бағытында − қазақ халқының этнографиясы мен ауыз әдебиетін, мәдениетін зерттеушілер тарапынан гендерлік мәнбір (факт) ретінде хатқа түсті, екі жыныс орайында қазақы ерекшелік ретінде сөз болды.

Қазақ тіл білімінде гендерлік факторлар бұрын да назарға іліккен, атап айтқанда, қазақ ағартушы, зиялылары Ш. Уәлиханов, Ы. Алтынсарин т.б. ғылыми, ғылыми этнографиялық еңбектерінде ескеріліп отырған. Ағартушылық мәдениеттегі негізгі тетік − адам. Шоқан Уәлиханов сыртқы әлемге "дала адамын" түсіндіруді көздеді. Осы мақсатпен ол қазақ және қырғыз халықтарының аңыздарын, салтдәстүрін, діні мен тілін зерттеді. Ғалым бұрыннан қазақтар арасында кең тараған тәңірлік дін мен шамандықтың маңызын көре білді, мұсылмандықтың мәденитұтастық қызметіне назар аударды. Оның *"Қазақтардағы шамандықтың іздері"*, *"Қашқария туралы жазбалар"*, *"Сахарадағы мұсылмандық туралы"* т.б. ғылыми этнографиялық еңбектерінде қазақ және басқа түркі халықтарының мәдениетіне энциклопедиялық талдау жасалған. Солардың

ішінде жыныстың мәдени әлеуметтік мәнін айғақтайтын тілдік деректер мол. Мәселен, әйел тілінің дәстүрленуін ол былай түсіндіреді: "Қазақтарда от − үйдің киесі, шамшырағы, сондықтан да жаңадан түскен жас келіншек үлкен үйдің отына тағзым етуге (сәлем етуге) тиіс. Бұл салт (жаңа түскен жас келіншектің отқа тағзым етуі) моңғолдарда неке қию үрдісінде жасалады.

Жаңа түскен жас келін әуелі өз отауына кірмес бұрын, атасының үйіне кіріп, тағзым етуі тиіс, содан соң қалыңдық атасының отына бір қасық май тамызуы керек. Бұл ырымкәдені *"отқа май құю"* дейді. Жас келін сәлем еткенде, *"аруақ риза болсын"* деп тізе бүгіп, еңкейіп *"От ана, Май ана, шапағатыңды тигізе көр!...* дейді. Отқа тамызған май жанып жатқанда, жас келіннің жанындағы әйелдердің бірі алақанын отқа қыздырып, келіннің бетін сипайды.Үлкен үйдің отының құрметіне деп, қалыңдық атасының иығына шапан жабады, осы кезде отағасы ошақ жақтағы тулақты нұсқап, жас келінге отыр деген белгі беріп: *"иін қандырып илеген тулақтай, мінезің жұмсақ болсын қарағым"* деп батасын береді" [1: 158, 43, 177].

Ш. Уәлиханов зерттеулерінде гендерлік атаулар да кездеседі: "Рухы бар, жоталы әйелдерді *Елті* деп атайды (олар өзінің сиқырлық өнерімен, адамдарды еліту, ұйыту − бар санасезімін билеп алушы, өзіне бағындырушы). Елті сөзінің тегі қазіргі тіліміздегі еліту, олар да − *"бақсы"*, − дейді [1: 158]. Осы тәріздес ғылыми этнографиялық бағалы мәліметтер Ыбырай Алтынсарин еңбектерінде де кездеседі. Ол өзінің біраз еңбектерін қазақ халқының салтдәстүрлік ерекшеліктерін зерттеп, этнографиялық очерктер жазуға арнады.

Ы. Алтынсариннің *"Орынбор ведомствосы қазақтарының өлген адамды жерлеу және оған ас беру дәстүрлерінің очеркі"* мен *"Орынбор ведомствосы қазақтарының құда түсу, қыз ұзату және той жасау дәстүрлерінің очерктері"* атты еңбектері бастанаяқ гендерлік фактор ескеріле отырып жазылған [2: 91. Ол қазақтардың өлген адамдарды жерлеу дәстүрін сөз еткенде, өлген кісінің әйелі, қызы, анасы, апа-қарындастарының дауыс айтып жоқтауы, бейіт тұрғызу (бейіттің ауыл төңірегіндегі ең биік қыраттау, суға жақын жерге тұрғызылатыны, еркектердің моласының төбесіне найза, әйелдердің моласына бақан немесе пішпек қою) рәсімдерін т.б. баяндаған.

Ал, *"Орынбор ведомствосы қазақтарының құда түсу, қыз ұзату және той жасау дәстүрлерінің очеркі"* еңбегінде баласына қалың беріп, құда болғысы келген адамның ел аралап, қызы ұнаған үйдің керегесіне қамшысын қыстырып кететінін, ол құдалықтың бастапқы белгісі екенін, мұнан кейін көп кешікпей жаушы (елші) жіберіп, қыздың әкешешесінен ризашылық сұрайтынын, құдалар келіп қалың малға келісім жасайтынын, қалың малдың мөлшері қыздың жасауы мен әкешешесінің әлауқатына

байланысты қырық жеті немесе отыз жеті қара мал болатынын, ал кедей адамдар құда болғанда, ірілiуақты жиырма жеті, он жеті мал беретінін сөз етеді. Қалың малмен қоса бас жақсы туралы да келісетінін, олар қыздың сәукелесі, алтын жүзік, сырға, мақпал шапан, жорға ат пен күміс ертоқым сияқты асыл заттардан тұратыны айтылады.

Күйеу қайындап барғанда, − дейді Ыбырай, − мүмкіндігінше жақсы киінуі, ертұрманы таза күмістелген болуы керек. Күйеу басына бетін көрсетпейтін оқалы тымақ кию қажет. Ілуге әкелген малдарын қайын жұрты көріп, егер оны азырқанса немесе мал басынан кемістік тапса, күйеуді ауылға түсірмей, қайтарып жібереді. Күйеу қайын атасына оның көңіліндегідей ілу әкелуге тиіс. Тек сонда ғана ол құрметпен қарсы алынады" [2: 95]. Бұл еңбекте қыз аулында болатын *"Қынаменде"*, *"Қызқашар"* ойынсауығы, күйеу жігіт пен қалыңдықты кезіктіруде берілетін кәделер *("желі аттар", "ит ырылдатар", "кемпір өлді", "отқа салар", "қол ұстатар", "шаш сипатар", "көрпе қимылдатар"* т.б.) түгел дерлік сөз болады.

Гендердің дәстүрленуінің бастауы да ерте замандардан бері сақталып келе жатқан салтдәстүрлер, әдетғұрыптар мен мәденитілдік құндылықтар. Ыбырайдың қазақ халқының салтдәстүрлерін зерттеудегі мақсаты дәстүрдің озығы мен тозығын ғылыми түрде талдап, өзінің көзқарасын білдіре отырып, мәнмағынасын ашу, озық дәстүрді тәрбиенің құралы ету еді. Сонымен бірге тілімізге Ы. Алтынсарин еңбектері арқылы енген гендерлік мақалмәтелдер де жетерлік. Атап айтқанда, *"Ерлер көп болса − отын жоқ, әйелдер көп болса − су жоқ", "Жан жолдасың − жарың", "Ер −бас, қатын − мойын", "Ұятсыз қатын тұзсыз ас секілді", "Сұлу − сұлу емес, сүйген − сұлу"* т.б.

Тағы бір атап өтетін жайт: Қазақстанда қыздардың арнайы оқу орнында бөлек оқытылуы XIX ғасырдан басталады және бұл Ы. Алтынсарин есімімен тікелей байланысты. Ол қыздар мектебін ашу жөніндегі ойын В.В. Катаринскийге жазған бір хатында мәлімдеген: "Губернатор несколько сомневается в успехе женского киргизского интерната... а ведь если не начинать такого полезного дела, то ведь никогда ничего и не будет. Да, я уже и уверен, что в Иргизе дело это пойдет хорошо..." [2: 375]. *Қазақ тілінің гендерлік қырының лингвистикалық пайымы.* Тіл ғылымында гендерлік бағыт бірден пайда болмағаны сияқты қазақтың гендерлік лингвистикасының тырнақалды белгілері қазақ тіл білімі аясында XX ғасырдың алғашқы жартысында пайда болды. Қазақы гендерлік бағытты қалыптастыруда Ахмет Байтұрсынұлы мен Құдайберген Жұбанов ғылыми мұраларын зерттеп-зерделеудің өзіндік орны бар.

А. Байтұрсынұлы еңбектерінде бұрынғыдай гендерлік атаулар емес, ер мен әйел тіліне тән гендерлік ерекшеліктер, атап айтқанда, *"ғұрып сөзі", "қалып сөзіне"* байланысты ашып көрсетілген. Соның ішінде *жар-жар,*

*беташар, жоқтау, бата (ғұрып сөзі), бесік жыры (қалып сөзі)* т.б. турасындағы пікірлері гендерлік тұрғыдан пайымдалады. Ғалым "ғұрып сөзі" ғұрып сарынымен, яғни ғұрып бойынша істелетін істерге байлаулы сөздер айтылған. Қалып сөзі тұрмыс қалпында болатын істер сарынымен айтылады. Мәселен, "жар-жар − қыз ұзатар үйде айтылатын, қызды жұбату үшін айтылатын өлең" [3: 46], − дей келіп, үнемі қайталанып отыратын бастапқы екі жолды (нұсқасымен) бөліп көрсетеді:

Бір толарсақ, бір тобық санда болар,
Қырық кісінің ақылы ханда болар, − немесе:
Алып келген базардан қара насар,
Алтын құйрық сәукеле шашың басар.
Жауаптағы айтылатын екі жол:
Есік алды құба тал майда болсын,
Ақ бетімді көретін айнам болсын [3: 427].

Қазақ қызының гендерлік бейнесін сипаттайтын мұндай өлең түріне байланысты А.Байтұрсынұлы зерттеулерінің орны ерекше. Ғалым зерттеулеріне сәйкес, салт-дәстүр жырларының бір тобы әйелдер ғана жырлайтын *бесік жыры* мен *жоқтауөлең* болса, енді бір тобы *(беташар, бата)* ерлердің үлесінде. Мәселен, "жоқтау − өлген кісіні жоқтап сөйлеу. Жоқтау көбінесе белгілі адамдарға айтылады.

**Әдебиет**


1. Валиханов Ч. Следы шаманства у киргизов // Собрание сочинений в пяти томах». – Алма-Ата: Каз. сов. энциклоп., 1985. Т. 4. – 460 с.
2. Алтынсарин Ы. Таңдамалы педагогикалық мұралары. – Алматы: Рауан, 1991. – 144 б.
3. Байтұрсынов А. Ақ жол: Өлеңдер мен тәржімелер, публ. мақалалар және әдеби зерттеу / Құрастырған Р.Нұрғалиев. – Алматы: Жалын, 1991. – 464 б.
4. Хасанұлы Б. Ана тілі − ата мұра (Қазақ тілінің жер жүзі тілдері жүйесіндегі алатын орны). Алматы: Жазушы, 1992. – 272 б.


## ПАРЕМИЯЛӘРДӘ ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЫ


*Кадыйрова Г., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Г.Ф. Җамалетдинова*


Кешенең дөньяга карашы гаиләдә формалаша. Ә гаилә хатын-кыз кулында. Ир кеше гаиләне туендыручы булса, тапканны әрәм итми саклау, балаларга да шул яхшы сыйфатларны бирү, әдәпле, инсафлы, җәмгыятькә файдалы кешеләр итеп тәрбияләү хатын-кыз җилкәсенә төшә. Әлеге сыйфатлар тел-сурәтләү чараларында да шулай күрсәтеләме соң? Чынлап та, хатын-кыз халык авыз иҗатында шундый сыйфатларга хас кеше буларак тасвирланамы? Әлеге сорауга җавап бирү – эшебезнең актуальлеге.

Паремиология (борынгы грек сүзе, paroimia – мәсәл, гыйбрәтле хикәя, мәкаль һәм logos – сүз, өйрәнү) – мәкаль-әйтемнәрне, табышмакларны, афоризмнарны, сынамышларны, канатлы әйтелмәләрне һ.б. тышкы төзелешләре белән кыска, эчтәлекләре белән җыйнак, үткен

һәм сурәтле итеп әйтеп бирә торган фикер җәүһәрләрен өйрәнә торган тел белеме тармагы. Паремия ул, лингвистик терминнар сүзлегендә бирелгәнчә, фольклорның кечкенә жанрлар тибы: әйтем, мәкаль, табышмак, сынамыш, тапкыр сүз, теләк, тизәйткеч һ.б. Халыкның тәҗрибәсен, дөньяга карашын чагылдыра, кыскалык һәм форма тотрыклылыгы белән характерлана. Фразеологизмнар да төзелешләре һәм эчтәлекләре буенча паремияләр рәтендә каралырга хокуклы. Димәк, «паремия» төшенчәсе «фразеологизм» төшенчәсеннән киңрәк. Фразеологизмнар, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, канатлы әйтелмәләр, цитаталар кебек, паремиянең аерым берәмлеге булып тора. Безнең эшебезнең максаты – әлеге берәмлекләрдә хатын-кыз образының бирелү узенчәлеген ачыклау.

Халык авыз иҗатында хатын-кыз образының бирелеше үзенчәлекле. Нәкъ менә алар ярдәмендә мәдәниятта хатын-кызның тоткан урыны, һәм хатын-кызга булган мөнәсәбәт, фикер ачыклана. Без эшебездә татар телендә булган мәкальләр, фразеологизмнарны тикшердек. Әлеге тикшерү нәтиҗәсендә, мәкальләрне, фразеологизмнарны берничә төркемгә бүлеп карадык:

1.Хатын-кызның рольләренә бәйле рәвештә:

а) Ана:

*Ана булмыйча ананың кадерен белеп булмый.*

*Кояш янында – җылылык, ана янында – изгелек.*

ә) Хатын

*Асыл хатын – үзе ир, үзе хатын.*

*Атың начар булса да, хатының яхшы булсын.*

б) Каенана

*Каенанасы нинди – килене шундый.*

в) Килен

*Килен кеше – ким кеше, ялчы белән тиң кеше.*

*Киленне килгәндә, келәмне җәйгәндә макта.*

г) кыз бала һ.б

2. Хатын-кызның характерына бәйле:

*Бал сасымас – кыз картаймас.*

*Бозга таянма – кызга ышанма.*

*Гөл, үссә, – җирнең күрке; кыз, үссә, – илнең күрке.*

*Куштан кыз матур була.*

*Кыз бала җаныңны кыздырыр.*

*Кызлар бүрәнә ярыгыннан да көләләр.*

*Оялчан кыз – сөйкемле кыз.*

*Акыллы хатын – хәзинә.*

*Аяз көннең яшененнән, хатын-кызның усалыннан курык.*

*Бер хатынның хәйләсе кырык төягә йөк булыр.*

3. Хатын-кыз белән беррәттән ир-егет образы чагыштырылып карала:
*Яхшы кыз – якадагы кондыз, яхшы егет – һавадагы йолдыз.*
*Ир – ат, хатын – арба.*
*Ир – баш, хатын – муен.*
*Ир күрке – хатын, хатын күрке – ир.*
*Ир – табучы, хатын – туздыручы.*
4. Йортта хатын-кызның урыны:
*Ипи тәме тоз белән, өйнең яме кыз белән.*
*Кыз бала – өй зиннәте.*
*Кызлы йорт – нурлы йорт.*
*Йорт тоткан да хатын, йорт бетергән дә хатын.*
*Хатынсыз йорт – язсыз ел кебек.*

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: паремияләрдә хатын-кыз образының бирелеше гаять үзенчәлекле. Без хатын-кыз образының паремияләрдә бирелешен 4 төркемчәгә бүлеп тикшердек: роле, характеры, ир-ат образы белән бирелеше һәм йортта, гаиләдә урыны. Билгеле ки, тематик яктан әле тагын да күбрәк төркемнәргә бүлергә мөмкин, чөнки паремияләрдә хатын-кыз образы еш очрый, хәтта өстәлеп тә тора. Иң күп мисаллар хатын-кызның характерына бәйле төркемчәгә табылды. Мисаллардан күренгәнчә, хатын-кыз ул – хәйләкәр, аңа ышанырга ярамый, ләкин ул – йортның яме, өйнең зиннәте.

Шулай итеп, мәкальләр, әйтемнәр, фразеологизмнар ярдәмендә халык аңында хатын-кыз образына булган мөнәсәбәтне ачыклап була. Паремияләрне өйрәнү дә шуның белән әһәмиятле.

**Әдәбият**


1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 166 б.
2. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. 3 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. – 1015 б.
3. Юсупова Ә.Ш., Нәбиуллина Г.Ә., Денмөхәммәтова Э.Н., Мөгътәсимова Г.Р. Татар паремияләренең теле. – Казан: Ихлас, 2010. – 320 б.


## «ҚЫЗ ЖІБЕК», «АЙМАН-ШОЛПАН» ЖЫРЛАРЫНЫҢ БАСЫЛЫМДАРЫ ЖӨНІНДЕ


*Қазмағамбетова А., Қ.Жұбанов атындағы Ақтөбе өңірлік мемлекеттік университеті, II курс магистранты*
*Ғыл. жет. – фил.ғыл.канд., доц. М.Р. Балтымова*


Қазақстанның Батыс өңірінде дүниеге келген ғашықтық жырлардың аймақтық ерекшелігімен қатар өз кезеңінде жалпы руханиятта алған маңызын олардың 19 ғасырдың өзінде бірнеше рет баспа бетін көргені де анықтай түседі. «Қыз Жібек» жырының сюжеттік негізі қазақ арасында түрлі жанрда, яғни аңыз, ертегі, жырлар үлгісінде де талай ғасырдан бері айтылып келе жатыр. Дегенмен жырдың өзі тек XIX ғасырдың екінші

жартысында ғана жазып алына бастаған. 1887 жылы Қазалы бекінісінде әскери қызметте жүрген орыс офицері Е.А. Александров жергілікті өңірдегі айтулы жырау Мұсабайдан «Қыз Жібекті» қағазға түсіріп алады да, көп ұзамай оны әріптесі, милиция пропорщигі М. Ағаманов арқылы орыс тіліне аудартады. «Қыз Жібек» жырының бұл аса бағалы нұсқасын 1959 жылы Мәскеудің Орталық тарих музейіндегі белгілі түркітанушы Н.И. Гродековтің жеке қорынан талантты мәтінтанушы-ғалым Мәлике Ғұмарова іздеп табады [1]. Аталған нұсқаны сол жылдары Мұсабай жыраудан орыс офицері әрі фольклоршы И.В. Аничков та жазып алған. Бұл жайында ол өзінің «Поездка на киргизские поминки» (1897ж.) атты мақаласында әсерлі баяндайды.

Мұнан соңғы жырдың тағы бір нұсқасы Қазан қаласында 1894 жылы белгісіз ноғай азаматының әзірлеуімен жарыққа шықты. Бастырушы жырдың соңында: «... мұны мен өзім ноғай болсам да, досым Ахметкерімге арнап, қазақша жаздым» – дейді. Осы белгісіз нұсқа 1895, 1896, 1899 жылдар арасында тағы да бернеше рет басылған. Бұдан кейін 1900 жылы эпостың тағы бір көркем нұсқасы белгілі баспагер әрі ақын жетісулық Жүсіпбек қожа Шайхысламұлының атынан Қазандағы «Университет» баспасынан жарыққа шығады. Мұнан соңғы уақытта «Қыз Жібек» жырының Жүсіпбек нұсқасы Қазан төңкерісіне дейін және Кеңес кезеңін қоса санағанда 10-нан аса қайта басылған екен.

Эпостың 1894 жылғы белгісіз нұсқасы мен 1900 жылы Жүсіпбек жариялаған нұсқаларын салыстыра қарағанда, олардың сюжеттік құрылымы мен жалпы мәтінінде айтарлықтай өзгерістер жоқтығын аңғарамыз. Эпостың алғашқы басылымындағы қарасөзбен баяндалатын тұстарын Жүсіпбек жырға айналдырып, көп жерін өзінше өңдеген.

Басында менен жайылды,

Қисса болып Қыз Жібек... – деу арқылы ақын өзінің авторлық құқын дәлелдеумен болады. Дегенмен Жетісу жерінде 1926 жылы қазақ әдебиетінің болашақ классигі М. Әуезовпен кездескен Жүсіпбек ақын бұл жырды Ақшәмшіде бір жыраудан ертеректе үйренгенін, содан жазып алып, баспаға бергендігін айтқан [2: 420].

«Қыз Жібектің» жаңа нұсқалары Мұсабайдан басқа, Сыр бойының Әбілқайыр Дәнекеров (1954), Рахмет Мәзқожаев (1959), Қуаныш Баймағанбетов деген дарынды ақын-жыршылардан жазып алынған. Аталған жырдың нұсқалары эпостың тұңғыш ғылыми басылымын дайындау барысында 1963 жылы зерттеліп, «Қыз Жібектің» канондық мәтінін қалыптастыру үшін, қажетіне қарай пайдаға асқаны да мәлім.

«Қыз Жібекті» жырлауға Ақтөбе, Торғай, Қостанай өңірлерінің жыршылары да белсене араласты. Мысалы, Қостанай өңірінен жазылып алынған Хакім Досмағанбетұлы (1930), Әлиәкбар Досжанов (1947)

нұсқалары, ақтөбелік белгілі жыршы Шапай Қалмағанбетовтың өз қолымен өткізген екі бірдей үлгісі осыған дәлел. Сондай-ақ оралдық Қайырғали Иманов (1940), халық ақыны Халима Өтеғалиева (1950), Молдасейіт Төлепқалиев (1956), Қасым Мырзағалиев, шығыс қазақстандық Ержан Ахметов (1959) орындаған нұсқалары да эпостанушылардың тарапынан жақсы бағаланды. Бұдан өзге де бірлі-жарым жыр үлгілері Оңтүстік Қазақстан (1953), Қарағанды облысынан (1955) жазып алынған.

Революциядан бұрын жарық көрген қазақ кітаптарының қашан, қай жерде, қалай баспадан шыққаны, олардың шығарушылары кімдер екендігі және жазба мұраларды жинаушылар мен авторлар туралы мәліметтер берілген Әбіш Жиреншиннің 1971 жылы жарық көрген «Қазақ кітаптарының тарихы» атты кітабынан басқа көлемді еңбектер бүгінде өте сирек [3]. Сол себепті Ү. Субханбердина мен Д. Сейфуллина құрастырған библиографиялық көрсеткіш таптырмас құрал [4]. Еңбекте 1807–1917 жж аралығында жарияланған қазақ кітаптары жинақталған. Осы жылдарда баспадан шыққан күллі лиро-эпостық жырлардың кітаби нұсқаларының ішінде жоғарыда аталған екі жырдың басылым тарихы мынадай:

**«Қисса-и Қыз Жібек»** 1876 жылы, 1894 жылы, 1896, 1897, 1899, 1900,1902, 1903, 1905, 1908, 1910, 1911, 1913 жылдары Қазан қаласында әр түрлі (Хұсайыновтар б., университет табиғханасы, Домбровский табиғханасы) т.б. баспаханаларда басылған.

**«Қисса-и Айман-Шолпан» қиссасы** Чиркова табиғханасынан 1896жылы, Қазанда 1898 жылы, 1900 жылы, 1901 жылы Университет табиғханасынан, 1906 жылы Шәмсуддин Хұсаинов уәрсәләрінен, Қазанда 1908 жылы, 1910 жылы Домбровский матбәғәсінан, 1913 жылы Б.Л. Домбровский матбәғәсі, 1916 жылдары бірнеше рет басылып шыққан [24].

Осы көрсеткіштерден-ақ 1807–1917 жж арасында жарық көрген лиро-эпостық жырлардың ішінде аталмыш екі жырдың басылымының жалпы санын анықтаймыз. Бұл жылдар аралығында жалпы саны 84 кітап баспадан шыққан, оның ішінде «Айман-Шолпан» жыры 9 рет, «Қыз Жібек» жыры 13 рет қайта басылғанын байқадық. Бұл басылымдардың көбі М. Әуезов атындағы ӘӨИ-дің сирек қолжазбалар қорында және Орталық ғылыми кітапханада сақтаулы тұр. Бұл басылымдар аталған жырлардың XIX ғасыр мен XX ғасырдың басында өте сұранысқа ие болғандығына куә болады.

**Әдебиет**

1. Ғұмарова М. Эпос және ақындық мұра. – Қарағанды: "Ли Ю.Ю.", 2013. – 292 с.
2. "Қыз Жібек" лиро-эпосының ғылыми басылымын баспаға әзірлеу тәжірибесінен. – С. 115-134.
3. Ғабдуллин М. Қазақ халқының ауыз әдебиеті: оқу құралы. – Алматы: Рауан, 2013. – 455 б.

4. Қазақ әдебиетінің тарихы. Он томдық. 1том. – Алматы: ҚАЗақпарат, 2007. – 812 б.
5. Қасқабасов С. Таңдамалы. – Астана: Фолиант, 2014. Т.2. Мифология. Фольклор. Әдебиет. Зерттеулер. – 344 б.

## ЭТИКЕТ ТАТАРСКОГО ЗАСТОЛЬЯ В СЕЛЕ ТОКАЕВО

*Камалдинова И., Чувашская Республика, Токаевская школа, X класс*
*Рук. – Д.М. Гималтдинова*

Работа посвящена исследованию традиций татарского застольного этикета жителей села Токаево Комсомольского района Чувашской Республики.

Современный мир стремительно меняется. Глобализация привела к тому, что стирается граница между народами. Люди по всему миру стали одинаково питаться продуктами быстрого приготовления, одеваться в джинсы, жить в одинаковых жилищах и проводить время у экранов компьютера или телевизора. Люди столетиями жили размеренной традиционной жизнью, а за последние 10-20 лет жизнь кардинально изменилась. На этом фоне становится очевидным важность сохранения народных традиций и знаний народов. Поэтому данная работа является исключительно актуальной, потому что она направлена на изучение и сохранение народных знаний в области застольного этикета татар.

**Цель работы** – изучение традиций застольного этикета татар села Токаево Комсомольского района Чувашской республики.

**Задачи:**

1.Изучить литературу по теме татарского этикета застолий.
2.Опросить старожилов села о традициях приема гостей.
3.Выяснить, по каким праздникам обычно приглашали гостей.
4.Узнать, как сервировались столы, как рассаживались гости.
5.Выяснить, какие подарки дарили в гостях.
6.Описать типичное меню и последовательность подачи блюд.
7.Найти предметы старины, связанные с приемом гостей.

В ходе исследовательской работы были использованы следующие методы:

1.Изучение краеведческой литературы и обзор татарских Интернет сайтов.
2.Опрос старожилов.
3.Анкетирование.
4.Статистическая обработка данных.
5.Реконструкция.

Надо отметить, что данная исследовательская работа привлекла большой интерес жителей. Ученикам было очень интересно помогать авторам работы. Бабушки и дедушки были очень рады, что внуки интересуются стариной, историей, они с удовольствием доставали из сундуков старенькие, но любимые татарские платья, тюбетейки, в которых ходили в гости, показывали домотканые скатерти, салфетки, коврики, деревянные самодельные ложки, маслобойки, формы для выпекания хлеба и многое другое…

Родители тоже всячески помогали: по просьбе детей пекли различные блюда, фотографировали.

Все получили огромное удовольствие от участия в данном проекте! Осознали гордость за то, что принадлежат к своему народу. Почувствовали ответственность за сохранение и передачу традиционных народных знаний дальше – своим потомкам.

**Возродим утраченное**

Детская Экспедиция «Возродим утраченное» дала многое. Мы лучше узнали традиционную кухню и быт наших бабушек, нашли огромное количество предметов старины. Познакомились с традиционным татарским этикетом, традицией приглашения гостей. Записали воспоминания многих пожилых людей.

Традиционная татарская кухня, впитавшая в себя кулинарные традиции булгар, русских, чувашей, влияние Востока и Европы, богата самыми разнообразными блюдами повседневного и праздничного стола. И по сей день сохранились не только замечательные рецепты национальной кулинарии, но и существовавшее в веках радушное гостеприимство народа. Особенность татарской кухни – это то, что все кушанья можно разделить на следующие виды: жидкие горячие блюда, вторые блюда, печеные изделия с несладкой начинкой (также подававшиеся на второе), печеные изделия со сладкой начинкой, подававшиеся к чаю, лакомства, напитки. Появилась гордость за свой татарский народ, за то, что у народа такая богатая история со своими традициями, национальной кухней.

Было проведено анкетирование школьников, которое показало, что большинство учеников знает свои национальные блюда, многие даже умеют готовить. Дети гордятся татарской национальной кухней.

Экспедиция привлекла к себе огромный интерес школьников, многие ученики подходили к участникам с желанием присоединиться. Выяснилось, что у многих детей в семьях, живущих с представителями старших поколений, есть много ценных старинных экспонатов.

Очень рады были пожилые участвовать консультантами в Экспедиции.

Таким образом, краеведческая экспедиция пробудила необычайный интерес школьников, у детей проснулось национальное самосознание, гордость за свою культуру.

В рамках данной работы не удалось полностью охватить все вопросы, зато было решено работу продолжить в виде проекта – альбома «Традиционный татарский этикет»: сделать качественные фотографии предметов старины, записать воспоминания пожилых, чтобы оставить в памяти поколений свои народные национальные традиции.

Известный татарский просветитель и энциклопедист Каюм Насыри в своей книге о воспитании описал ряд правил, обязательных во время

еды: «За стол садись сразу же, как только подадут еду, не заставляй себя ждать. Ешь правой рукой, если за столом собрались почтенные люди, не тяни к еде руку раньше них – это невоспитанность. В умеренной еде большая польза – будешь здоров телом, ясен умом, силен памятью». Хочется, чтобы молодое поколение не забывало наставления пожилых.

**Литература**

1. Паркер Э.Н. Татары. История возникновения великого народа. – М: Наука, 2010. – 323 с.
2. Шихаб Китапчы. Наследие татар. – Казань: Алгоритм, 2013. – 369 с.

## ЛИНГВИСТИК ТИКШЕРЕНҮ ОБЪЕКТЫ БУЛАРАК ПОЭТИК ТЕКСТ
## (XX гасырның беренче яртысы татар шигърияте мисалында)

*Камалова Д., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән.канд., доц. А.Ф. Йосыпов*

Сүз сәнгате әсәрләрен өйрәнү төрле максатларда һәм төрле методологик позицияләрдә башкарылырга, оештырылырга мөмкин. Милли әдәбият һәйкәлләре тел тарихы галимнәре һәм әдәбият теориясе тарихы өлкәсендә эшләүче галимнәр өчен генә түгел, стилистика мәсьәләләре белән шөгыльләнүче галимнәр өчен дә кыйммәтле материал булып тора. Мондый тикшеренүләр барышында тел белгечләре күпчелек формага яки текстларның эчтәлегенә игътибар итәләр, ә бу төр өйрәнүләрнең үзәгендә булган текстларны форма һәм эчтәлек бергәлегендә анализлау исә төп бурычлар рәтендә каралмый.

Шундый бер закончалык бар: автор никадәр талантлырак булса, аның әсәрләре сурәтләү чараларына шул кадәр баерак була [1: 86], – дип яза филология фәннәре докторы Г.Х. Әхәтов. Күзгә бәрелеп тормаган күренешләрне үз әсәрләре тукымасында матур урнаштыручы, вакыйгаларны җанландыра белүчу, совет чорында күтәрелеп чыккан атаклы татар халык шагыйре – Һади Такташ.

Аның теле – үзе бер дәрья, үзе бер диңгез. Такташ татар милли әдәби теленең формалашуында һәм алга үсешендә гаять зур роль уйнады. Ул әдәби телебезне яңа троплар, яңа фигуралар белән шул кадәр баетты ки, аның иҗаты татар поэзиясенең генә түгел, бәлки башка тугандаш халыклар поэзиясенең дә үзеннән соңгы буыннарына уңай йогынты ясады. Такташ моңа ана телен, туган халкының фольклорын, борынгы әдәбиятын һәм шулай ук Көнбатыш Европа, рус классикасын, Көнчыгыш әдәбиятын яхшы белүе һәм алардан оста файдалануы аркасында ирешә алды [1: 86].

Текстка филологик анализ ясау, иң беренче чиратта, аның лингвистик поэтикасын ачыклауны күз алдында тота. Бу яктан исә Һади Такташ иҗаты гаять кызыклы, чөнки үз әсәрләрендә ул төрле сурәтләү чараларын куллана.

Әдәби сөйләмнең әһәмиятле хасияте буларак сурәтләү алгы планга килә, ягъни, укучының яисә тыңлаучының күңелендә нинди дә булса күзаллаулар, теге яисә бу образны, предметны, вакыйга, күренешне тудыра алу сәләте. Тел сурәтләү чаралары гаять күп һәм төрле.

Тел белгечләре аларны ике төркемгә бүлеп карыйлар: троплар һәм стилистик фигуралар. Тропларны әдәби әсәр авторлары күпчелек очракта табигатьне, геройларның образларын тудыру барышында куллана. Алар автор характерын, язучы һәм шагыйрьнең үзенчәлеклелеген билгели, аңа индивидуаль стиль эзләп табарга ярдәм итә. Стилистик фигуралар исә, автор сөйләмен җанландырып җибәрә, аңа эмоциональлек һәм образлылык өсти, текстны дәрт белән тулыландыра һәм, әлбәттә, укучыга билгеле бер кәеф тапшырып, анда эмоция һәм хисләр тудыра.

Һади Такташ үзенең шигырь текстларында металогик һәм автологик алымнардан оригиналь рәвештә оста файдалана. Сүзләрнең күчерелмә мәгънәдә кулланылуы металогик алым дип йөртелә.

Һади Такташ үз әсәрләрендә метафорларны яратып куллана һәм алар бик үзенчәлекле.

*Их!*
*Кичә генә әле февраль иде,*
*Бүген давыл кырга кар ташый,*
*Март аеның* ***нечкә билле*** *җиле,*
*Сузылып ятып җиргә, кар ашый...* (“Нәни разбойник”, 1926)

Бу өзектә китерелгән метафорага карата Хатип Госман мондый фикердә: “Нечкә бил” – бу татар поэзиясендә элек-электән килгән сылулык, иркәлек сыйфаты. Ләкин Такташка кадәр шагыйрьләрдән беркем дә язгы җилнең нечкә билле булуын күрмәгән! Монда Такташның искиткеч көчле талантлы, халык поэзиясенә никадәр тирән һәм нечкәләп керә белүе, анда йомылып яткан гүзәл чәчәкләрне үз иҗатында гаять зур осталык белән ачып бирүе күренә. Такташ халык иҗатының, гуяки, сулышын тоя, кан йөрешен сизеп тора. Ул аның кан йөрешен, гуяки, үз иҗатына тоташтырып җибәрә һәм, нәтиҗәдә, халыкның олы күңелендәге поэтик җылылык аның шигъри юлларына йөгерә” [2: 86-87].

“Сузылып ятып җиргә, кар ашый” метафорасы җанландыру алымы белән үрелеп киткән. Һәм мондый типтагы метафоралар Һ. Такташ иҗатында аз очрамый. Мисал:

***Төпсез күзләреңне***
*Еракларга* ***табан тегәсең***.

Әлеге алым, үзенә күрә, метафораның укучыга тәэсир көчен дә арттыра.

Такташның теле шактый үткен, моңа бәйле рәвештә ул еш кына усал, сатирик яңгырашлы метафоралар да куллана:

*Әй, сез, калдык непман уллар!*

***Базар корольләре!***
***Шарлатаннар!***
***Череп беткән сыра кортлары!***(“Такташ үлде”, 1923)

Лингвистик яктан Һ. Такташ иҗатын өйрәнү бик кызыклы, чөнки аның тарафыннан кулланылган күчерелмә мәгънәдәге сүзләр аның тел байлыгын, образлылыгын, халык иҗаты җәүһәрләре элементларыннан оста файдалануы һәм бары аңа гына хас булган оригиналь *тропларны* күрсәтә. Һәм Һ. Такташның иҗатына гына хас булган үзенчәлеге итеп билгели.

**Әдәбият**

1. Әхәтов Г.Х. Такташның татар әдәби тел үсешедәге роле. – Казан: ИЯЛИ, 1982.
2. Заһидуллина Д.Ф., Ибраһимов М.И., Әминева В.Р. Әдәби әсәргә анализ ясау. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 с
3. Курбатов Х.Ф. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 с.

## ШӘКӘРІМ ШЫҒАРМАШЫЛЫҒЫ – РУХАНИ БІЛІМНІҢ ҚАЙНАР БҰЛАҒЫ

*Канапьянова Д., «Туран-Астана» университеті, ІІ курс студенті*
*Ғыл. жет. – филол. ғыл. канд., доц. Г.Н. Зайсанбаева*

Қазақстанда жоғары білім беру жүйесінде болашақ мамандардың тұлғалық қасиетін ашуда құндылыққа бағдарланған білім негізге алынады. Бұл, біріншіден, тұлғаның жан-жақты дамуып,қоғамдағы әрқилы мәселелерді шешуде белсенді, құзыретті болып қалыптасуына, екіншіден болашақта қазақстандық білім беру жүйесінің әлемдік білім беру кеңістігінде бәсекелестігін арттыруға бағытталған.

Құндылық бағдарлы білім беру қоғамдағы барлық саланың жандануына, азаматтардың саналы әрекетінің сапасының артуына, адамның ішкі әлеуетінің жарыққа шығып, қоғамның қажеттілігін өз мүддесінен оғары қоя білетін азаматтардың санының артуына ықпал етері сөзсіз. Қазіргі таңда БҰҰ адами даму әр тұлғаның өз әлеуетін дамытудағы таңдауының болуын және адам өмірінің басты мақсаты мен нәтижесі адамның рухани дамуы екендігін, әр адам өз өмір сүру ортасына оң ықпал етуге ұмтылуын, белсенді қатысуын қамтамасыз ету деп көрсетеді [3: 9]. Бұл қоғамның әл-ауқатының артуынан да маңызды болып табылады. Елбасының «Болашаққа бағдар: рухани жаңғыру» Жолдауында көрсетілгендей: «Ұлттық жаңғыру деген ұғымның өзі ұлттық сананың кемелденуін білдіреді» [1: 1]. Қазақстан әлемдік проблемалардан қалыс өмір сүре алмайды. Қазіргі жаһандану үдерісі жағдайында, ең басты адамзаттың мәселесі бұл әлемдегі экологиялық жағдай, климаттың өзгерісі, халықтар, ұлттар арасындағы қақтығыстар, діни алауыздықтар белең алуы болып табылады. Яғни, рухани-адамгершілік білім мәселесі өте өзекті болып отыр.

Қазақ халқының ойшылы Шәкәрім өткен ғасырдың басында «ар ілімі оқылса» деп арман еткен. Шәкәрім шығармашылығының басты тақырыбы жүрек тәрбиесіне, адамның ішкі жан дүниесінің кемелденуіне, әрбір жанның бұл әлемде қиянатсыз өмір сре алатынына деген сенімге, адами қасиеттердің дамуының маңызына арналған.

Білім беруде бұл аксиологиялық бағдарлы білімге бастау болатын ұлы туындылар. Шәкәрім шығармалары тұлғаның дүниетанымдық көзқарасын айқындап, оның өмірлік ұстанымдарының қалыптасуына негіз болады. Құндылықтар адамның қоғамдағы өз орнын анықтауына, қиындықтарды жеңуге, барлық жағдайда өзін жетілдіруге және адам деген атқа лайық өмір сүруге саналы бағдар береді. Әлемдік руханият жеке ұлттардың дүниетанымдық ерекшеліктерінен және адамзатты біріктіретін ортақ құндылықтардан құралады. Қазақ халқы – әлемдік таным көкжиегінде көшпенділердің өркениеті арқылы өзіндік бояуымен танылған халық. Қазіргі білім беруде ұсынылып отырған жалпыадамзаттық құндылықтарға негізделген ішкі білімді дамытуға бағытталған Қазіргі таңда ғасырлар қойнауынан осы күнге дейін жетіп отырған ұлттық құндылықтардың өзектілігі күнделікті тіршілігімізден айқын байқалады. Сондықтан да білім беруде ғасырлар бойы бүкіл адамзатқа ортақ болған құндылықтарға негіздеп құрылған білім беру мазмұны болашақ мамандардың да құзыреттілігіне негіз болары сөзсіз. Яғни, халық ұлттық құндылықтарын сақтай отырып, биік бәйтеректей тамырын тереңге жаяды. Батыр бабамыз Б.Момышұлы: «Ұлттық рух тамаша қасиеттерге ие, өз ұлтыңды танытуға көмектеседі, ал бізге осы асыл қасиеттерді дамыта түсу қажет, осындай адам ғана өз халқының алдындағы борышын терең де жоғары сезінеді», – деген [1: 2]. Сондықтан да, жалпыадамзатқа тәнқұндылықтар- Шәкәрім шығармашлығының түп қазығы, адамзатқа ұсынар баға жетпес қазынасы. Шәкәрім шығармаларында жалпыадамзаттық құндылықтар қалай танылады, соған тоқаталайық. Рухани-адамгершілік білім Ойшылдың мына жаратылыс сырына жауап іздеп, ол жауаптарын өлең жолдарымен және «Үш анық» еңбегінде ұсынады. Бұл шығармалардың барлығында Жаратушының әлемді қалай жаратып, қалай басқарады? – деген философиялық сұраққа терең талдау жасалынады.

Болмыстың рухани және материалдық әлемдерден құралатынын, ол Жаратушының рухани қуатымен басқарылатынын, материалдық дүние көзбен көрініп, қолмен ұсталса, рухани әлем тек рухани болмыстан тұратынын айтады.

Басында **жан** мен **дене екі басқа,**  
Жан шыдап тұра алмайды қозғалмасқа.  
Дене сауыт сықылды жанның орны,

Оны да күту керек бұзылмасқа...
Кейде жақсы іздейміз, кейде жаман,
Көңіл неге қызықса – соған таман.
Дене жеңсе, түпсізге қызығамыз,
Жан билесе, жаманнан қылмақ аман.
Жан талпынар талайды көрмек үшін,
Әр сырын дүниенің білмек үшін.
Дене байғұс салмақ боп баса берер,
Жаралған ғой түбінде өлмек үшін.
Дене менен жан – анау, көңіл – мынау
Қайсысына билеттің байғұсым-ау?
Ең түбінде **өзің – кім, сенікі – кім,**
Досың қайсы, өзіңе қайсысы жау?
Анық қара: **жан – өзің, дене – киім,**
Мақтан, бояу – денеге берген сыйың.
Жанға мұндай алдауың азық емес,
Оған пайда не қылдың жалғыз тиын.
Сауық-қызық көрем деп, күнде жиын,
Жан құтқарып алуың болар қиын.
Түптіге ұмтыл, тұрақты істерді қыл,
**Тәуекел деп өзіңе сүйтіп сыйын.**

Осы өлең жолдарында адамның жаны, тәні және нәзік денесі жайында айтылған. Яғни адамның рухани болмысы мен материалдық болмысы жайында жазады. Адамның рухани болмысы оның ой-санасының, таным-түсінігінің кеңдігінен, ниеті мен іс-әрекетінінің ізгілікке бағытталуымен айқындалады. Материалдық дүние рухани болмыстың тығыздалған түрі ретінде жанның мекені, сауыты деп көрсетеді ойшыл. Рухани жетілу үшін:

Хақиқатты дәл көруге,
Жан көретін көз керек.
Бас көзімен сенделуге,
Бізге рұқсат жоқ, шырақ.
Сөнген ойды жандыруға,
Жан берерлік сөз керек.
Жаны жоқты нандыруға,
Жан керек қой милырақ – деп рухани жолдың маңызын, ақиқатты көруге саналы көз керектігін ашады.

Шәкәрім шығармаларының дені «ар», «ұждан» категориялары болып табылады. «Таза дене, толық мінез ой істерін керек қылады, соның қатты бір керегі – ұждан. Оны адам осы өмірі үшін ғана керек қылмайды, соңғы өмір үшін де керек қылады. Атым қалсын, мені жақсы көрсін,

пəленше сондай таза деген үшін емес. ..Ұжданның жан тілегі екеніне нанған адам өмірде істеген қиянатына қатты өкініп, күйіп, істеген жақсылығына қуанып өлсе керек. Олай нанбай, ұжданды құр ғана көрініс үшін адамдыққа лайық деп ұғатын кісіге жақсылық пен қиянаттың көп айырмасы болмаса керек. Оған бүгінгі өмірдің айла-əдісін тапса болғаны. ...Ұждан – өмірге бірдей керек таяныш. Бұған нана алмаған адамның жүрегін ешбір ғылым, өнер, ешбір заң-жол тазарта алмайды» дейді. Шəкəрім шығармашалаға келешек ұрпаққа ар ілімі арұылы ішкі тазалыққа, жан үйлесіміне ұмтылуға тəрбиелейді. Жаны таза, ішкі білімі жоғары адамақиқатты тани алады, əлеммен үйлесімді өмір сүре алады деген қазіргі замаанауи білімнің негізі болып табылады. Адамның үйлесімді дамуы, білімге құштарлығы, қиянатсыз таза өмірге ұмтылысы бақытқа жеткізеді деген даналықты бізге мұра етеді.

**Əдебиет**


1. Нұрғали Р. Ұлт ұстазы // Егемен Қазақстан. 2007, қыркүйек 26. – Б. 13.
2. Қазіргі əлемдегі философия: даму стратегиялары.– Алматы: Атамұра, 2013. – 456 б.


## ИСПОЛЬЗОВАНИЕ МНЕМОТЕХНИЧЕСКИХ ПРИЕМОВ ПРИ ОБУЧЕНИИ ДЕТЕЙ В ШКОЛЕ


*Кашаева А., КФУ, студент V курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. А.Х. Ашрапова*


В современном мире информация имеет огромное значение, и не только взрослые, но и дети живут в мощном потоке информации. В связи с этим актуальной становится проблема запоминания этих новых данных и сведений. Особенно школьники часто сталкиваются с этой проблемой: они знакомятся с большим количеством новых для них терминов, заучивают правила, изучают разные языки и т.д.

Для того чтобы с легкостью запоминать новую информацию, необходимо тренировать свою память. Память – это главный инструмент нашего разума. Существует множество приемов, форм, путей и методов развития и эффективного использования памяти. Мнемотехника является одним из самых интересных и действенных. Мнемотехника (мнемоника) – это искусство запоминания, совокупность приемов и способов, облегчающих запоминание и увеличивающих объем памяти путем образования искусственных ассоциаций [3: 8].

Мнемотехника существует уже несколько тысячелетий. Считается, что данное слово было придумано в 6 веке до н. э. Пифагором Самосским. Слово «мнемотехника» имеет однокоренное слово Мнемозина. Мнемозина – богиня памяти и мать 9 муз в греческой мифологии. Уже в древней Греции успешно применялись мнемотехнические приемы. Древние греки, используя данные приемы, приобретали способность легко и быстро запоминать материал в больших

количествах. И именно древними греками впервые были созданы известные тексты о мнемотехнике.

Также мнемотехникой интересовался Аристотель, он обучал этому искусству своего ученика Александра Македонского. Выдающийся мыслитель Джордано Бруно разрабатывал, изучал и преподавал мнемотехнику. Стоит отметить, что Наполеон Бонапарт и Юлий Цезарь обладали исключительной памятью, благодаря использованию приемов мнемотехники.

Однако особым в истории мнемотехники стал 20 век. По всему миру (кроме России) данный метод стал стремительно развиваться. А в нашей стране, по причине своеобразности советского режима, мнемотехника формировалась скрыто.

Последний серьезный этап в изучении мнемотехники связан с именами таких ученых, как Владимир Козаренко и Самвел Гарибян. Их популярные работы: метод речевых способов Самвела Гарибяна и система визуальной методики «Джордано» Владимира Козаренко – являются одним из самых значимых работ в настоящее время.

Приемы мнемотехники с давних пор применяются во многих областях и на этой основе выделяются основные направления мнемотехники:

- народная мнемотехника;
- классическая мнемотехника;
- педагогическая мнемотехника;
- цирковая (эстрадная) мнемотехника;
- спортивная мнемотехника;
- современная мнемотехника [3: 15, 21].

В настоящее время использование мнемотехнических приемов при обучении школьников различных возрастов является актуальным вопросом в области педагогики. Современный школьник помимо обучения письму, чтению и счету изучает географию, историю, биологию и т.д. и получает большое количество информации по этим областям. Запомнить все простым заучиванием очень сложно, в таком случае информация остается в нашей памяти на короткое время. Использование приемов мнемотехники параллельно с использованием других методов обучения может быть очень полезным.

Далее рассмотрим некоторые мнемотехнические приемы запоминания. Их хорошо описывают Марат Зиганов и Владимир Козаренко в своей работе «Мнемотехника. Запоминание на основе визуального мышления».

Очень действенным методом для школьников считается **метод Цицерона**. Метод Цицерона, основан на естественных ассоциациях, представляет собой последовательность опорных образов. Они формируются припоминанием хорошо знакомых помещений. Необходимо зафиксировать внимание на 10 крупных предметах в комнате, закрепить их в памяти

и повторить. Затем запоминаемые образы и ассоциации «прикрепляются» к выделенным предметам приемом образования ассоциативной связи [2: 15, 21].

Следующий прием – **прием «Цепочка»**. Образы связываются в ассоциации попарно. Размеры образов примерно одинаковые в каждой паре. Когда образуется связь между первым и вторым образом, первый образ убирается из сознания переносом внимания на второй. После этого образуется взаимосвязь между вторым и третьим образом и т.д. Когда цепочка образов припоминается, в сознании возникают сразу по три-пять образов [2: 15, 21].

**Прием «Матрешка»**. Образы соединяются парами. Первый образ ассоциации всегда больше второго и содержит в себе второй. После соединения первого и второго образа нужно перевести свое внимание на второй образ (первый должен исчезнуть из сознания), далее необходимо мысленно увеличить второй образ и создать ассоциацию между вторым и третьим образами. И так далее. Образы постоянно вкладываются друг в друга. При этом в ассоциации всегда должны быть четко видны только два за [2: 15, 21]. Этот метод применяется часто и является очень результативным.

Таким образом, мнемотехника является очень популярным, интересным и простым методом в обучении. Использование этих приемов способствует увеличению объема памяти и ее развитию.

**Литература**

1. Гарибян С. Школа памяти. Суперактивация памяти через возрождение эмоций. – СПб, 1993.

2. Зиганов, М.А., Козаренко В.А. Мнемотехника: Запоминание на основе визуального мышления. – М.: Школа рационального чтения, 2008. – 254 б.

3. Козаренко В.А. Учебник мнемотехники. Система запоминания "Джордано". – М, 2002. – 286 б.

## РОЛЬ РОДНОГО ЯЗЫКА ПРИ ИЗУЧЕНИИ ИНОСТРАННОГО ЯЗЫКА НА ПРИМЕРЕ ЗВУКОВЫХ СИСТЕМ АНГЛИЙСКОГО И ТАТАРСКОГО ЯЗЫКОВ

*Каюмова А., Казань, лицей № 177, XI класс*

*Рук. – Р.Ф. Гатауллина, А.Р. Зайнутдинова*

Не вызывает сомнений тот факт, что язык является основным средством выражения мыслей, эмоций, ощущений каждого человека.

Цель исследования – выявление роли звуковой системы родного языка при изучении иностранного языка. Данная цель предполагает решение следующих **задач**:

1. Изучить сложившееся в специальной литературе мнение, относительно места и формы использования родного языка при изучении иностранного;

2. Определить сформировавшееся к настоящему моменту в методике преподавания иностранного языка мнение относительно роли родного языка в изучении фонетики;

3. Рассмотреть имеющиеся фонетические упражнения в татарском и английском языках и их роль в изучении иностранного языка.

Одним из направлений изучения иностранного языка является опора на базовые знания родного языка, ведь каждый обучающийся имеет определенные навыки говорения на родном языке. Более того, эти базовые навыки находятся в тесной связи со звуковой системой обоих языков. Рассмотрение формата обучения с позиции роли родного языка при овладении иностранными языками представляет определенную **научную новизну** данной работы.

Существует определенное количество звуков, которые сложно воспринимаются детьми и требуют отдельных занятий. Для иллюстрации указанной выше точки зрения, остановимся на звуковых упражнениях, касающихся изучения [ə] и [ж], [ң] и [ŋ], [w], [ө] и [ə:°] , [х] и [h].

Звуки[ə] и [ж]

Оба этих звука присутствуют и в английском, и в татарском языках и требуют определенного навыка произнесения. Для закрепления правильной артикуляции и произношения особое значение имеют скороговорки.

а) Произнесите по несколько раз каждый ряд:

ак-әк, аз-əз, ат-əт, ар-əр, ам-əм;

ак-əк-ук-үк, аз-əз-уз-үз, укы-үке;

Звуки [ң], [ŋ] и [х], [h]

В татарском языке существует отработка пары сходных звуков.

Фонетические упражнения выглядят так:

Произнесите по несколько раз каждый ун-уң, ан-аң, ин-иң; хам-һəм, хас-һəс, хат-һава.

Так же и в английском языке:

Сравните: [ sin ]  sin (грех) – [ siŋ ] sing (петь)

[h] – фарингальный звук. Он образуется в глотке и произносится с придыханием. Близкий к нему звук есть в английском языке: hat, hand, hare.

Этот звук характеризуется как сильное придыхательное начало гласного, поэтому в зависимости от последующего гласного в слове, все органы речи с самого начала занимают положение, нужное для артикуляции последующего гласного: he [hJ] он, who [hH] кто, horse [hLs] лошадь, hard [hRd] твердый, hope [houp] надежда, house [haus] дом, hand [hxnd] рука, help [help] помощь. В положении между двумя гласными звук [h] произносится более звонко: ahead [q'hed] впереди, behave [bI'heIv] вести себя, a house[q'haus] дом.

При объяснении произношения [ө] и [ə:°] также используется созвучие двух языков. Самый близкий вариант татарского [ө] можно встретить в словах 'клён', 'мёд', 'Пётр'. Но в татарском языке [ө] короткий, а русский ['о] встречается только под ударением. Попробуйте данные русские слова произнести как можно короче и с большим огублением, и Вы будете

близки к нужному звуку. Он похож на частый в английском языке звук: bird [bə:d], work [wə:k]. Но английскому звуку не хватает огубленности.

На основании вышеуказанного сделали несколько основных **выводов**:

1. В некоторых случаях родная речь предполагает определенную помощь в изучении иностранного языка, в первую очередь за счет ассоциативных связей при изучении новых слов.

2. Существуют определенные проблемы, связанные с овладением фонетическими (артикуляционными) и грамматическими навыками, обусловленные разноструктурным характером языков.

3. Отработка фонетических упражнений на родном и иностранном языке позволяет сформировать определенные артикуляционные навыки, позволяющие произносить иностранные слова и фразы приближенно к эталонному варианту.

4. И в татарском, и в английском языках существуют определенные упражнения, целью которых является отработка навыка произнесения отдельных звуков. Отдельные виды таких упражнений направлены на формирование определенного звука, другие – на формирование дифференциации с другим, схожим по месту или форме образования.

**Литература**


1. Баранова Е.Н., Дупленко Е.П. О подготовке к межкультурному языковому общению// Педагогика. – 1998. – №1.
2. Брабин Г. Родной язык и мозг// Курьер ЮНЕСКО. – М., Париж. 2002, №3, – С. 12.
3. Щерба Л.В. К вопросу о двуязычии // Щерба Л.В. Языковая система и речевая деятельность. – Л., 1974. – С. 313–318.


## ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ДРАМА ҺӘМ ПРОЗА ӘСӘРЛӘРЕНДӘ МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ


*Кәлимуллина А., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Т.Ш. Гыйлаҗев*


Татар әдәбиятының классик язучысы Г. Исхакый (1878–1954) проза һәм драма әсәрләренең үзәгенә милләт язмышы мәсьәләсен куеп, әлеге проблеманы төрле яссылыкта актырта.

Татар халкы тормышының төрле якларын һәм аңа гына хас булган милли традиция һәм гореф-гадәтләрне, проблемаларны уңышлы чагылдырган "Сөннәтче бабай" (1911) әсәре әдәбиятыбызның гүзәл үрнәге булып тора. "Сөннәтче бабай" – чын мәгънәсендә милли һәм халыкчан әсәр, – дип яза әдәбият галиме И. Нуруллин. Ул татар авылының үзенә генә хас фикерләү рәвешен, хис-тойгы һәм гореф-гадәтләрен белеп язылган" [4: 14]. Автор әлеге әсәре белән әдәбиятта психологизмны яңа төсмерләр белән баета. Хикәядә милли, фәлсәфи проблематикалар чагылыш таба. Сөннәтче бабай образы аша ачылган милли характерның асылы әсәрдә мөһим проблема булып тора. Бу чор әсәрләреннән аермалы

буларак, милли характер, милли менталитет проблемалары тыныч тормыш шартларында сурәтләнә һәм чишелә.

Ислам мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә тасвирланган милли традицияләр һәм гореф-гадәтләр Г. Исхакыйның "Остазбикә" (1915) повестенда да чагылыш таба. Анда татар хатын-кыз бәхете мәсьәләсе үзәккә куелып, ул ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне, кешенең шәхси яшәешен тасвирлау аркылы гәүдәләнеш ала. Әсәрдә кыз сорау, туйга әзерләнү, никахлашу мәҗлесе, ислам диненә караган традицион йолалар тасвирлана, милли проблематика белән беррәттән иҗтимагый-әхлакый мәсьәләләргә дә игътибар ителә. Әсәрнең бу аспекты хакында Т. Гыйлаҗев болай дип яза: “Төп сюжет сызыгы аркылы “Сәгыйдә кебек татар хатын-кызлары милләтне инкыйраздан, юкка чыгудан коткарып калучылар, аның иҗтимагый-мәдәни яңарышына, үсешенә, икътисади алгарышына җирлек әзерләүчеләр” дигән гомумиләштерүче нәтиҗә ясала” [2: 161].

Г. Исхакыйның бер төркем драма әсәрләрендә милләт язмышы тарихи һәм иҗтимагый-әхлакый контекстта чагыла. “Г. Исхакыйның икенче төр пьесаларында көчле яктыртылган теманы “милләт язмышы” дип атап, “Милләтне алга җибәрү өчен ниләр эшләргә кирәк?” дигән сорау белән билгеләп булыр иде” [1: 40], – дип яза күренекле әдәбият белгече А. Әхмәдуллин. Драматург “Өч хатын белән тормыш” (1900) "Алдым-бирдем” (1907), "Зөләйха” (1912), “Мөгаллимә” (1913) әсәрләрендә татар халкының иҗтимагый һәм рухи яңарышын хатын-кыз проблемалары белән аерылгысыз бәйләнештә карап, ул бу мәсьәләне татар әдәбиятының иң мөһим мәсьәләләреннән берсе итеп күтәрә. Автор беренче пьесада иске татар тормышы тәртипләре, гореф-гадәтләре аркасында михнәтле яшәешкә дучар ителеп тә, күңел аклыгы, кешелекле сыйфатлары белән рухи өстенлеккә чыккан Әсманы тасвирлый, ә икенчесендә үз бәхете өчен көрәштә җиңгән Галия образы аркылы “Гаилә саф мәхәббәткә, тигезлеккә нигезләгәндә генә, бәхетле һәм тотрыклы була ала” дигән карашны яклый. Татар әдәбиятына тема һәм жанр яңалыгы алып килгән “Зөләйха” трагедиясендә милләтне дин һәм вөҗдан ирегенә ирешү аша саклап калу проблемасын яктыртса, әдәбитәнкыйди фикердә зур бәхәс кузгаткан “Мөгаллимә” драмасында исә милләткә хезмәт итү хакына үз шәхси бәхетеннән баш тарткан мөгаллимә Фатыйма образын үзәккә куя [3: 87]. Әлеге тип проблематикалы әсәрләрдә язучыны кешенең яшәеш позициясе һәм аның үзгәрүе кызыксындыра. Әсәрләрнең үзәгендә фәлсәфи һәм этик эзләнү, кешенең яшәү мәгънәсе, яхшылык һәм яманлык, дөреслек һәм гаделлек хакында уйланулары тора.

Г. Исхакый татар әдәбиятында беренчеләрдән булып катнаш гаилә проблемасын күтәреп чыга. Катнаш никахның милләт язмышына

йогынтысы "Ул икеләнә иде” (1914), "Ул әле өйләнмәгән иде”(1916) повестьларында ачык күзәтелә. Әсәрләрдә куелган проблема һәм аның чишелеше бу ике әсәрне берләштереп тора. Повестьлар өчен уртак проблематика икенче әсәрдә тулырак һәм эзлеклерәк яктыртыла. Катнаш никах һәм милләтара мәхәббәт проблемалары төрле яссылыктан чыгып анализлана. Г. Исхакый үзенең геройларының каршылыклы уй-тойгыларын һәм фикер көрәшен, шәхси драмаларын милләт фаҗигасе дәрәҗәсенә күтәрә.

Димәк, Гаяз Исхакый үз әсәрләрендә укучының игътибарын халыкның милли яшәешенә, күркәм гореф-гадәтләренә, милли йолаларына, нәсел-нәсәбәсенә, борынгы тамырларына юнәлтә. Язучы әсәрләрен халыкның милли үзаңын уяту һәм шул юл белән аның азатлыгына ирешү максатында яза. Халык, милләт язмышы турында уйланганда, драматург еш кына хатын-кыз мәсьәләсенә игътибар итә. Гаиләне, җәмгыятьне хатын-кыздан башка күз алдына китереп булмый. Хатын-кызның уңай роленнән башка үсеш-үзгәреш, прогресс була алмас иде. Татар мәгърифәтчеләре, җәдитчеләре моның асылын дөрес тоеп алалар. Әдип әсәрләренә гомуми күзәтү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, ул хатын-кызның ир-ат белән тигез хокуклы булмавын инкыйразга алып баручы җитди сәбәпләрнең берсе итеп таный. Хатын-кызны хөрмәт итмәгән, аның ирекле зат икәнлеген, шәхес булуын, милләтнең киләчәген – балаларны тәрбияләүче булуын танымаган милләтнең киләчәге өметсез булуын искәртә.

**Әдәбият**

1. Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 239 б.

2. Гыйлаҗев Т.Ш. XX гасыр башы әдәбияты // Татар әдәбияты. Теория. Тарих. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – Б. 138–204.

3. Мусин Ф. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 191 б.

4. Нуруллин И. Гаяз Исхакый // Исхакый Г. Зиндан: Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – Б. 5–18.

## МИН КУЛЫМА КИТАП АЛАМ

*Кәримова А., Арча р-ны Шушмабаш урта мәктәбе, X сыйныф*

*Җит. – Т.Ә. Сабитова, Ф.С. Мортазина*

Мин Арча кызы, төгәлрәк әйтсәк, Шушмабаш авылыннан. Казан арты төбәгеннән булуым белән чиксез горурланам, чөнки безнең як кешеләре мәгърифәтлелеге, миллилеге, зыялылыгы белән аерылып торалар.

Бөек шагыйребез Г. Тукайның «Халык зур ул…» сүзләре арчалыларның холкын бик тирән чагылдыра. Тыныч хезмәттә дә, яу кырында да, мәдәнияттә һәм мәгърифәттә дә, сәнгать һәм әдәбиятта да, спортта һәм, гомумән, һәр җирдә дә Арча халкы шуны даими раслап килә.

Мин аның күпкырлы иҗаты белән кызыксынган, аны ихтирам иткән Арча районында яшәүче үзешчән  шагыйрьләрнең иҗат җимешләрен өйрәнүне **максат** итеп куйдым.

Арча районы мәгариф хезмәткәрләре профсоюз оешмасы тарафыннан Г. Тукайның 130 еллыгына багышлап бастырылган “Илһам чишмәсе” китабы-на укытучылар һәм тәрбиячеләр тарафыннан иҗат ителгән шигырьләр тупланган. Шигырьләр белән танышкач, аларда мәктәп еллары, үзең белем һәм тәрбия биргән балаларны ярату хисләре, яшьлек, хезмәт, авылларыбыз-ның матурлыгы да сөйләнелә. Мине тагын да куандырганы шул: “Илһам чишмәсе” дип аталган китапта укытучыларымның да иҗат җимешләре бар.

Таныштыруны тәмам итеп, анализлау этабына күчик. Һәрберебез кече яшьтән үк балалар бакчасында һәм мәктәпләрдә сөекле шагыйребезнең әсәрләрен укып һәм дә ятлап үсәбез. Югарыда әйтелгән җыентыкта шул әкиятләр геройлары яки шул әкияткә ияреп язылган  шигырьләр иң күбе.

| *ӘСӘРНЕҢ БЕР ГЕРОЕ ТУРЫНДА* | |
|---|---|
| **Түбән Аты шүрәлесе**<br>Урманга килеп кергәч ,бер зат күренә искитмәле:<br>Яхшылабрак караса егет – бу бит таныш Шүрәле!<br>“Ир-егет, хәйләләп, кулны кыстың – ышануыма үкенәм....<br>Әнә шулай сөйләштеләр Былтыр белән Шүрәле.<br>Ышанмасаң, кариэм, үзең Түбән Атыга кил, яме!<br>*Хәмидуллина З. Я.Түбән Аты мәктәбе укытучысы* | **Шүрәле** (Тукайга ияреп)<br>Нәкъ Казан артында бардыр<br>Бер авыл-Кырлай диләр...<br>Котырган төлкеләр очрар,<br>Ялгыз барма син, балам....<br>Гамьсезлекне күргән саен,<br>Читкә бормый йөзебезне.<br>*Галәветдинова В Р,*<br>*Яңа Кырлай мәктәбе ветеран укытучысы* |

Безнең белем өлкәсендә тир түгүче хезмәткәрләребез дә килешә, Тукаебыз белән әңгәмә кора.

*ТУКАЙ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ*

| **Тукайга бездән сәлам** | **Тукай һәм тел.** |
|---|---|
| Якташ, сәлам! Сиңа Өчиленең<br>Яз сәламен кушып җибәрәм.<br>Тагын җитте апрель. Син генә юк,<br>Авылдашлар сине көтәләр...<br>Синең нигез исән, ул да көтә,<br>Анда яңа бер йорт коралар.<br>*Зыятов А.Ф.Өчиле мәктәбе укытучысы* | Тукай, синнән күпне белдем мин<br>Нигез итеп туган телемне.<br>Ул гына аз, җитмәс диеп белем<br>Үстерергә туган илемне.<br>Тукай, синең якташың бит мин дә,<br>Тыңлап ярсу йөрәк тибешемне,<br>*Хәкимҗанова Р.Р. Ташкичү мәктәбе* |

Тукайны Казан артының Арча, Әтнә якларыннын башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Ул яклар шагыйрьнең гомер бишеге генә түгел, аңа беренче шат-лык-кайгы хисләрен татыткан, иҗат сәләте биргән җирләр.Кушлавыч – Өчиле – Кырлай... Арча районы территориясенә кергән бу авыллар Габдулланың балачак биографиясендәге төп урыннар.

Биредә бүгенге көндә дә шагыйрьнең тормышына кагылышлы истәлекле биналарны саклыйлар.

*ТУКАЙ ЯШӘГӘН АВЫЛЛАР*

| **Кырлай юлы** | **Иман нурлы Кырлаем** |
|---|---|
| Тирә якта каен агачлары,<br>Уңда, сулда тезелеп калалар...<br>Бу юлларны Тукай абый<br>Гел сагынып яшәгәндер<br>Һәр каены сагыш булып<br>Күңелендә яшнәгәндер.<br>*Ганиева С.Х. Носы мәктәбе укытучысы* | Ятим Апушны сыйдырып,<br>Биргән ул җан җылысы...<br>Тукай рухын саклап яши<br>Кечесе вә олысы.<br>Шундый Аллаһ йорты булу-<br>Авылыма зур бәхет.<br>*Насретдинова Р.Г. Яңа Кырлай мәктәбе* |

Исәнмесез, Тукай бабай!

Сезгә гади бер татар кызы хат яза. Сезнең шигырьләрегезне яратып укыйм. Әкиятләрегез дә кызыклы. Аңламаган сүзләрне, аерым җөмләләрне мин әбидән һәм укытучылардан сорыйм.

Сөекле Тукай әфәнде, без Сезне онытмыйбыз.Үзегез турында да күп кенә әсәрләр, шигырьләр яздылар инде. Кемнәр язган дип уйлыйсызмы? Мин яшәгән Арча районының тәрбиячеләре һәм укытучылары.Алар да нәкъ тә сезнең кебек туган телебез һәм милләтебез турындагы фикерләрен шигъри юлга салдылар.

Сез гел безнең күңелдә яшисез.”Сау булып торыгыз ”, дия алмасам да, сезгә ихтирам белән, Алинә.

Эшкә нәтиҗә ясаганда немец язучысы Иоганн Петер Эккерман сүзләрен куллану урынлы булыр дип уйлыйм. “От всех приобретенных знаний в памяти у нас остается только то, что мы применили на практике”. “Барлык алынган белемнәрдән безнең хәтердә бары тик кулланып караганнары гына истә кала”.

Бүгенге көндә милләт буларак исән булуыбызның, туган телебезне саклап кала алуыбызның һәм башка бик күп яхшы сыйфатларыбызның да нигезендә авыл һәм аның әхлагы ята. Авылларны һәм телебезне яшәтүгә үзләреннән зур өлеш кертүчеләр дә әдәбиятка һәм сәнгатькә гашыйк (үзешчән шагыйрьләр) кешеләр.

## М. ӘУЕЗОВ ДРАМАЛАРЫНДАҒЫ ВЕСТИАЛДЫ ЛЕКСИКАНЫҢ РӨЛІ

*Көшімбет М., Ақтөбе Мемлекеттік университеті, ІІ курс магистрі*

*Ғыл. жет. – фил. ғыл. канд., доц. Б.С. Қарағұлова*

Кейіпкер болмысын, мінез-құлқын айқын танытатын тәсіл – портрет. Көркем шығармада автор кейіпкерін тікелей өзі суреттейді. Авторлық мінездеме – көркем шығарманың тұрақты компонеттерінің бірі. Авторлық мәнездеу құрамына кейіпкердің сыртқы кескін-келбетін, жүріс-тұрысын, мінез-құлқын зерттеу жатады. Көркем шығармада кейіпкердің образын ашу үшін тек бір ғана тәсіл қолданылмайды, барлық амал-тәсілдердің

жиынтығы кейіпкер сомдауға әсер етеді. Портрет – кең ауқымды ұғым. Әдебиеттегі портретті өнердің бейнелеу, сурет жанрдағы портретпен салыстыру басым. Сол арқылы әдеби портреттің сыр-сипаты, ерекшелігі танылa түседі. Ең айрықша ерекшеленетін тұсы – бейнелеу өнерінде портрет қылқалам мен бояудың күшімен шықса, әдебиеттегі портрет сөзге сүйенеді. Сөздің сиқырлы күшімен кейіпкердің образы қаланып, қырланады. Көркемсөз иесі кейіпкер тұрысын, қимылын, қозғалысын, киімін, дауыс мәнерін беру арқылы оның ішкі әлемін бойлайды.

Портреттің ерекшеліктері көркем шығарма кейіпкерінің сыртқы бейнесі ретінде, атап айтқанда, оларды кескіндемедегі портрет ерекшелігімен салыстыруда анықталады. Мұндай салыстыру портреттің негізгі компоненттері кескіндеме және көркем әдебиетте: I) адамның денесі және оның бөліктері; 2) киім, аяқ киім, бас киімдер; 3) мимика, қалыптар, қаңылтыр. Бұл сөздерді портреттің номинативті компоненттерімен шартты түрде атаймыз. Портреттің қандай да бір компонентінің белгісін көрсететін сөздерді сипаттайтын сөздермен атаймыз [1: 22].

Сипаттаушы сөздер – кейіпкер болмысын, тұлғасын оқырманға айқын танытатын тілдік амал. Сипаттаушы сөздер кейіпкерлердің кескін келбетін, киген киімін анықтай, түстей танытады. Олар компоненттерді түрлі қырынан айқындап, дәлелдейді. Портреттік суреттеулерде сипаттаушы сөздердің қызметі ерекше. Сипаттаушы сөздер екі түрлі белгіні атап көрсете алады: 1) портрет компоненттерінің сыртқы физикалық белгілерін (ұзын көйлек, тостаған көз, жалпақ бет). Бұл топтағы психикалық, эмоциялық ерекшеліктерін атайтын белгілер (мейірлі көз, ісмер саусақ). Бұл ішкі белгілер деп аталады. Лингистикалық әдебиеттерде бұл белгілер басқаша терминдермен де аталады.

Қазақ халқында халықтық табиғат қорғау дәстүрі ертеден бері сақталған. «Елім бай болсын десең, жеріңнің бабын тап» деген халық мақалын есте ұстаған ата-бабамыз күздеуге, көктеуге, жайлауға және қыстауға көшіп, қонысын аударып отырған. Мұның түбірі жердің шөбін қалпында сақтап, қорын азайтпауда жатыр. Қорқыт бабамыз жерді бүлдіріп қаза беруден сақтандырып, «У шығып кетеді» деп бәйек болуы, Асан қайғының халқына жайлы қоныс іздеп, желмаясымен жерді кезуі тегін емес қой. Ал осы бабаларымыздың бізге мұра қылып қалдырған жерінің бүгінгі халі қандай? Бүгінгі таңда жер бетіндегі күллі Адам баласын толғандырып отырған, толғағы жеткен өзекті мәлелердің негізгісі табиғат тағдыры болып отыр.

Жалпы білім беретін мектептерде білім мен тәрбие беру және оларды экологиялық мәліметтермен толықтыру мұғалім арқылы жүзеге асады. Ол үшін мұғалім де, оқушылар да өткен сабақтардан көгеріп өсіп, жан дүниесі тазарып «Туған жеріне туын тігетін» нағыз патриот болып шығуды мақсат ету керек. Сонда ғана жеріміз көркейіп, ағашымыз бүр жарып, бұлағымыздың көзі ашылып, экологиялық білім мен тәрбие аламыз. Ол үшін өзім беретін сыныптарда дәстүрлі емес сабақ: сырттай саяхатқа шығу, суретті альбом жасау, реферат қорғау, анкеталық сұрақтар арқылы сұрау, шығарма жаздыру сияқты жұмыстар жүргізіп білім мен тәрбие беруге тырыстым.

Бағдарлама бойынша «Ақсақ киік», «Толағай», «Бүркітші», «Өзек», «Қансонарда бүркітші шығады аңға», «Акулар ұйықтағанда», «Абайдың табиғат лирикасы» тақырыптары арқылы оқушылардың мақсаттарын қанатандырып, арман-тілегін жетелеп, жақсылыққа сендіріп, өз беттерінше жұмыс істеулеріне жол ашып, толығынан экологиялық бағыт беруге тырыстым. «Табиғаттың жан даусын шығармайық» атты дөңгелек үстел

ұйымдастырылды. Бұл дөңгелек үстелде тек өзіміздің, Батыс аймағының экологиясы әңгіме болды.

Табиғатты қадірлеген халық бізге оны сүюді, қорғауды міндет қылды. Сондықтан «Жалғыз ағашты шаппа», «Жер ананы қорға», «Бұлақ көрсең көзін аш, сауабы тиер» деген тыйым сөздермен оқушы бойына табиғатты қорғай, аялай жүру керектігін сіңіре білген жөн. Осындай үздіксіз тәлім-тәрбие және терең білім беріп отырсақ, оқушылар бұлақ көзін аша жүрер, бақша өсіріп, нұрға бөлендірер деген ойдамын.

Біздің Отанымыз – егеменді, тәуелсіз мемлекет. Асқақтаған Алатауы, кеңшілігі кермет, дархан дастарқандай далада егіні теңіздей толқыған, төрт түлігі мыңғырған, өндірісі өркендеген мекенде өмір сүруді армандасақ, өз Отанын сүйіп, Көк байрағын көкке көтеруді мақсат ететін шәкірт тәрбиелеп оқыту – біздің ең бірінші міндетіміз. Елбасы Н.Назарбаев Жолдауында «Бабалардың Отанды, туған жерді, өзінің халқын сүюге тәрбиелеу - мұғалімнің аса маңызды да жауапты, қадірменді парызы» екендігі баса айтылған. Осы орайда, жас ұрпақты оқытуға, тәрбиелеуге және жеке тұлға ретінде жан-жақты дамуына ықпал ету үшін әрі қарай осы бағытта тереңірек жұмыстанамын деп ойлаймын.

**Әдебиет**


1. Айтжанова Құттыгүл. Қазақ әдебиетінің әдіснамасы. Оқу құралы. – Алматы: Ғылым баспа орталығы, 2002. – 326 б.
2. Әрінова Б.А. Қазақ әдебиетін оқыту әдістемесінің ғылым ретінде қалыптасуы мен дамуы. – Алматы: Жазушы, 2004. – 316 б.


## ТАТАР ҺӘМ КАЗАХ ЛИНГВОМӘДӘНИЯТЕНДӘ ИСӘНЛӘШҮ ЙОЛАЛАРЫ


*Сымахэцзань Илиясы, КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Г.Ә. Нәбиуллина*


Милләтне милләт итүче факторларның берсе тел булса, икенчесе, һичшиксез, гореф-гадәтләр. Теге яки бу халыкның үткәне дә, бүгенгесе дә милли традицияләрдә ачык чагыла. Татар халкының борынгы гореф-гадәтләре бик күп. Шулар арасында сәламләшү, хушлашу сөйләм жанрына бәйле гадәтләр.

Туган-тумачаң, күрше-күлән, дус-иш, таныш-белешең белән исәнләшү, хәтта бер дә белмәгән кешегә сәлам биреп узу – элек-электән килгән күркәм гадәт. Һәр халыкның үз милли традицияләре, гореф-гадәтләре бар. Әмма һәр халык исәнләшүне үзенчә аңлата Мәсәлән, *"исәнмесез", "әссәламәгаләйкум", "сәлам", "хәерле көн", "сау булыгыз"*. Инглизләр “*һеллоу*”, гарәпләр “*әссәламегаләйкем*”, урыслар “*привет*”, “*здравствуйте*”, яһүдиләр “*шоломалейкем*” (“мир вам”) дип сәламли.

Татарларда исәнләшү формалары күп төрле. Иң еш кулланыла торганы – “*исәнмесез”, “саумысыз*”. Авыл халкы, гадәттә, кешенең исемен

әйтеп сәламли. *“Габдрахман, исәнме*”, *“ни хәлләрдә яшисез*”, *“ни хәлләрегез бар”, “исән- саулармы барыгыз да”, “сәлам бирдек”, “хәерле иртә”, “хәерле көн”, “хәерле кич”.*

Исәнләшү тирән мәгънәгә ия. “*Исәнмесез”, “Саумысыз*” дип әйтү генә дә кешенең сәламәтлегенә, исән-имин йөрүенә ниндидер бер сөенү хисен аңлата. Моннан үзең дә канәгатьләнү аласың, кешеләр белән шулай аралашып, күрешеп йөрүеңә сөенәсең.

Исәнләшкәндә, стандартлашкан түбәндәге сөйләм формулалары актив кулланыла: *Исәнме! Исәнмесез! Саумысыз! Әссәләмәгаләйкем! Сәлам! Исәннәрмесез! Хәерле көн! Хәерле кич! Нихәл? Нихәлләр?* һ.б. Олы кешегә яшь кеше *Сәлам!* дип әйтмәс, әлбәттә. *Исәннәрмесез!* дигәне дә бик үк зыялы түгел. *Саумысез!* дигәне дә бераз гади сөйләмгә хас күренеш. *Нихәл?* дип әйтү бөтенләй гади сөйләм дәрәҗәсенә төшерү була. *Әссәламугаләйкум!* дип картларга, дини сферада гына әйтү урынлы.

Сөйләм этикетының милли үзенчәлеге – аның мәгънәви эквивалент формаларының үзенчәлекле белдерү планы. Татар *”Хуш килдегез! Керегез! Түргә үтегез!*” дисә, рус “*Добро пожаловать! Заходите! Проходите!”* дип әйтә. Үзенчәлек – татар телендә ишек төбендә торырга ярамый, өйнең түренә -мактаулы җиргә үтәргә тәкъдим ясала.

Каюм Насыйри – XIX йөз татар мәгърифәтчеләре арасында иң алдынгысы һәм эшлеклесе. "Китаб-әт-тәрбия" хезмәтендә галим әдәп-әхлак турында йөз унөч үгет-нәсыйхәт туплый. Ул: "Сәлам бирсәң, ишеттереп бир, сәлам алсаң, ишеттереп ал. Ягъни сәламне ишеттереп бирмәсәң, гүяки син сәлам бирмәдең, әгәр ишеттереп алмасаң, шулай ук сәламне алмаган кебек буладыр", – дип әйтә. Әгәр бер кеше дә булмаган бер өйгә барып керсәң дә, сәлам бирү тиеш. Мәгърифәтче, педагог, язучы Ризаэддин Фәхреддин дә тәрбия эшенә күп игътибар бирә. Балаларга үгет-нәсыйхәтләрендә ул болай яза: "Мөселманнар бер-берләре белән очрашканда "*Әссәламегаләйкум"* дип сәламләшерләр. Сәламнән соң мөселманнар бер-берләрен кулдан кысарлар. Сәлам биргән кешегә "*вәгаләйкемсәлам*" дип җавап кайтару фарыз.

Казахларда исәнләшүнең берничә төре бар. Алар "гәүдә тигезү", "кул алып исәнләшү", "маңгайдан иснәү", "күздән үбү", "кулдан үбү" һ.б. "Гәүдә тигезеп" ир-атлар, батырлар исәнләшкән. Ул "Мин сиңа хөрмәттәмен" дигән мәгънә бирә. Яшьләр олы кешеләргә беренче булып, кул биреп исәнләшү тиешле. Ә яшьләр арасында шулай исәнләшү - дуслык хөрмәт билгесе булып санала.

Яше олы булган әби-бабайлар үзләренең оныкларның "күзләренең яки кулларыннан үбеп", "майгайларыннан үбеп" исәнләшкән. Бу иркәләтүнең бер билгесе. Казакларда кешенең яшенә бәйле исәнләшү бик мөһим роль уйный. Олы, урта һәм кече яшьтәге кешеләр белән исәнләшү

төрлечә була. Мәсәлән, "*Амансыз ба? (Исәнмесез?), Амансың ба? (Исәнсең ме?), Аман ба? (Исән ме?)"* дигән исәнләшүгә *"Аманбыз" ("Исәнбез"), "Үздериңиз аман-саумысыз?" ("Үзегез исән-саумысыз?")* дип җавап бирeләр. Гадәттә ике кеше очрашканда, яшь кеше "*Әссәләме гәләйкөм*" дип сәлам бирергә тиеш. Олы яшьтәге кеше исә, җавап итеп, "*Вәгәләйкем әссәләм*" дип, сәламли.

Казах халкында үзенә генә хас булган исәнләшүнең бер үзенчәлеге бар – киленнең кайната-кайнанасына һәм ир ягындагы туганнарына сәлам бирүе. Хөрмәт күрсәтеп, килен кеше үзенең кайната һәм кайнанасына бөгелеп башын аска аска иеп сәлам салуы. Алар шул вакытта: "Б*әхетле бул!",«Көп яша!» "Угыл тап*!" дигән теләкләрен белдерәләр.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, татар һәм казах халыклары исәнләшү йолаларына бай.

## УЙГЫРЛАР: МӘДӘНИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ

*Сяфукатэ Иэрцзати, КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Р.С. Нурмөхәммәтова*

Уйгырлар хәзерге Кытай Республикасының Шенҗан-Уйгыр автоном районында яшәүче җирле халык. Диннәре буенча алар – сөнни мөселманнар. Уйгыр теле төрки телләр группасына керә.

Уйгырларның традицион эшчәнлеге – сату-итү, игенчелек, терлекчелек, һәм башка төрле һөнәр төрләре. Лобнор уйгырларына балыкчылык һәм аучылык та хас.

Уйгырлар бай һәм үзенчәлелк мәдәният барлыкка китергәннәр һәм бу мәдәният, үз чиратында, бик күп Көнчыгыш, Шәрык мәдәниятларына йогынты ясаган.

Борынгы уйгырларның музыкаль мәдәнияте үзәгендә «12 мукам» (бик борынгы, комплекслы, поэтик инструмнталь музыка төре, бер-юерсенә бәйле 12 өлештән тора) тора. Шулай ук бик күп,уйгырларда меңләрчә җыр, халык инструменталь музыка әсәрләре һ.б. да бар. Уйгыр халык музыкаль инструментларыннан – тамбир, дутар, равап, сатар, геджак, най, дап һ. б. билгеле.

Борынгыдан уйгыр халкының милли әдәбияты бик бай . Алар арасындафольклор, проза, поэзия, дини әдәбият (буддизм һәм манихей дини текстлары тәрҗемәләре) үрнәкләре күп. Уйгыр классик әдәбият булып исәпләнгән исләлекләрең гаять зур өлешен уртак төрки мирас булган Урта Азия халкы әдәбияты тәшкил итә. Шундыйлардан Йосыф Баласагунлының «Котадгу белиг» поэмасы (11 гаср), Әхмәт Йүгнәкиның «Хакыйкать бүләге» этник-дидактик поэмасы (12 гаср азагы 13гаср башы.). Уйгыр язучылары һәм шагыйрьләре арасында төрки дөньяга танылган Билал Наизм, Зия Самади, Латфулла Муталлип, Изим Искандеро һ.б.бар.

Мәшрәп – уйгурларның иң борынгы гореф-гадәтләренең берсе, икенче төрле әйткәндә ул ял итү кичәсе. Ул соң көздән алып язга кадәр

дәвам итә. Мәшрәп – ул этик һәм эстетик тәрбия бирү мәктәбе. Ул музыкага, җырга яки шигырьләр язу осталыгы булган кешеләрне ачырга ярдәм итә. Шулай ук монда егетләрне тәртип сакларга һәм җаваплы булырга өйрәтәләр. Җыелыш башында катнашучылар тарафыннан «Җигит беши» – *егет башы* сайланыла. Үз чиратында ул җырчы, биюче яки аш пешерүчене билгели ала. «Җигит беши» белән беррәтән «кази» да сайланыла һәм ул, кирәк булган очракларда, «Мәшрәп»тә катнашучыларны хөкем итәргә тиеш.

Мондый җыелышлар милли җырлар, мукамлар һәм милли биюләр белән үза. Әлеге җыелышта катнашучылар бер-берсе белән аралашудан үзләренә күп кенә файдалы мәгълүмат алалар. Бәлки шуңа күрәдер, надан кешеләрне уйгурлар «мәшрәп көрмигән» дип атыйлар. Шул ук вакытта, мондагы кешеләр һәрвакытта да бер-берсенә ярдәмгә килергә әзер, кайчак «мәшрәптәге» кешеләр бер-берсенә туганнардан да якынрак була ала.

Уйгурлар арасында хәзерге вакытка кадәр ирләр арасынды берләшмәләр булдыру киң таралаган күренеш. Мәсәлән «Отуз огул». Уйгур теленнән тәрҗемә иткәндә «Отуз огул» – утыз угыл яки утыз егет дигәнне аңлата. Гадәттә, берләшмәгә билгеле бер яштә булган егетләр керә, аларның башлыклары шулар арасыннан сайланыла. «Отуз огул» максатлары – ул берләшмәгә кергән кешеләргә һәряклап ярдәм күрсәтү.

Уйгурлар тарихын өйрәнү өчен кызыклы һәм мөхим булган дивар язулары табыла. Аларның ясалышына карап уйгур дәүләтләрнең социаль-сәяси, культур дәрәҗәсе турныда нәтиҗәләр ясап була. Мәсьәлән, бер тау куышы диварларында уйгур аристократлары, тулы гәүдәле, бәләкәй генә сакаллы һәм мыеклы ир кеше сүрәтләнгән. Аның социаль статусы турында, озын формалы баш киеме һәм ачык түстәге кыйбатлы материалдан тегелгән өс киеме аша белеп була.

Уйгыр мәдәнияте бик бай һәм үзенчәлекле мздзнният аны фәнни яктан өйрәнү кызыклы һәм фән өчен актуаль мәсьәлә булып санала.

**Әдәбият**

1. Кононов А.Н. История изучения тюркских языков в России: дооктябрьский период. – М.: Наука, 1972. – 344 с.

## КӨРКЕМ МӘТІНДЕГІ КЕЙІПКЕР БЕЙНЕСІ

*Тилеуова Н., «Тұран-Астана» университеті, IV курс студенті*

*Ғыл. жет. – фил. ғыл. канд., проф. Г.Т. Карипжанова*

Контексте белгілі бір жүк арқалап, айтылмақ ойға әсерлі үн үстейтін әсерлі сөздер экспрессоид деп аталады. А. Байтұрсыновтың тілімен айтсақ, «көңіл күйінен шығып, көңілге күй түсіретін сөздер» [1: 26]. Р. Сыздық: «Экспрессоид-белгілі бір стильдік мақсатпен қолданылған, оқырманға әсер ететін, экспрессиялы сөздер немесе тұлғалар, тіркестер» [2: 45] деген анықтама береді. «Ақбілек» романындағы экспрессоидтардан

мысал келтірсек: *«Мамырбайдың бәйбішесі маң-маң басып,малайларға киіз үйін қағып-сілкіп,жинатқызып жүрген еді. Мамырбайдың Ақбілегі, Ақбілегі-жас түлегі, айы- күні-жалғыз қызы алтын сырға, күміс шолпы сылдырлатып, ақ көйлегін көлеңдетіп, қызыл-жасыл көрпелерін қағып үйге әкелген еді.»* [3: 34]. Бұл үзіндіде қыстауға қонып жатқандағы Мамырбайдың бәйбішесі мен қызының қимылдарын берудегі автор шеберлігіне көңіл аударайық. Бәйбішенің маң-маң басуы дәл қолданылған сөз, бұл сөз бәйбішенің жас ерекшелігіне сай жүрісін ғана емес,сондай-ақ оның сабырлылығын,маңғаздығын да танытады. Ал Ақбілектің шолпысын сылдырлатып, көйлегін көлеңдетіп жүруін беру арқылы оның сұлулығымен қатар әдептілігін де көрсетеді. Автордың кейіпкеріне немесе кейіпкердің кейіпкерге деген қатынасын берудегі экспрессоидтардың рөлі ерекше. Мысалы: *«Молда деген аты болмаса, Тезекбай кісі атын да жаза алмайды. Барлық оқуы «қырық қадістен» есінде қалған «қаланнаби ғалайссалам»-айтты пайғамбар ғалайссалам. Бар білген құлшылығы-өлікке, шелпекке, өлі тиген малға «жасын» оқу, тарауық оқығанда, «алқамға» қосып «еттеқазелиге» деген бірдеңені міңгірлету»* [3: 36]. Бұл үзіндіде автор Тезекбай молданың надандығын, дүмшелігін таныту мақсатында «есінде қалған «қаланнаби ғалайссалам»-айтты пайғамбар ғалайссалам» деген сөздерді қолданса, мұны аса нақ танытатын экспрессоид «міңгірлету» етістігі. «Міңгірлету» сөзі арқылы автор Тезекбай молданың оқуын, молдалылығын кекетіп, білімінің таяздығын мысқылдайды.

*Жылдағы зекет, пітір садақасын беріп, бізді оқытуға әкеміз таңқы мұрын, жылтыр қара қожаны ұстап, сегіз жылдай жаз үй артындағы қоста, қыс қонақ үйде теңселіп, қалғып-шұлғып сабақ оқыдық»* [3: 45]. Бұл сөйлемде автор «теңселіп, қалғып-шұлғып» экспрессоидтарын қолдана отырып, қара қожаның оқуы нәтижесіз болғанын жеткізеді.

«*Маңдайы қалқиып, мойны қаздиып, көзі мөлдіреп, ерні үлдіреп, үріп ауызға салғандай жұтынып тұр еді-ау. Шашбауын сылдыр еткізіп, сып етіп түрегелгені, тізесімен ақ көйлегін серпе тастап, аяңшыл бедеудей кербездене аяқ басқаны, тысқарыда жүріп, жеңгесімен сыбырлап сөйлесіп, дауысы күмістей сыңғырлап тәп-тәтті күлгені, әнтек жымиып келіп, шай жасап, өп-өтірік сызылғансып үш саусағының ұшымен шыны-аяқ әпергені, салалы қою кірпігін салмақпен қағып...*» [3: 47]. Бұл үзінді тізбектелген экспрессоидтар шоғыры, әрі автор оларды Ақбілектің сұлулығын, ибалылығын, қылықтылығын, әдептілігін т.б. таныту мақсатында жұмсаған. Мысалы: «қоқиып,қаздиып, мөлдіреп..» экспрессоидтары Ақбілектің сұлулығын, «сылдыр еткізіп, сып етіп, кербездене, сыңғырлап» экспрессоидтары әдептілігін, ал «әнтек жымиып, сызылғансып» экспрессоидтары қылықтылығын танытады. Бұл ретте экспрессоидтар жағымды я жағымсыз эмоцияларды таңбалайтынын

ескерсек. Бұл үзіндіде автор Бекболаттың көзімен Ақбілекке баға береді, яғни автор экспрессоидтарды қолдана отырып кейіпкерге деген өз қатынасын ғана емес, басқа кейіпкердің де қатынасын көрсетеді. Жүсіпбек Аймауытов психолог жазушы ретінде кейіпкерлер бейнесін ашуда олардың қимылдарын, сөздерін, әдеттерін ұтымды қолдана білген суреткер. «Ақбілек» романындағы Бозінген бейнесін жасаудағы автор шеберлігіне бас имеу мүмкін емес. Мысалы: *«Тек Бозінгеннің қара бойында титтей ғана міні бар еді, өз басының киім-кешегі болмаса, өзге шаруаға әнтек қыры жоқеді. Таза көрпелері салтақ-салтақ боп, төсек орны жуырда жиылмай,* ***қоқып, ыбырсып*** *жатар еді.»* [3: 63]. Мұндағы «титтей» сөзін қолдана отырып автор Бозінгенді мысқылдайды, яғни керісінше мағынада қолданады. Ал келесі сөйлемнің етістіктерінің барлығы дерлік экспрессоид. Ол арқылы Ж.Аймауытов Бозінгеннің салақтығын, шаруаға қыры жоқтығын көрсетеді. Ал *«Бозінген әлдебір қызық өсек айтады екен деп, кимешегін желкесіне қарай бір тартып, жампаңдап, құлағын таяй берді »*деген сөйлемде Бозінгеннің өсекқұмарлығын танытуда автордың «кимешегін желкесіне қарай бір тартып, жалпаңдап» деген сөздерді қолдануы орынды. *«Сөйткенше болмады, «күйеу келді» дегеннен жаман Бозінген апыраңдап түрегелңп, жалма-жан ауыз үйге барып, Күмсінайға қайталатып бір аяқ ұн салып берді.»,*немесе *«Өз үйіне түгел естірген соң, бұл хабарды ішіне сыйғыза алмай, Бозінген бошалаған түйеше тайраңдай басып, екі қолын құлаштай сермеп, Бірқұлақтікіне қарай жөнелді.»* [3: 64]. Осы үзінділердегі «апыраңдап, тайраңдай» экспрессоидтары Бозінгеннің бар болмысын ашып, оның өсекті жаюға асыққанын танытады. Мұнда автор Бозінгеннің бейнесін ашуға экспрессоидтарды ұтымды қолданады. Шығармадағы тағы бір жағымсыз кейіпкер Өрікті бейнелеуде автор: *«Ертеңінде түндегі бөтне қатын әлдеқашанғы осы үйдің байырғы қатынынан жаман ерте тұрып, төсек жиып,байға дәрет алғызып, орамал әперіп, шылапшынды шығартып, сымпыңдап, қужаңдап, ажарланып, құлпырып түрегелді.»* деген үзіндідегі «сымпыңдап, қужаңдап» экспрессоидтары арқылы автор өзінің Өрікке деген қатынасын көрсетеді.*«Қазы тілгенде, шұжық, бүйін қарта қылғанда, мүше бұзғанда Өрік өзі қақайып қарап отыратын болды»* [3: 66] дегендегі «қақайып» сөзінің мағынасын кеңейтіп, оған лексикалық мағынадан тыс эмоцияналды-экспрессивті бояу беретін сөзді қолданады. *«Бауырың екен, көрдік»- деп шаптығып, жерден алып, жерден салды»* деген үзіндідегі «шаптығып» сөзі де Өріктің үрысқақтығын, аузына ақ ит кіріп, қара ит шығатын, өткір тілді адам екенін танытатын экспрессоид болса, жоғарыда аталған эскпрессоидтардың барлығы дерлік Өріктің я Бозінгеннің бейнесін ашуға қызмет етеді.  Үркияның тоқалды ұнатпауын көрсету үшін: «Өрік тым қымсынбастан, тізесін шошайтып, жұртқа қарсы, шалқиып отырып

шай ішті» деген үзіндідегі «шошайтып,шалқиып» экспрессоидтарын қолданады. Бұл экспрессоидтардың артында Өріктің келе сала өзін осы үйдің қожайыны санауы, ешкімнен қымсынбауы жатыр.*«Жылтыр» дегенде езуін қисайтып, басын бір шұлғып тастады, өз атын мардымсып атағаны көрініп тұрды. Жылтыр жұлып алғандай тікірейе қарап:*

*– Мені кім деп естідіңіз?– деп сұрады»* [3: 35]. Бұл үзіндіде Жылтырдың қимылдарын суреттеуде автор экспрессоидтарды қолданады. Әрі соның арқасында Жылтырдың өзімшіл, өркөкірек бейнесі толық ашылады.

*– Жоқ, ерте емес. Алдымен келгендеріңізге қуанып айтам,-деп Төлеген жылмаңдап:-мінеки, тартыңыздар!-депманағы күміс сауытын ашып, алдарына қойды* [3:35]. Мұндағы «жылмаңдап» экспрессоидын Жүсіпбек Аймауытов Төлегеннің жағымпаздығын таныту үшін сәтті қолданады.

«*Ащы темекісін бипаздап тартпағанда, Ықаң енді не бітіреді? Тыпаң, міне,жаңа ботинкасын көлденеңдетіп, екі аяғын айқастырып отыр ғой. Оған бұлар «бізде жан екеміз» дегендей әлдеқандай боп, дардиып келіп отыр еді»* [3: 36]. Бұл үзіндіде автор Ықаң мен Тыпаңның дала қазағының не күйде екенін сұрап білгісі келмейтін, қазаққа қабырғасы қайыспайтын,болдым-толдым деген, өздерін беделді адамдар қатарына қосып, мардымсып, марқаюынтаныту үшін «бипаздап, дардиып» экспрессоидтары орынды қолданылған.

*«– Ә,.– деп Тыпаң да қутыңдап түрегелді. Ақбалаға қарап Ықаң басын қылқың еткізді»* [3: 36]. Мұндағы «қутыңдап, қылқың» экспрессоидтарын ел алдында салмағы бар деген Ықаң мен Тыпаңның жас комиссардың алдында құрдай жорғалайтынын таныту үшін Жүсіпбек Аймауытов әдейі пайдаланған. Жазушы экспрессоидтарды ұнамды я ұнамсыз кейіпкерлердің бейнесін ашуға қолданған. Ж.Аймауытовтың шеберлігі оның кейіпкерін суреттеуде көп сөзге ұрынбай, бір ұтымды жұмсалған экспрессоидпен бар болмыс, бітімін, бейнесін аша білуінде.

**Әдебиет**

1. Байтұрсынов А. Шығармалары. – Алматы: Санат, 1989. – 302 б.
2. Сыздықова Р. Сөз құдіреті. – Алматы: Санат, 2005. – 271 б.
3 .Аймауытов Ж. Шығармалары. Алматы: Мектеп, 1989. – 559 б.

## БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАКАЛЫ РАЙОНЫ ЯҢА МАТЫ АВЫЛЫНДА ЯШӘҮЧЕ КЕРӘШЕННӘРНЕҢ ЙОЛА ЛЕКСИКАСЫ

*Тимашева А., М. Акмулла ис. БДПУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. И.С. Насипов*

Яңа Маты авылы Башкортстан Республикасының Бакалы районында, район үзәгеннән 18 чакрымда көнбатыш ягында урнашкан. Аның тарихы XVIII гасыр азагыннан башлана. Авыл халыкның төп

өлешен керәшеннәр тәшкил итә. Алар мәдәнияте һәм сөйләше буенча татар халкының бер этник төркеме. Керәшен татарларының үзләренә генә хас тел үзенчәлекләре, тарихы, гореф-гадәтләре, йола-бәйрәмнәре, киемсалымы, бизәнү әйберләре, ашамлык-ризык төрләре һ.б. бар. Боларны В. Витебский, С. Матвеев, А. Можаровский, Н. Фирсов, Н. Катанов, Ф. Баязитова һ.б. галимнәр өйрәнгән.

Бу кечкенә хәбәрдә без Яңа Маты авылында яшәүче керәшен татарларының йола фольклорын һәм аңа бәйле лексиканы тикшерүне максат итеп куйдык. Яңа Маты авылында яшәүче керәшеннәрнең йола лексикасын өйрәнү барышында кыр, анкета һәм тасвирлау, чагыштырма-тархи методлар, күзәтү, эзмә эзлекле сайлап алу һ.б. алымнар кулланылды.

Яңа Маты авылында үткәрелгән һәм әби-бабалардан күчеп килгән бәйрәмнәрнең берсе – ул һәр елның 7 нче гыйнварендә үткәрелә торган Раштуа бәйрәме. Русча *Рождество – туым, туу* сүзеннән барлыкка килә. Ул Аллаһы Тәгаләнең кешеләрне хак юлга күндерү өчен, Җиргә җибәрелгән пәйгамбәре Иисус Христос туган көн дип билгеләнә. Бу көн табигатьнең кояш торгынлыгыннан чыгып, елның җәйгә таба авышуына туры килә.

Икенче зур бәйрәмнәрнең берсе 19 нчы гыйнвар көнне билгеләнә. Бу көнне суга көмеш кач төшерәләр, ягъни суны изгеләндерәләр, шул исәптән бәйрәмне *Кач ману көн* дип йөртәләр. Районның берничә авылында бәке казып су коеналар. Изгеләндерелгән су барлык булган чирләрдән арындыра, сафландыра дигән фикерләр һәм ышанулар бар. Менә шуңа күрә дә кач манылган су *Тереклек суы* дип йөртелә.

Елның яз фасылы *Май чабу – кыш озату* бәйрәме белән башлана. Ягъни игенченең язгы эшкә күчә башлау чорын билгеләп үтүгә бәйле. Бәйрәмнең атамасы бу көнне әзерләнә торган майлы тәбикмәк белән бәйле. *Май чабу* ел саен *Олы көнгә* бәйле рәвештә төрлечә килә. Пасха алдыннан була торган 7 атналык олы уразага бер атна калгач башлана. *Май чабу* бәйрәме – халыкның күңел ачуына, уен-көлкегә корылган бәйрәм.

7 нче апрель көнне билгеләнә торган *Кош ияр типмәс көнгә* зур урын бирелә. Һәм 7 нинди атна көненә туры килә, шул көн ел буена *Кош ияр типмәс көн* дип санала. Бу көндә эш башларга, яңа әйбергә тотыну тыела.

Бәйрәмнәр чылбырын дәвам итеп *Бәрмәнчек бәйрәме* килә. Ул *Олы көнгә* бер атна калган якшәмбедә үткәрелә. Бу вакытта инде су буйларында үсә торган талларның бөреләре кабарып шыта, чәчәк аталар, шул чәчәк ата торган тал ботакларын *бәрмәнчек* дип атыйлар. Иртән кояш чыкканчы, авыл халкы *Әрнәш* елгасына төшеп, нәзек тал ботакларын сындырып алып кайтып, изгеләр сурәте каршына, мал-туар йортына куялар.

Керәшен халкының иң зур бәйрәме булып саналучы бәйрәм – ул *Олы көн*. Һәр елны төрлечә – 4 нче апрельдән 8 нче май араларындагы атна көнгә туры килә. *Олы көнгә* каршы төндә хуҗабикәләр тәм-томнар өлгертә.

Бу бәйрәмдә иң изге йолаларның берсе – *Олы көн йомыркасы* пешерү. Иртән торып балалар өйдән-өйгә кереп бәйрәм йомыркасы җыя башлыйлар. Ишектән керү белән: “Христос яңадан туган!” диләр. Хуҗалар “Чыннан да яңадан туган!”– дип җавап кайтаралар һәм бүләккә йомырка, төрле тәм-томнар яки акча тапшыралар. Бу бәйрәм бер атна буена дәвам итә, урамнар уен-көлке белән тулы була, кунакка йөрү, йомырка отышлы уйнау бу бәйрәмдә бик тә урынлы. Иң мөһиме, *Олы көн* атнасында яңа эш башларга, җир эше белән булышырга яки су пычрату катгый тыела. Халык бу эшләргә бик кискен караштa, алар фикеренчә, бу эшләрне башлаучы кешеләрне кайгы көтә.

*Олы көннән* бер атна үтеп икенче атнаның сишәмбе көнен үлеләрнең *Олы көне – Үле чыгу көне* билгеләнә. Бу көнгә алдан ук әзерләнәләр. Һәр кеше үзенең гүр иясе булган якыннарының, танышларының каберләрен тазартып, буяп, төзәтеп куялар. Авыл халкы барысы да бер уңайлы көн сайлап, зыярат эчен чистарту көне дип билгеләп, зур эш башкаралар. Бәйрәм көнне барысы да үз вакытлары белән кояш батканга кадәр зыяратка искә алырга киләләр, чәчкәләр, төрле ризыкларны кабер өстенә салалар.

Ямьле җәй көннәрен *Питрау* бәйрәме башлап җибәрә. Рус теленнән *Петров день – Петр көне* сүзтезмәсеннән. Ул һәр елның 12 нче июлендә билгеләп үтелә. Бу көнне ике атналык *Питрау уразасы* тәмамлана. Тереклек һәм үсемлекләр дөньясында да үзгәреш чоры башлана: нәкъ төш вакытында кошлар сайраудан туктый. Хәтта бу көннән башлап су буйларында су коенырга ярамый дип әйтәләр. Бәйрәм көннең иртәнге ягында җыеп киптерелгән кыр чәчәкләрен кайнатып эчсәң, барлык авырулардан дәва була диләр. Бәйрәмнең иң мөһим ризыгы – ул җир җиләгеннән пешерелгән пирүк (пирог).

Инде җиләк-җимешләрне җыйганнан соң, бакчадагы яшелчәләр дә җитешә башлый. Беренче бәрәңгене тәмләп карау – *Энҗел бәйрәме* 2 нче августка туры килә. Ул табигать көчләренә табынуга кайтып кала. *Энҗел* җиттеме, авыл халкы күк йөзен курку баса. Чөнки бу вакытта игеннәр өлгергән була. Аны көчле яңгырлар юк итәргә мөмкин, дигән юраулар яши халыкта.

Инде август аеннан соң көзгә керү башлана. 14 нче октябрь көнне *Покрау* бәйрәме билгеләнә. Русча *Покров – покровительствовать*, ягъни *яклау* сүзеннән, татар телендәге “каплам”, “япма” мәгънәләренә туры килә. Ул үзенә күрә көзне озату, кышны каршылау булып тора. Бу чорда көзге эшләр тәмамланган, ә язгы әзерләккә баш салынмаган. Шунлыктан халык бераз бушанып, ял итеп ала. Өйдән-өйгә яки туганнан-туганга йөрү башлана. Табынның иң татлы ризыгы – Покрау пирүге, дөге ярмасыннан һәм кишердән әзерләнә.

Санап үтелгән барлык бәйрәмнәр дә Яңа Маты авылында бик зурлап үткәрелә. Бәйрәмнәрнең күбесе христиан динендәге башка халыклардагыча булса да, керәшен халкында, яки безнең авылда, ул бөтенләй башкача уздырыла. Хәтта бер үк бәйрәмнәр күрше авылларда да бөтенләй икенче төрле башкарыла, үзенчәлекле эчтәлеккә ия. Аларда мәҗүси традицияләрнең хрситиан дине тәртипләре белән үрелеп китүе – синкретизм күзәтелә.

Көннән-көн тормыш үзгәрә, һәм аның белән бергә халкыбызның гореф-гадәтләре, традицияләре дә үзгәрешләргә дучар була. Ата-бабаларыбыздан күчеп килгән йолалар да заманча эчтәлек ала бара. Моңа христиан дине тәртипләренең ныгый баруы да йогынты ясамый калмыйдыр. Бу, бер яктан караганда, тормышка яңа сулыш керткәндәй күренә, ләкин икенче яктан, без элек булган бәйрәмнәрнең төс-ямен җуябыз. Шулай да, шатлыкка күрә, туган авылыбыз халкы һаман борынгы рухи тормыш чолганышында яшәргә, рухи мирасны күз карасыдай сакларга омтыла.

**Әдәбият**


1. Антонова З.П. Керәшен җыру әйтә. – Яр Чаллы: “Хәерле иртә” нәшр., 1999. – 242 б.
2. Максимова Н.В. Без бер тамырдан: Керәшен татарларының этногенезын һәм этнографиясен өйрәнү буенча урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен уку ярдәмлеге. – Казан: Мәгариф, 2002. – 223 б.
3. Тимашева А., Тимашев С. Башкортостан Республикасы Бакалы районы Яңа Маты авылы милли бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләре // Сб. материалов Фестиваля-конкурса “Буыннар сабагы”. – Уфа: Изд-во БГПУ, 2017. – С. 104–108.
4. Филиппов А.С. Карендәшләр. Керәшен бәйрәмнәре, йолалары йәм гореф-гадәтләре. – Казан: “Идел-Пресс”, 2001. – 79 б.


## КЕРӘШЕН ХАЛЫК УЕН-БИЮ ҖЫРЛАРЫНЫҢ ҺӘМ ТАКМАКЛАРЫНЫҢ ПОЭТИК ЭШЛӘНЕШЕ

(Кукмара районы Югары Чура авылы мисалында)


*Тимофеева Т., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Ф.И. Габидуллина*


Җыр – халык лирикасының һәм язма поэзиянең киң таралган төре, сүз-текст белән көй-музыканың үзара үрелүенә нигезләнгән, җырлап башкаруга исәп ителгән жанр [2: 3]. Чыннан да, җыр – һәр милләтнең үзенә генә хас булган рухи байлыгы, ата-бабаларыбыздан калган иң кадерле мирасларыбызның берсе. Аларда халыкның көнкүреше, йолалары, гореф-гадәтләре чагылыш тапкан. Халыкның һәм аерым бер шәхеснең рухи дөньясын, фикер һәм кичерешләрен чагылдыру вазифасыннан чыгып, бөек шагыйребез Габдулла Тукай җырларны “халык күңеленең көзгесе” дип атаган [1: 238].

Җыр бәйрәмгә ямь өстәү, күңелләрне күтәрү, халыкны берләштерү чарасы булып тора. Кукмара районы Югары Чура авылында элек-электән

бер бәйрәм дә җыр-бию, уен-көлкесез үтмәгән. Табигать кочагында уза торган кичке уеннарда, Симет, Питрау, Майлы ботка кебек бәйрәмнәрдә егетләр һәм кызлар бергәләп күңел ачкан, танышкан, уеннар уйнаган. Һәм, әлбәттә, уеннар җыр-бию белән бергә үрелеп барган.

Әйлән-бәйлән җырлары керәшен халкы иҗатында төп урынны алып торалар. Алар структур яктан ике өлештән – күмәк башкарыла торган җырдан һәм бию такмагыннан (кушымтадан) гыйбарәт.

Такмак – "бәйрәмнәр, туйлар, уеннар дәвамында халыкның күңелен күтәрү, биетеп алу функциясенә хезмәт итүче мөстәкыйль жанр" [3: 26]. Кайчандыр такмаклар үзләренә күрә уен коралы, гармун вазифасын үтәгән. Бию такмаклары белән уен җырларының уртак яклары икесенең дә биетүгә хезмәт итүләреннән, тиз һәм еш кабатланучы хәрәкәт ритмына корылуларыннан гыйбарәт. Аерым бию такмакларның күпчелеге иркен рәвештә кызу темп белән җиңел көйгә башкарыла. "Түгәрәк уен" барышында башкарыла торган уен-бию такмагын мисалга китерик:

*Чия агачы чемнәре,*
*Чия агачы чемнәре күк*
*Аларның нәселләре.*
*Дулкынланып сулар кerә*
*Пароход иднәнә.*
*Ышанмагыз егетләрнең*
*Яратам дигәненә.*
*Шулмы синең яратуың?*
*Шулмы синең сөюең?*
*Шулмы синең, гомерлеккә*
*Ярың булам, диюең? (Егорова Зоя Александр кызыннан язып алынды, 78 яшь)*

Югарыда мисалга китерелгән такмак күмәк башкарыла торган өлешенең өч юлдан гына торуы, ике юлның да бертөрле башланып китүе белән бераз аерылып тора. Чыннан да, такмакларның поэтик эшләнешенә килгәндә, аларның бер ише бер үк сүзләрне кат-кат кабатлаудан башланып китә, һәм әлеге сүзләрдән төзелгән тезмәләр башкаларыннан берме яки ике-өчме иҗеккә кыскарак була. Нәкъ менә шул рәвешле көйләү исәбенә алар үзенчәлекле музыкаль-ритмик башлам барлыкка китерәләр.

Әйлән-бәйлән уены вакытында башкарыла торган такмакларның тагын бер үзенчәлеге аның юморга, көйгә бай булуыннан гыйбарәт. Юморга корылу биюгә дәрт-илһам өстәү һәм шаян, күңелле атмосфера тудыру өчен хезмәт итә. Аларда кулланылган көлке тудыру алымы бик тә кызыклы: башта ниндидер бер фикер әйтелә дә шуның артыннан ук әлеге фикернең киресе раслана. Димәк, үзара ярашмаучы ике күренешнең бергә килүе һәм беренчесенең юкка чыгарылуы нәтиҗәсендә көлкеле хәл

барлыкка килә. “Өчле бию” такмаклары югарыда әйтелгән сүзләргә ачык мисал булып тора:

*Тартма, егет, тәмәкеңне,*
*Мыегыңны көйдерер.*
*Бу Чураның егетләре*
*Сөймәсәң дә сөйдерер.*
*Кушымта:*
*Ай-һилләү-һилләү-һилләү,*
*Утыз кызга бер кияү,*
*Анысы да аяксыз,*
*Йөри алмый таяксыз. (Ефремова Зоя Александр кызыннан язып алынды, 55 яшь)*

Уен такмаклары да, бию такмаклары да – кабатлауларга, рифмаларга бай булулары һәм текстларының мөмкин кадәр ваграк кисәкләргә бүлгәләнүе белән характерлана торган поэтик-музыкаль берәмлекләр. Күпчелек җырлар дулкын кебек бер-бер артлы тезелеп, бер-берсен куәтләп килүче аһәңдәш һәм кайсыдыр яклары белән тиңдәш тезмәләрдән торалар. Иң мөһиме, алар, ритмик яктан бию көенә яраклашып, сүз белән көйнең гармоник берлегенә ирешергә мөмкинлек бирәләр.

Димәк, уен-бию җырлары үзләренең поэтик үзенчәлекләре, эмоциональ-драматик рухлары, шигъри-музыкаль ритмнары белән аерылып торалар һәм уеннарны, биюләрне оештыруда мөһим роль уйныйлар. Рифмалары һәм ритмнарының бик тә төгәл булуы хисабына алар хәтта музыка коралын да алыштырга да сәләтле.

**Әдәбият**

1. Әхмәдуллин А. Әдәбият белеме сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 238 б.
2. Миңнуллин К. Җырларның шигъри табигате. – Казан: Мастер Лайн, 1999. – 107 б.
3. Татар халык иҗаты / Төз. И.Н. Надиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 320 б.

## ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНДӘ ИСЕМ СҮЗ ТӨРКЕМЕ

*Узум С., Бөгелмә р-ны М. Өнҗәл ис. лицей-интернат, VIII сыйныф*
*Җит. – С.Г. Юнусова*

Татарстан – күп милләтле республика, анда төрле милләт вәкилләре, Тукайча әйткәндә, "тел, лөгать һәм әхлак алмашып" яши. Мин Бөгелмә районы Мостафа Өнҗәл исемендәге лицей-интернатның 8 нче сыйныф укучысы. Лицейда рус, татар, инглиз телләре белән бергә, төрек телен дә өйрәнәбез. Бүгенге эшемнең темасы итеп мин: «Татар һәм төрек телендә исем сүз төркеме» темасын сайладым.

Татар һәм төрек телләре – иң киң таралган төрки телләр. Бу телләр икесе дә, башка барлык төрки телләр кебек, агглютинатив (тагылмалы) телләргә керә. Сүзнең тамырына аффикслар (кушымчалар) билгеле бер тәртиптә ялгана (мәсәлән: өстәл-ләр-ем-дә, araba-lar-ımız-da). Татар теленә

иң якын торган телләр – башкорт, нугай, казах, каракалпак, карачай, болкар, комык телләре. Шулай ук төрек, гагауз, азәрбайҗан, үзбәк, төрекмән, кыргыз телләре дә татар теленә бик якын торалар.

Әгәр исем сүз төркемен карасак, татар һәм төрек телләрендә охшашлык шунда: аларда **род** категориясе юк. Татар телендә кем? соравы кешеләргә генә куела.Төрек телендә дә, нәкъ татар телендәге кебек, kim? (кем?) кешеләргә карата гына кулланыла. Хайваннар, бөҗәкләр, балык, кошларга барысына да ике телдә дә нәрсә? (ne?) соравы куела.

Татар һәм төрек телләрендә охшашлык шунда: аларда **род** категориясе юк. Татар телендә кем? соравы кешеләргә генә куела.Төрек телендә дә, нәкъ татар телендәге кебек, kim (кем?) кешеләргә карата гына кулланыла. Хайваннар, бөҗәкләр, балык, кошларга барысына да ике телдә дә нәрсә? (ne?) соравы куела.

Исемнәрнең күплек сан формасын карасак, татар телендә күплек сан кушымчалары *-лар//-ләр, -нар//-нәр* белән ясала. Татар телендә *-м,-н,-ң* хәрефләреннән соң, *-нар//-нәр* аффикслары ялган. Мәсәлән, урындыклар, кешеләр, урманнар, идәннәр. Ә төрек телендә исемнәрнең күплек сан формасы *-lar//-ler,* аффиксы ярдәмендә ясала. Мәсәлән: masalar, kişiler, orma**n**lar, anneler,babalar. Төрек телендә -н хәрефеннән соң, *-lar* кушымчасы ялгануы аермалы як, чөнки төрек телендә *-нар* кушымчасы юк [2: 91].

Татар һәм төрек телләрендә тартым аффикслары күплек сан кушымчасыннан сон килә. Мәсәлән: *дәфтәр, дәфтәрләр, дәфтәрләрем; ev (өй), evler (өйләр), evlerim (минем өйләрем), sųz (сүз) sųzler (сүзләр) sųzleriniz (сезнең сүзләрегез)* [2: 96].

Һәр ике телдә дә 6 килеш бар. Баш килешнең генә кушымчасы юк, кыек килешләрнең аффикслары бар.

| № | Килешләр | Кушымчалар | Сораулары |
|---|---|---|---|
| 1 | Баш килеш (именительный падеж) | - | Кем? Нәрсә? |
| 2 | Иялек килеше (притяжательный падеж) | -ның//-нең | Кемнең? Нәрсәнең? |
| 3 | Юнәлеш килеше (направительный падеж) | -га//-гә, -ка//-кә, | Кемгә? Нәрсәгә? Кая? |
| 4 | Төшем килеше (винительный падеж) | -ны//-не | Кемне? Нәрсәне? |
| 5 | чыгыш килеше (исходный падеж) | -дан//-дән, -тан//-тән, -нан//-нән | Кемнән? Нәрсәдән? Кайдан? |
| 6 | Урын-вакыт килеше (местно-временной падеж) | -да//-дә, -та//-тә | Кемдә? Нәрсәдә? Кайда? Кайчан? |

Ә төрек телендә түбәндәгечә:

| № | Килешләр | Кушымчалар | Сораулары |
|---|---|---|---|
| 1 | Yalın durum, yalın hal (основной падеж) | - | Bu ne?Bu kim? |
| 2 | Tamlayan durumu, ilgi hali (родительный падеж) | -in/ -ın/ -un/ -ün или -nin/ -nın/ -nun/ -nün | Kimin?Neyin? |
| 3 | Belirtme durumu,belirtme hali (винительный падеж) | -yi/ -yı/ -yu/ -yü ı/ -i/ -u/ -ü | Kimi?Neyi? |
| 4 | Yönelme durumu, yönelme hali (дательный) | -a/ -e -ya/ -ye | Kime?Neye? Nereye? |
| 5 | Kalma durumu,bulunma hali (местный) | -da/ -de,-ta/te | Nerede? Kimde? |
| 6 | Çıkma durumu, ayrılma halı (исходный) | -dan//-den, -tan//-ten. | Nereden? Kimden? Neden? |

Тартым категориясенең татар һәм төрек телләрендә кушымча белән ясалуында уртаклык бар.

| ат | Төрекчә | | Татарча | |
|---|---|---|---|---|
| | Берлек сан | Күплек сан | Берлек сан | Күплек сан |
| I | Benım-kitabım | Bizim-kitabımız | Минем китабым | Безнең китабыбыз |
| II | Senin-kitabın | Sizin-kitabınız | Синең китабың | Сезнең китабыгыз |
| III | Onun-kitabı | Onların-kitapları | Аның китабы | Аларның китаплары |

Татар телендә сорау җөмләләр сорау сүзләре яки сорау кисәкчәләре ярдәмендә ясала. Татар телендә сорау кисәкчәләре *мы//ме* җөмлә ахырындагы сүзгә кушылып язылa. Мәсәлән, Син укучы кызмы? Бүген дүшәмбеме? Төрек телендә дә сорау җөмләдә сорау сүзләре яки сорау кисәкчәләре булырга мөмкин. Сорау кисәкчәләре *mı//mi, mu//mь*, гадәттә, хәбәрдән соң килә. Алар аерым язылалар. Мәсәлән: Bugün çarşamba mı?; bugün Cumartesi mi?; Pazara gidecek misin?; Bana elbise alacak mısın?

Йомгак ясап шуны әйтәсе килә, без татар теленең «Исем» һәм төрек теленең «İsim» сүз төркеменең тикшердек. Тугандаш халык теле булган татар һәм төрек телендәге исем сүз төркеме арасында уртак яклар бик күп дигән нәтиҗәгә килдек.

**Әдәбият**

1. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен д-лек. – 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 335 б.

2. Щека Ю.В. Практическая грамматика турецкого языка. – АСТ: Восток-Запад, 2007. – 666 с.

НОМИНАЦИЯ ЛИЦ В ДЕТСКОЙ РЕЧИ
(на материале произведений М. Карима)

*Уметбаева Н., БГПУ им. М. Акмуллы, студент V курса*
*Науч. рук. – докт. филол. наук, доц. Г.Н. Ягафарова*

Мустай Карим – известный башкирский писатель и поэт. Он автор более ста поэтических и прозаических сборников, свыше десяти драм. Его произведения были переведены на разные языки мира, они представляют башкирскую литературу на мировом уровне. Творчество Мустая Карима является национальным достоянием народа и страны.

Целый ряд рассказов, повестей автора посвящен теме детства и детей, теме восприятия окружающего мира ребенком. Самыми популярными и читаемыми произведениями о детях являются повести «Радость нашего дома», «Таганок», а также автобиографическое произведение «Долгое-долгое детство».

В данных повестях для характеристики детских персонажей часто используются элементы детской речи – вида речевой деятельности, характеризующего те или иные этапы развития детей определенного возраста. Детская речь отличается от взрослой речи отступлениями от норм на многих уровнях – фонетическом, словообразовательном и синтаксическом. Ее особенности определяются свойствами мышления детей: отмечается большое число звукоподражаний, образование нерегулярных форм по регулярным моделям, особый синтаксис.

Мустай Карим очень хорошо разбирался в психологии детей и их развитии. В своих работах он это знание умело применял, вводя в текст повествований характерные речевые обороты, лексемы. Среди них выделяются слова – номинации лиц. Данные наименования относятся к существительным, в тексте чаще используются в вокативной функции, примечательны своеобразным словообразованием. В этой статье мы хотим рассмотреть номинации лиц в детской речи персонажей повести Народного поэта Башкортостана Мустая Карима.

В современной лингвистике «номинация» понимается как сложный процесс «образования языковых единиц, характеризующихся номинативной функцией, т. е. служащих для называния и вычленения фрагментов действительности и формирования соответствующих понятий о них в форме слов, сочетаний слов, фразеологизмов и предложений» [1: 336]. В изучаемых произведениях дети в основном номинируют в своей речи близких родственников, с которыми живут вместе, друзей-сверстников, с которыми вместе играют, общаются вне дома, и других взрослых знакомых. Герой из повести «Радость нашего дома» Ямиль нежно называет свою маму *әсәйем, әсәкәйем* «мама, мамочка моя», бабушку – *өләсәкәйем* «бабуленька моя», сестренку Оксану – *һеңлем, туғаным* «сестренка, род-

ная моя», отца называет *атайым,* «папа, папочка». Эти люди – самые близкие родственники Ямиля. Чтобы показать это, автор использовал притяжательные аффиксы I лица *-ым, -ем*, которые призваны показать особо близкие отношения.

Как известно, дети пополняют свой словарный запас двумя путями: первый – через усвоение существующих в языке лексических единиц, второй – через создание, придумывание новых номинативных единиц в процессе индивидуального языкового творчества. Если первый путь сопровождает человека всю жизнь, то второй путь обычно длится до 8-9-и лет, когда происходит смена активного словотворчества ребенка усвоением большого количества готового лексического запаса. В процессе придумывания новых слов ребенок выступает как самостоятельный субъект номинативной деятельности. Так, в повестях М. Карима дети очень часто дают прозвища друг другу, которые, как известно, основываются на какой-либо определенной черте характера, внешности, роде занятий или по созвучию с подлинным именем и фамилией.

В повести «Долгое-долгое детство» прозвище главного героя – *Кендек* ‘Пупок’. «*Сначала эти злые ребята "повивального деда"* – «кендек бабайы» *превратили в "деда-повитка"* – «кендек-бабай». *Стерпел. Мало им – "деда-повитка" укоротили просто в "повитка"* – «кендек». *Тоже стерпел. Но в один прекрасный день превратился я... в Пупка*», – разъясняет автор [2: 124]. Его так начали называть из-за того, что он каждый раз ходил со своей Старшей матерью-повитухой на роды. Еще одним его прозвищем стало слово «Рукавказ»: оставшегося без звучного прозвища-топонима малыша ребята утешают, выбрав ему звучное вымышленное имя: «*Ужас какая грозная, в общем, страна. Это Рукавказ! Пупок! Ты – Рукавказ...*» [4: 446]. У других мальчиков из этой же повести так же есть прозвища: Хамитьяна называли *аркыры баш Хәмитйән* ‘поперечная голова Хамитьян’; Шайхаттара – *төлкө* ‘лиса’; Шагидулла – *башлыҡ* ‘глава’; Аскат – *һары серәкәй* ‘желтый комар’. Все эти прозвища мальчики придумали сами и используют их в обращении и общении друг с другом.

В повести «Долгое-долгое детство» представлены и прозвища взрослых, которые встречаются в детской речи как следствие подражания взрослым. Например, *Кара Йомағол* ‘Черный Юмагул’*, Буран Абдулла, Лекаревка урыы Тимофей* ‘Тимофей из деревни Лекаревка’*, Кара Якуп* ‘Черный Якуп’*, Микәй, Тиле Ғәббәс* ‘Глупый Габбас’*, Күркә Мәүлетбай* ‘Мавлетбай-индюк’ и т. д. Как видим, данные имена возникают на основе различных мотивов именования, но являются характеризующими, идентифицирующими именами.

Таким образом, наши наблюдения показывают, что в произведениях М. Карима активно используется детская речь, в составе которой

выделяется пласт номинаций лиц. В данной статье мы рассмотрели лишь малую часть проблемы, имеющей отношение к прозвищам. Тема требует дальнейшего развития и дополнения.

**Литература**

1. Номинация // Лингвистический энциклопедический словарь. – М.: Сов. энциклопедия, 1990. – 336 с.

2. Кәрим М. Озон–озак баласак. – Өфө: Китап, 2012. – 272 б.

3. Ваганова А.К. Номинация в детской речи: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. – Таганрог, 1997. – 29 с.

4. Ягафарова Г.Н. Окказионализмы в творчестве Мустая Карима // Вестник Башкирского университета. – 2016. – Т. 21. – №2. – С.442–447.

## РЕПРЕЗЕНТАЦИЯ МОТИВА СТРАННИЧЕСТВА В ТВОРЧЕСТВЕ М. ЮНЫСА

*Фаезова Л., КФУ, аспирант*

*Науч. рук. – канд. филол. наук., доц. Г.Р. Гайнуллина*

Национальная ментальность и национальный характер, как ее составляющая, в качестве предмета изучения литературоведения относится к числу приоритетных и актуальных проблем современной гуманитарной науки. По мнению многих исследователей (Г.Д. Гачев, М.Ю. Тимофеев, Е.В. Папилова, М.К. Попова), художественная литература наиболее целостно и в деталях воплощает национальную ментальность, что позволяет определить генезис, динамику и механизмы ее становления. Например, как утверждает специалист по имагологии Е.В. Папилова, «художественная имагология обладает достоверностью иного рода: литература при всей ее условности способна полнокровно, живо воссоздать атмосферу человеческих отношений, менталитет, характеры, речь, стереотипы обыденного сознания, сформированные в той или иной национальной или социальной среде» [6: 34].

Своеобразная репрезентация национального характера в прозе татарского писателя-мариниста М. Юныса позволяет рассмотреть его в двух аспектах. Во-первых, главный герой многих его произведений, единый сквозной образ Габдрахмана Рахманкулова, наиболее приближенный к личности автора и являющийся его альтер эго, транслирует страннический тип мироповедения человека, одновременно реализуя личные искания самого автора. Во-вторых, этот же образ в процессе рецепции не только раскрывает образ «дургого», но и характеризует образ «своего». В данной статье мы преимущественно рассматриваем первый из них, поскольку странническое мироповедение самого автора, выраженное мотивомстранничества позволяет проникнуть нам в глубинные структуры самого текста, расширяя границы итепретации и анализа на предмет национального характера.

Мотив странничества, широко распространившийся в русской литературе дореволюционного периода, изучен достаточно глубоко, и доказано, что феномен странничества в культурологическом плане является традицией русской культуры [8: 132].

В татарской литературе мотив странничества как феномен недостаточно изучен, и в данной работе мы попытаемся описать репрезентативный характер странничества и определить его специфику на примере творчества М. Юныса.

Актуализация страннического мотива в творчестве М. Юныса во многом связана с эпохой оттепели, которая подготовила благоприятную почву для обновления национального дискурса в национальных литературах Советского периода. Странничество М. Юныса в отличие от вышеперечисленных его источников, в том числе выражает самостоятельную оригинальную форму идентичности личности. Выбирая странничество как коммуникативную стратегию, и реализуя его, М. Юныс в своей прозе последовательно реабилитирует традицию национальной идентичности, возвращает в литературу тему миграции родного народа.

Еще в первом рассказе «Безнең өй өянкеләр астында иде» («Наш дом был под ивами»), написанном в 1964 году М. Юныс предвосхищает страннический мотив своего творчества, беря за основу хронотоп встречи на кладбище – на месте, где «встречаются» живые и мертвые. Содержательная сторона странничества означает «уход» из одного мира в другой. Автор намекает на то, что живой человек всегда находится в движении и в поиске своей идентичности. Таков единый герой всех романов и повестей М. Юныса Габдрахман Рахманкулов. Трилогия «Наука странствий», роман «Кипчакская дочь», повесть «Найти и потерять», рассказы «Наш дом был под ивами», «Праздник» начинаются хронотопом пути и сюжетом становится странствие героя. (Примечательно, что фамилия Рахманкулов дублирует смысл имени Габдрахман, что в переводе с арабского означает «раб Аллаха» (слово «рахман» является одним из имен Аллаха), и это с одной стороны характеризует героя, в то же время отсылает читателя к суфийским традициям.)

В трилогии «Дөнья гизү» (по авторскому переводу название книги – «Наука странствий», 1977–1984), в романе «Кыпчак кызы» (Кипчакская дочь», 2004–2014) герой М. Юныса Габдрахман Рахманкулов рефлексирует и анализирует свое страническое мироповедение.

Для названия частей трилогии автор обращается к таким мощным символам, как «ветер» и «буря». Первая часть называется – «Соленый ветер», вторая – «Долгожданная буря». Автор, несомненно, эксплуатирует потенциал литературных универсалий ветра и бури. Например, символ «ветра», означающий свободу, волю, время, движение, в ХХ столетии

представляется как «мощный символ изменений, непостоянства, пустого бахвальства и эфемерности». В контексте со словом «соленый» символ означает перемены, связанные с морем. «Буря» в мировой литературе часто символизирует одновременно разрушительную и созидательную силу и как метафора здесь указывает на духовные искания героя, чаще всего он оказывается борцом. В трилогии эти символы указывают на альтернативную традицию протеста или борьбы культурного героя в условиях идеологического дискурса. Поэтому если духовная сторона странничества подразумевает уход из мира, то в светском понимании оно отождествляется с уходом из империи. В отличие от русского скитальчества, у которого наблюдается корреляция с аспектом страдания и смещение в сторону романтических традиций (например, в творчестве Н. Некрасова, М. Горького), мотив странничества М. Юныса выражает путь поиска авторской идентификации. Эта мысль подтверждается также в тертьей части трилогии, которая называется «Таңда Босфор аша».

В «Науке странствий» Габдрахман Рахманкулов будучи отличником-студентом филологического факультета Московского государственного университета неожиданно для всех принимает решение уйти в мореходство.

В эпизоде прощания с однокурсниками, узбек Уметгали в размышлениях указывает Рахманкулову на один из источников его страннического мироповедения.

«*Исеңдәме, Габдрахман, мине Шәрекъ йолаларын саклаучы суфи дип үртәвең? Син үзең бабаларыңның күчмәлек гадәтеннән арынып җитмәгәнсең әле, – диде Өметгали.*

*– Минем бабаларым атларына тапталмаган яшел болыннар эзләп күчеп йөргәннәр. Мин саф һава, иркен сулыш эзлим. Иркен сулыш һәм ирек*».

*(«Помнишь, Габдрахман, ты меня поддразнивал, что я – хранитель-суфий Восточных традиций? Ты сам еще не преодолел кочевнические привычки своих прадедов, – сказал Уметгали.*

*– Мои прадеды кочевали в поиске свежих зеленых лугов для своих табунов. Я же ищу свежий воздух, чтобы дышать в полную грудь. И свободу»* (перевод наш) [9: 64].

Или же Рахманкулов сравнивает себя с одним из односельчан, который тоже любил путешествовать. В отличие от других односельчан, которые вынуждены были уходить на подработки на Урал, Сибирь и Донбасс, и, заработав достаточно денег, чтобы отремонтировать и обновить хозяйство, возвращались на родину, сосед Рахманкулова Закиулла абый мечтал увидеть край света.

«Бәлки, мин дә, Зәкиулла абый шикелле, төпләнеп яшәү авырлыгыннан куркып, “пүчтәк эш” артыннан гына йөри торганмындыр?»

*(Возможно, я тоже как Закиулла абый, избегаю трудностей оседлого образа жизни и гоняюсь за «пустяковой работой»? (перевод наш)* [9: 78].

Төрле тарихи хәл-вакыйгаларга бәйле җир-су атамалары да бар: *Баяр урманы, Сугыш чокыры* һ.б. *Сугыш чокыры* дип аталган урынның тарихы турында шундый истәлек сакланган: Ул урын Йонны һәм Рсай авыллары арасында була. Җир бүлгән вакытта, җир үлчәүчеләр Бөре өязеннән киләләр. Чокырлы һәм урманлы 13-14 га җир кайсы авылга булырга тиеш? Халык аптырауга кала. Ике авыл арасында тавыш куба. Җир үлчәүчеләрне ике як та төрлечә сыйларга тотыналар; ит, бал, май, йомырка, акча бирәләр. Кайсы авыл күбрәк ришвәт биргән, шул авылга бу җирне биреп киткәннәр. Бер караганда – җир Рсайлыларга, икенче караганда – Йонны авылына күчкән. Халык моның белән килешә алмыйча, көче кулланып көрәшергә була. Билгеле бер көн билгеләнә. Ике якның да ирләре таяклар белән коралланып, бу урынга җыелганнар. Йонны авылыннан атаман Зәйнетдинов Мөхәммәтдин исемле кеше, ә Рсай авылыннан Әхмәтдин исемле кеше бермә-бер көрәшкә чыгалар. Җиңүче ягына җир калдырылырга тиеш була. Йонны атаманы Әхмәтдинне ерткычларча тукмап үтерә, һәм моны карап торган халык бөтенесе бер юлы бер-берсенә ташлана. Йонны халкы Рсайларны авылларына хәтле куып алып бара. Имеш, шул көннән башлап бу кан коелган җир *Сугыш чокыры* атамасын йөртә.

Кеше киләчәккә карап яши, ләкин йортның стенасын нигезсез күтәреп булмаган кебек, кеше дә үзенең үткәнен онытса, аның бүгенгесе дә, киләчәге дә булмый. Ата-бабаларыбыз безгә телебезне, мәдәниятебезне калдырганнар, һәм без аларны сакларга тиешбез.

**Әдәбият**

1. Генеалогии и архивы. Илишевский район. д. Юнин. URL: http://www.ufagen.ru/places/ilishevskiy/yunino.html (дата обращения: 15.12.2019).

2. Башкортостан татарлар фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төз., кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М. Сөйләйманов. – Уфа: Китап, 2018. – 344 б.

# РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН ИҖАТЫНДА ӘХЛАК ТЕМАСЫ

*Шәйхетдинова З., КФУ, III курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Г.Ф. Каюмова*

Стиль сүзе телнең нинди максатларда һәм ничек кулланылышын белдерә. Язучы үз әсәренең үзенчәлекләреннән чыгып, төрле тел чараларын сайлый һәм аларны үзе теләгәнчә файдалана. Сүзләр мәгънәви яктан күп төрле. Үзләре үк образга әйләнгәннәре (символлар), күчерелмә мәгънәлеләре (метафора, метонимия, сынландыру, гипербола, юмор), предметлы сурәтләү чаралары (синонимнар, антонимнар, эпитет, чагыштыру), әдәби нормаларга туры килмәгән лексик чаралар (диалекталь, гади сөйләм, арго һәм жаргон сүзләр, варваризмнар) бар. Р. Миңнуллин – әнә шул тел-стиль чараларына җан кертеп, аларны иң оста кулланып язучыларның берсе.

Мәсәлән, “Трамвайда “куян” булып йөрергә яраткан малай турында” шигыренә игътибар итик. Әсәрнең исеме нәкъ эчтәлегенә тури килми, малай “куян” түгел:

*Әздер миннән*  
*Көлсәң дә –*  
*Билет булган*  
*Кесәмдә!* [3: 111].

Автор алдан малайны билетсыз итеп сурәтли, биредәге малай хисләрен бирүдә градация алымын куллана:

*Мин шундый каушаганмын,*  
*Мин шундый курыкканмын* [3: 111].

“Табын янында” шигырендә Нур белән Вилнең ярышуы сурәтләнә. Белгәнебезчә, табын алдында мондый ярышлар үткәрү урынлы түгел. Р. Миңнуллин ситуацияне кабатлаулар аша бирә:

*Виле: “**Бетә бит**!” – дип, Нурны*  
*Тора котыртып.*  
*Нуры тиз-тиз ашый ашын,*  
***Бетә дип** куркып* [4: 110].

“Нишләрбез инде?!” шигырендә тыңлаусыз Ләлә сурәтләнә:

*Инде берәр эш кушсалар,*  
*Әй Ләлә чәбәләнә,*  
*Киреләнә, үҗәтләнә,*  
*Кыскасы, кәҗәләнә!* [3: 116].

Әлеге күренешләрне төгәлрәк, бер-бер артлы килүче процессларны биръ автор синонмнарны куллана: *чәбәләнә, үҗәтләнә, киреләнә* һәм *кәҗәләнә* дип берләштереп куя.

“Томау, җиң һәм кулъяулык” шигырендә баланың борынны җиңенә сөртүе тасвирлана. Бала безне кисәтеп тә куя:

*Юпь-юеш шул, юпь-юеш,*
*Тагын сөртер идем дә.*
*Борчылмагыз!Минем әле*
*Бар икенче җиңем дә!* [4: 119].

Биредә автор юмор, йомшак көлү чарасы, җиңелчә елмаюга мөрәҗәгать итә, шаян мөнәсәбәтне белдерә.

“Таш, чыпчык һәм алма” шигырендәге фикер түбәндәге юлларда белдерелә:

*Әмәлен ләкин таптым –*
*Агачка мин таш аттым.*
*Юк ла, алмага аттым,*
*Чынлап та, аңа аттым.*
*Юк ла, чыпчыкка аттым!*
*Ахрысы, юкка аттым...* [4: 60].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: Р. Миңнуллин шигърияте төрле сурәтләү чараларга бик бай. Р. Миңнуллин сүзләрнең лексик чараларыннан да актив файдалана, аларны сурәтләү чарасына әвereлдерә.

Шулай итеп, Р. Миңнуллин иҗаты, шигърияте, аның иҗат теле – әле ачылып бетмәгән сер. Мавыктыргыч, үзенә тартып-чакырып тора торган сер. Аның теленең тылсымлы көчен ныграк өйрәнгән саен, бу серле шигъри дөньяның асылына якынаябыз. Шуңа күрә, шагыйрь иҗатының индивидуаль лексик үзенчәлекләрен, стилистик алымнарының бирелешен, андагы урынлы кулланылган бай, энҗе бөртекләредәй тел-бизәкләү чараларын өйрәнү мөһим.

**Әдәбият**

1. Миңнуллин Р.М. Әсәрләр. Җиде томда. Т.3: балалар өчен шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр, мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 543 б.

2. Миңнуллин Р.М. Әсәрләр. Җиде томда. Т.4: балалар өчен кечкенә әкиятләр, ирекле тәрҗемәләр, төрле язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 528 б.

3. Шәймәрданов М.Х. Татар милли педагогикасы: югары һәм урта педагогика уку йортлары өчен уку ярдәмлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 399 б.

## ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ ТАРТЫКЛАР ЧИРАТЛАШУЫ ОЧРАКЛАРЫ

*Шәнгәрәева А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. М.Р. Саттарова*

Җанлы сөйләм процессында авазларның еш кына үзгәрүе, бүтән авазлар белән алмашуына тап булабыз. Бер ук морфема төрле аваз

вариантларында йөрергә мөмкин. Авазлар үзгәрү хәзерге телне, яисә аның элекке кагыйдәләре нигезендә бара. Бер морфема составындагы төрле авазларның теге яки бу кагыйдә нигезендә тәңгәлләшүе ***чиратлашу*** дип атала[4: 234].

Тартык авазларның чиратлашуына карата тел белгече Л. Яфаров: “Татар телендә, шул ук вакытта башка төрки телләрдә дә, саңгырауларның яңгыраулаша баруы эпохалар буена килгән үсеш, үзгәреш һәм камилләшү процессы буларак, телдәге күп кенә тарихи фактлар белән исбатлана”, – дип язды [5: 55].

Башкорт һәм татар телләренең казах, себер татарлары, удмурт, марый телләре белән лингвоэтник бәйләнешләре бар. Башкорт теле грамматикасына зур өлеш керткән галим Н.К. Дмитриев “Грамматика башкирского языка” монографиясендә авазлар чиратлашуы мәсьәләсенә аерым бүлекчә багышлый [2: 28]. Әлеге хезмәтендә ул *п, т, к, къ* саңгырауларының *б, г, гъ* яңгыраулары белән чиратлашу мәсьәләсен карый, түбәндәге мисаллар китерә: сап-сабы, аяк-аягъы, һ.б. Шулай итеп, чиратлашу күренешен Дмитриев мәҗбүри характерга ия ди, әдәби норма буларак, орфографиядә чагылуын табигый күренеш, дип яза [2: 30-31]. Башкорт телендә аваз чиратлашуы авазларның сөйләмдә бер-берсенә тәэсир итешүе нәтиҗәсендә барлыкка килә: әгәр [к], [қ], [п] тартыкларына тәмамланган сүзләргә сузык авазга башланган кушымча ялганса, ике сузык арасында калган әлеге тартыклар, шул сузыклар тәэсирендә яңгыраулашалар, мәсәлән, ак-а > ага, түк-ә > түгә, төп-е > төбе һ.б. Акустик яктан бу беренче формантаның түбән төшүендә һәм спектрда борын тартыкларында була торган өстәмә форманта пәйда булу белән тәкъбир итеlә. Авазларның нигез ахыры һәм аффикслар башында яңгыраулыкта һәм саңгыраулыкта параллелизмга дучар булуы төрки телләрнең барлыкка килүеннән үк башланып, хәзерге көнгәчә дәвам итә, дип яза Дмитриев [2: 33-35].

Башкорт телендә аваз чиратлашу һәм татар телендә аваз чиратлашу арасында параллель үткәреп була. Башкорт телендә, татар телендәге кебек, сыйфат дәрәҗәләре, төгәлрәк әйткәндә, чагыштыру дәрәҗәсе *-раҡ, -рәк, -ыраҡ, -ерәк, -ораҡ, -өрәк* кушымчалары белән ясала: *йәшел – йәшелерәк, кара – кararак, кызыл–кызылрак, зәңгәр-зәңгәррәк*. Еш кына, мондый очракларда тартыклар чиратлашуына тап булабыз: әгәр сыйфат-сүз к, ҡ, п авазларына бетә икән, чагыштыру дәрәҗәсе ясалган вакытта әлеге авазлар г, ғ, б авазлары белән чиратлаша: *күк – күгерәк, ябыҡ – ябығыраҡ.*

Шуны өстәп әйтергә кирәк, чиратлашу рәвеш дәрәҗәләре ясалганда да барлыкка килә: *күп – күбрәк, шәп – шәберәк, озак – озаграк.*

***Абайлабыраҡ*** *ҡараһа, күрше урыҫ ауылындағы белешенең өйө икән. Инде ни эшләргә? Көн дә кисләп бара, үгеҙҙең дә көйшәп алғыһы*

*килгәндер. (Батырҙар тураһында әкиәттәр). Сәлмән үҙе килһә, утынды икәүебеҙҙән дә* ***күберәк*** *тейәп алып ҡайтыр. Әсәйебеҙ беҙҙе түгел, уны маҡтар (Батырҙар тураһында әкиәттәр).*

Әлеге мисалларда [п] һәм [б] авазларының чиратлашуына тап булабыз. Татар теленнән аермалы буларак, чагыштыру формасы ясалганда, шул исәптән чиратлашу барлыкка килгәндә дә, авазлар редукциягә бирешми.

Тартым белән төрләнгән очракта да, тартык авазлар чиратлашуга дучар булалар:

*Һаман өҙөлөр ул, "балам", тиеп,*

*Һыҙлаһа ла* ***йөрәге*** *яраһы* (Кәтибә Кинйәбулатова).

*4.Әбей, килеһенен тағы ла* ***шәбен*** *ҡыуалап, ҡыҙҙарҙы ашайым тип, ҙур өмөт менән ауыҙ һыуҙарын йотоп, шәберәк китте, ти (Башкорт халык әкияте).*

Башкорт телендә саңгырау тартыклар яңгыраулашуының тагын бер сәбәбе: әлеге авазлар алдында сузыкка яисә яңгырау тартыкка беткән сүз килеп, алар арасында пауза булмау (*бергөн = бер+көн; казғанаты = каз+ канаты*). Татар телендә исә кушма сүзләрдә язылыш кагыйдәсе саклана: *беркөн, аккош, акбур, өчпочмак тимераяк* һ.б. Тарихи искәрмә: *бүген* (*бу+көн*).

Шулай итеп, татар һәм башкорт телләрендә тартыклар чиратлашу очракларының төрлесенә тап булабыз. Һәр ике телдә дә чиратлашуны билгеле бер фонетик закончалыкка бәйләп булса, аерым бер мисалларның тарихи чиратлашуга, сөйләмгә инде нәкъ шул вариантта кулланганлыгын да күзәтә алабыз. Бу мәсьәләдә сузыклар чиратлашуы да аерым игътибарга лаек. Төрки телләрнең чагыштырма фонетикасы белемендә бу сорау әле дә ачык тора.

**Әдәбият**

1. Академический словарь башкирского языка. в 10 тт. / под ред. Ф. Г. Хисамитдиновой. – Уфа: Китап, 2011. – Т. 1. – 432 с.

2. Дмитриев Н.К. Грамматика башкирского языка. – М.: Наука, 2008. – 342 с.

3. Татар грамматикасы. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Т. I. – 512 б.

4. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 2002. – 406 б.

5. Яфаров Л.И. Татар теле фонетикасының кайбер закончалыклы тенденцияләре: Филол. фән. канд. ... дисс. – Казан, 1955. – 264 б.

## БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИЛЕШ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ЯРКӘЙ АВЫЛЫНЫҢ ГОДОНИМНАРЫ

*Юнысова Р., М. Акмулла ис. БДПУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. И.С. Насипов*

Урам исемнәре безнең тарихи мирасыбыз булган торак пункт топонимикасының мөһим өлеше. Исем – урамның «визит карточкасы» гына түгел, ул үзе барлыкка килгән чорның үзенчәлекле һәйкәле, алар ата-

бабаларыбыздан калган тарихи ядкяр. Шул сәбәпле,мине күптәннән туган авылмның урам исемнәре кызыксындыра.

*Югары Яркәй* – Башкортостан Республикасының Илеш районы үзәге. Шулай ук Югары Яркәй авыл совет биләмәсе үзәге дә булып тора. Уфадан 160 км ераклыкта Базы елгасы буенда урнашкан. Административ үзәктә 10 меңнән артык кеше яши. *Яркәй* авылы XVII гасыр уртасында *Елан* дип аталган.Соңрак авылның абруйлы кешесе - Яркәй Янчурин исемен алган. Бүген Югары Яркәй һәм Түбән Яркәй авыллары бар.

Югары Яркәй авылында 82 урам бар.

*Елга* урамы. Бу урам үз исемен XIX гасыр ахырында, Базы елгасының уң як яры буенда урнашканлыктан алган. Ул вакытта *Елга* урамы бердәнбер урам булган һәм Яркәй Янчуринның нәсел варислары да шунда яшәгән. 1935 елда *Куйбышев* урамы итеп үзгәртелә. Совет чорында мондый идеологик яссылыкта барлыкка килгән урам атамалары байтак. *Совет* урамы. Элек бу урам Уфа, Мәскәү, Бөре, Минзәлә кушылган трактка бәйле *Таш* урамы дип аталган. Ул 1937 елдагы картада теркәлгән. Халыкта аны *Екатерина юлы* дип йөртәләр. Риваять буенча, император үзе бу юлны төзергә кушкан, имеш. Әкренләп урам Иске Күктау авылы ягына, көнбатышка таба киңәя. *Ленин* урамы.Ул Бөек Ватан сугышыннан соң барлыкка килә. *Коммунистик* урамы бөтен авыл аша, көньяктан төньякка таба уза. Ул 1930 елларда барлыкка килә. 1950 елларда да биредә җирле административ органнар урнаша башлый. *Комсомол* урамы атамасы яшьләр оешмасы хөрмәтенә кушылган. Мондыйлар рәтенә шулай ук *Дзержинский, Ульянов, Зорге, Фрунзе, Киров,Чеверев,Чапаев* исемле урамнарны да кертеп була. *Кызыл Армия* урамы КПССның Илеш райкомы беренче секретаре Т.Л. Рахманов тәкъдиме белән аталган.

Илебезнең күренекле шәхесләре исемнәре белән аталган урамнар да байтак: *Пушкин, М. Горький, Фадеев, Шолохов, Гагарин, Салават Юлаев, Ломоносов, Жуков* исемнәрен йөртүче урамнар шундыйлардан.

XX гасырның 80 нче елларында *Октябрьнең 50 еллыгы, Яшьләр, Матросов* урамнары, *Каразирек* елгасы аша төзелгән күпергә бәйле *Күпер* урамы барлыкка килә.

XX гасыр азагында Югары Яркәйдә авыл урамнарына исем бирүдә сакчыл,уйлап карар кабул итү сизелә. Урам атамалары итеп күренекле якташларыбыз исемнәре алына: *Яримов* урамы (Яримов – җирле мәгърифәтче һәм сәясәт эшлеклесе), *М. Гәрәев* урамы (Муса Гәрәев – ике тапкыр Советлар Союзы Герое),*Абдуллин* урамы (Әнвәр Абдуллин – Советлар Союзы Герое) *Р. Хәйри* урамы (Ринат Хәйри – күренекле шагыйрь һәм журналист), *Г. Рәфыйков* урамы,(Габбас Рәфыйков – Илеш район Советының беренче рәисе), *С. Газизова* урамы (Сәлимә Газизова - БАССРның атказанган табибы, Ленин ордены һәм Хезмәт Кызыл Байрагы

ордены кавалеры), *Г. Сираев* урамы (Габдрахман Сираев – "Башкортстан" колхозы рәисе), *Х. Сарьян* урамы (Хәсән Сарьян – күренекле татар язучысы).

Авылның һәм төбәкнең тарихы да урам исемнәрендә чагылган. *Иванов* урамы атамасы 1960 елда яшәүдән туктаган элеккеге *Ивановка* хуторы исемен алган.Ул бүген авыл эченә кереп китеп бара. *Яркәй Янчурин* урамы *Яркәй* авылына нигез салучы кешеләрнең берсе Яркәй Янчуринның исем-аты.

Күренекле татар һәм башкорт әдипләренең исемнәре дә кушылган урамнар бар. Алар атамаларында Һ. Такташ , Ш. Бабич, Х. Дәүләтшина, З. Биишева, М. Җәлил исемнәре мәңгеләштерелгән.

*Спорт* урамында бик күп спорт мәйданчыклары һәм спорт комплекслары урнашкан. Казан юлы М-7 трассасы аша күрше Бакалы районына таба бара торган юл янәшәсендә *Бакалы* урамы сузылган.

Илебез тарихында урын алган күренекле бәйрәмнәргә бәйле *Олимпия*, *Җиңүнең 70 еллыгы урамы*, *9 Май* урамнары аталды. Топонимнардан *Баймак* һәм *Урал* атамалары да урам исемнәре буларак урын алган.

Соңгы елларда яңа урамнарга *Яшел* (Зелёная), *Роща* (Рощинская) , *Ылыслы* (Хвойная), *Нарат* (Сосновая) кебек матур исемнәр кушу да күзәтелә. Югары Яркәйдә шулай ук ике тыкырык бар – *Китапханә* һәи *Чеверев* тыкырыклары.

Шулай итеп, *Югары Яркәй*нең урам исемнәре авылның үткәнен һәм бүгенгесен чагылдыра. Алар аша без туган якның тарихын,үсеш-үзгәрешен күзәтә алабыз, күренекле шәхесләре белән танышабыз. Шулай ук бу атамалар район, республика һәм Туган илебез тарихына да бәйле. Шуңа күрә без аларны өйрәнү аша яшь буында туган телебезгә, тарихыбызга сакчыл караш, хөрмәт һәм горурлык хисе тәрбияли алабыз.

**Әдәбият**


1. Никонов В.А. Введение в топонимику. – М., Наука, 1965. – 179 с.
2. Усманова М.Г. Имя отчей земли. Историко-лингвистическое исследование топонимии бассейна реки Сакмар. – Уфа: Китап, 1994. – 272 с.
3. Хисамитдинова Ф.Г. Башкирская ойконимия XVI-XIX вв. – Уфа: Башир. кн. изд-во, 1991. – 304 с.
4. Шакуров Р.З. По следам географических названий. – Уфа: Башк. кн. издво, 1986. – 184 с.


## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЫШАНУЛАР


*Ягафарова А., Казан, 6 нчы гимназия, XI сыйныф*

*Җит. – Г.Н. Хафизуллина, М.З. Закирова*


Безнең бүгенге әдәбиятыбыз халыкның поэтик иҗатына, аның сүз сәнгатенә, фольклорга барып тоташа. Фольклор сүзе "халык акылы" дигән мәгънәгә ия. Ә халык акылы бик күп гасырлар дәвамында формалашкан. Бүгенге көндә фольклорда бик күп төрле жанрлар билгеле.

Татар халык авыз иҗатында киң таралган жанрлар булып җырлар, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, әкиятләр, легендалар, мәзәкләр, бәетләр, дастаннар санала. Галимнәр фикеренчә, бу жанрлар борынгы ышану-мифлардан килеп чыккан. Борынгы мифлар халык авыз иҗатының нигезен тәшкил итә. Шулар арсында ышанулар да бар.

Бүгенге көндә дингә ышанучылар бик күп булса да, кешеләрнең күбесе хаман да төрле мифик затларга, ияләргә ышанып яши бирә. Тормыш-көнкүрештә бу бигрәк тә ачык күренә.

Мәсәлән, гади халык яшәешеннән моңа мисалларны шактый күп китерергә була:

- *Ашаган сыныгыңны калдырсаң, иптәшең ташлар, яки бәхетең тулы булмас;*
- *Ашап утырган чәйгә икмәк кисәге төшсә, өйгә кунак килә;*
- *Бусагага утырсаң, үсми каласың;*
- *Берәр кеше ерак юлга киткәч, аның артыннан ук идән себерергә ярамый* һәм башкалар.

Әлеге һәм башка ышануларны без көн саен диярлек ишетеп яшибез, аеруча әби-бабайлар белән бергә яшәгән гаиләләрдә алар еш ишетелә.

Эзләнү эше барышында без үзебезнең гаиләләрдә ишеткән ышануларны тупладык, аларны җентекләп өйрәндек. Безнең фикеребезчә, ышануларны берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1. Ашау белән бәйле ышанулар:

*Тоз чәчелсә, талаш чыга;*

*Идәнгә төшкән ризыкны кабарга ярамый – җен кагылган булуы бар* һ.б.

Киенү белән бәйле ышанулар:

*Киемне кигәндә җырларга ярамый, салганда елавың бар;*

*Ккиемне өстеңдә кигән килеш тегәргә яки ямау салырга ярамый – сәламәтлегең белән кыенлыклар кичерерсең* һ.б.

2. Юлга чыгу белән бәйле ышанулар:

*Юлга чыгар алдыннан киемне ямарга, төймә тагарга ярамый – юлда бәхетсезлек саклап торыр;*

*Юлга чыккач, әйберең онытылса, кире кайтырга ярамый, кайткан очракта көзгегә карап алырга кирәк* һ.б.

3. Хуҗалык кирәк-яраклары белән бәйле ышанулар:

*Җирдә яткан көрәк, тырманы атлап чыксаң, бәхетсезлек килер;*

*Кояш баеганнан соң чүп ташларга ярамый* һ.б.

4. Йорт белән бәйле ышанулар:

*Бусагага утырсаң, үсми каласың;*

*Идән себергәндә ишеккә таба түгел, киресенчә, ишеккә каршы себерергә кирәк, йорт бәрәкәте чүп чыгарга мөмкин* һ.б.

Мисалларга караганда, ышанулар безнең халык күңелендә шактый нык урын алган, аларга игътибар итүчеләр дә, ышанмаучылар да бар.

Татар халык авыз иҗатында ышануларга бик охшаш жанр – сынамышлар да билгеле. Сынамышлар һәрвакыт авыл кешесенең көндәлек эшләре, көнкүреше, ахыр чиктә аның ач яки тук булуы белән бәйләнгән. Сынамышның төп максаты – киләчәкне хәбәр итү, һава торышы ничек булыр, күпме уңыш алыныр, кайсы игеннәрнең күпләп уңуын фаразлау.

Ышану һәм сынамышларның икесенең дә нигезендә нинди дә булса вакыйга-күренешнең булачагына ышаныч белән карау, өмет итү, фараз кылу ята. Халыкта ышанулар ул шул ук сынамышлар диеп кабул итү яшәсә дә, алар арасында аерма зур. Төп эшебездә китерелгән билгеләмәләргә карасак, сынамышлар төрле табигать күренешләре арасындагы бәйләнешләр, элемтәләр турында мәгълүмат бирсә, ышанулар үзәгендә мистик подтекст ята.

Сынамышлар бүген дә бик популяр. Чөнки аларда әйтелгән фаразлар күп очракта дөреслеккә туры килә, чынга аша. Бигрәк тә һава торышына бәйле сынамышлар кешеләр өчен кызыклы, кешеләр андый төр сынамышларга күпләп игътибар бирә. Мәсәлән:

*Карлыгачлар түбән очса, яңгыр явар, югары очса, аяз һава булыр;*

*Апрель актыкларында җылы яңгырлар булса, игеннәр яхшы булыр;*

*Беренче мартта буран булса, карабодай уңар.*

Ышанулардан аермалы буларак, сынамышларны төркемләүдә авырлыклар юк, аларны 4 ел фасылына – җәй, көз, кыш, яз айларына бәйләп, төрле төрләргә бүлеп карарга була. Әйтик, халык арасында кышка, язга бәйле сынамышлар аеруча киң таралган.

Ышану һәм сынамышлар халкыбызның ерак тарихын, милли үзенчәлекләрен, яшәү кагыйдәләрен өйрәнү чыганагы булып та торалар. Аларда борынгыларның фәне дә, сәнгате дә, педагогикасы да чагылыш таба. Шуңа күрә аларда аңлату да, кисәтү дә, тәрбия дә бар.

Халыкның үткәнен белмичә, киләчәге турында сүз йөртеп булмый. Ышану-юраулар, сынамышлар үткән заманны бүгенге һәм киләчәк белән тоташтыра, буыннарның рухи бәйләнешен тәэмин итә.

**Әдәбият**

1. Татар мифлары. Беренче китап: Ияләр, фаллар, ышанулар, им-томнар, мифлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 388 б.

2. Татар мифлары. Икенче китап: Ияләр, фаллар, ышанулар, им-томнар, мифлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 432 б.

3. Бакиров М. Татарский фольклор. – Казань: Ихлас, 2012. – 400 с.

4.Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. / Ф. Урманче. – Казан: Мәгариф, 2009. II т. (Д-С). – 343 б.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ «ТАМЧЫ» КОНЦЕПТЫ

*Япбаров А., Түбән Кама, 20 нче мәктәп, X сыйныф*

*Җит. – И.Ш. Ишмөхәммәтов*

Телне мәдәни күренеш буларак өйрәнү бүгенге көндә бик актуаль. Татар телендә күп кенә концептлар инде тикшерелгән, алар буенча фәнни эшләр башкарылган, ә “тамчы” концепты әлегә кадәр тикшерелми кала бирә. Шуны истә тотып, үз алдыбызга “тамчы” концептының татар телендә чагылышын тикшерү максатын куйдык.

“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә “тамчы” концептының 5 мәгънәсе бирелә [7: 30].

“Татарча-русча сүзлек”тә тамчы сүзенең 3 мәгънәдәге тәрҗемәсе китерелгән [5: 309].

Г.Х. Әхәтовның “Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге”ндә “тамчы” концепты кергән фразеологизмнар теркәлмәгән. Ә.Н. Исәнбәтнең “Татар теленең фразеологик сүзлеге”ндә 2 фразеологик әйтелмә очратырга була [3: 108]. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә, боларга өстәп, түбәндәге фразеологизмнар китерелә: 1) *тамчы гына черем итү* – бик аз гына йоклап алу; 2) *тамчы бөртек* – бик аз гына, бер бөртек кенә; 3) *катрә бөртек (катрә бөртеге) кадәр* – бик аз гына. “Татарча-русча-инглизчә фразеологик сүзлек”тә “тамчы” концепты кергән 4 фразеологик әйтелмәгә тап булдык [6: 204]. “Татарча-русча сүзлек”тә түбәндәге фразеологизмның тәрҗемәсе китерелгән: 1) *тамчы бөртек тә* – ни капли [5: 309].

Г. Саттаровның “Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге”ндә “тамчы” концепты кергән *Тамчы* татар антропонимы теркәлгән. Аның синонимы буларак Нотфә гарәп антропонимы китерелгән [9: 398, 417].

“Татар теленең зур диалектологик сүзлеге”ендә “тамчы” концептының тара сөйләшендә *тамы* дигән диалекталь варианты бирелгән һәм мисал буларак *тамы да* сүзе тәкъдим ителгән. *Тамы да* – бөртеге дә, тамчысы да (ни крошки, ни капли) [8: 605].

Татар теленең синонимнар сүзлегендә тамчы сүзенең синонимнары күрсәтелмәгән. Тик шулай да, тикшеренү барышында, аңлатмалы сүзлек, татар исемнәре сүзлеге һәм диалектологик сүзлектәге мәгълүматларга нигезләнеп, без тамчы сүзенең *катрә* [1: 206], *нотфә* (гарәпчә *тамчы*) [9: 398] һәм тамы [8: 605] дигән синонимнары барлыгын ачыкладык [7: 242].

Г. Тукайның шигърият теле сүзлегеннән күренгәнчә, шагыйрь үз иҗатында “тамчы” концептын шулай ук оста кулланган. “Актык *тамчы* яшь” шигырендә әлеге концепт шигырь исемендә теркәлгән. “Яхшы хәбәрләр” шигырендә “Язгы яңгыр *тамчысы* бер башка *тамчыдан* сорый”, “Мәхәббәт” шигырендә “Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр *тамчысы”*, “Ана догасы” шигырендә “Тамадыр мискинәмнең *тамчы-*

*тамчы* күзләреннән яшь”, ә “Укыгыз, кызлар…” шигырендә “*Тамчы-тамчы* тамган судан тирән диңгезләр булыр” юлларында кулланылган [10: 160].

М. Җәлилнең “Моабит дәфтәрләре” теле сүзлегендә “тамчы” концепты кергән строфаларны шулай ук очратырга була. “Кичер, илем!” шигырендә “Соңгы тамчы каным тамса тамсын, тик антыма таплар кунмасын!”, “Сандугач һәм Чишмә” балладасында “Бер *тамчы* эчә дә чишмәгә егыла”, “Ах, әгәр булсачы бер генә *тамчы* су! , Зөбәрҗәт *тамчылар, Тамчылар* сикерми, “Кар кызы” шигырендә Кызның йөзендә тама *тамчылар* “Күлмәк” шигырендә “Ике генә *тамчы* яшь чылатты гөл чуклары төсле керфеген”, “Һәр чигештә күпме яшь*”*, “Соңгы үпкә” шигырендә “Мин тапмадым җирдә бер *тамчы* су”, “Ана бәйрәме” шигырендә “Һәр *тамчысы* хәләл сөтемнең, “Чәчәкләр” шигырендә “Йотып тир һәм яшь *тамчысын”*, “Яңа ел теләкләре” шигырендә “Яшебезнең кайнар *тамчысын* кебек” “тамчы” концепты кергән юллар бар [2: 131].

Дөнья тел картинасын анализлау өчен мәкаль һәм әйтемнәрне анализлау мөһим санала. Шуның өчен без “тамчы” компоненты булган мәкаль һәм әйтемнәрне дә барладык. Н.С. Исәнбәтнең “Татар халык мәкальләре” (I том) җыентыгында “тамчы” сүзе аерым сүзлек мәкаләсе буларак кулланыла һәм ул концепт кергән 21 берәмлек китерелә [4: 336].

Интернет челтәрендәге татар халык мәкальләре тупланмасында боларга өстәп тагын 6 мәкаль-әйтем очраттык: 23) Бер тамчыдан диңгез булмый. 24) Күл тамчыдан җыела. 25) Тырышкан *тамчы* таш тишкән. 26) Адым-адым – юл булыр, *тамчы-тамчы* – күл булыр. 27) Ике *тамчы* су кебек.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: “тамчы” концепты телдә югары ешлыкка, күпмәгънәлелеккә ия; актив лексика; актив ясагыч нигезле сүз (таму, тамчылы, тамчыдай, тамчылану, тамчыландыру, тамчылап, тамчылау һ.б.). “Тамчы” бер составлы атау җөмләнең баш кисәге, шигырь исеме була ала (“Бер тамчы жылылык”, “Мәхәббәт тамчылары”, “Там там, тамчы, там”, “Тамчылар”, “Тамчы гөл”, “Тик бер тамчы якты кирәк җанга”, “Тамчы гөлем”, *“Тамчылар маршы”*). “Тамчы” лексемасының синтагматик бәйләнешләре дә киң: тамчы – тама, тишә, җиңә, яра, уйный.

Бу концептны репрезентацияләүче тел һәм сөйләм материаллары халык тарихын, халыкның тормышка мөнәсәбәтен ачыкларга ярдәм итә. “Тамчы” концепты милли концепт критерийларына туры килә.

Шулай итеп, “тамчы” концептын тикшерү барышында без аның татар теле дөнья күренешендә мөһим урын алуын, аны баетуга өлеш кертүен ачыкладык. “Тамчы” концепты да халыкның дөньяны танып белү үзенчәлекләрен, яшәү принципларын билгеләргә ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре / К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сәйфуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. – 792 б.

2. Муса Җәлил. “Моабит дәфтәрләре” теле: Сүзлек / К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримуллина, Л.С. Минһаҗева. – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.

3. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. 2 томда. Т. II. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 365 б.

4. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. 2-нче басма. Т. I. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 622 б.

5. Татарско-русский словарь: В 2-х т. Т. II (М–Я). – Казань: Магариф, 2007. – 309 с.

6. Татарча-русча-инглизчә фразеологик сүзлек. – Казан: Хәтер, 2010. – 296 б.

7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда, Т. III. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 831 б.

8. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.

9. Саттар-Мулилле Г. Татар исемнәре ни сөйли?: Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге. – Казан: “Раннур” нәшр., 1998. – 485 б.

10. Габдулла Тукай: Шигърият теле: Сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2009. – 527 б.

ЭЧТӘЛЕК

**Аббазова Р.** Сонеты в творчестве Уильяма Шекспира и Рената Хариса……………… 4
**Абужалитова А.** Білім мазмұнын жаңарту жағдайында критериалды бағалау – оқушылардың ізденімдік-танымдық құзыреттілігін қалыптастырудың негізі........... 6
**Альмеева М.** Этнонациональное в пословицах татарского народа…………………. 10
**Аманжанова А.** Репрезентация языковой картины мира в жанрах фольклора…….. 12
**Амирханова Л.** Насколько друг друга понимают азербайджанцы и татары……….. 14
**Арипбай А.** Әлемдік тілдік бейнесіндегі «Аққудың» танымдық сипаты…………… 17
**Әбрарова А.** Казан шәһәре урам исемнәренең орфографик үзенчәлекләре............... 20
**Әминова Г.** Эмоцияләрне белдерүдә синонимлык мөнәсәбәтләре............................ 22
**Әсхәдуллина Г.** Татар мәдәниятендә хатын-кыз сыйфатлары бирелеше.................. 25
**Әхмәдиева Й.** Шагыйрь шәхесен мәңгеләштерү: Татарстанда Тукайга һәйкәлләр... 27
**Әхмәтгәрәева Г.** Фэнтези әсәрләренең татар һәм төрек тәрҗемәләрендә реалияләр бирелеше........................................................................................................... 29
**Әхсәнова Г.** Олуг шәхес – Рәшит Рәхмәти Арат........................................................ 31
**Бариева А.** Чыңгыз Айтматов әсәрләренең татарчага тәрҗемә үзенчәлекләре........ 34
**Баһавиева Ч.** Татар халык сынамышларында кулланылган тезмә сүзләрнең ясалыш үзенчәлекләре................................................................................................ 36
**Болгарова А.** Сравнительные конструкции в фольклорных текстах (на материале татарских и русских загадок) ....................................................................................... 38
**Ван Янь.** Ассоциативное поле лексемы «счастье» в русском языковом сознании… 40
**Вәлиева А.** Якташ шагыйребез иҗатында поэтик бизәкләр...................................... 42
**Вилданова Ә.** Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романында һәм аның рус теленә тәрҗемәсендә синонимик парлы сүзләр.................................................................... 44
**Волков Т.** Сөйләшсәк тә төрле телләрдә...................................................................... 46
**Габдрахманова Л.** Г. Ибраһимов һәм Ш. Камал иҗатларында маринистик пейзаж 48
**Габдуллазянова Г.** Роль повтора в создании ритма и рифмы в произведениях детского фольклора………………………………………………………………... 50
**Габдуллин Р.** Г. Сабитов хикәясендә образ тудыру үзенчәлекләре.......................... 52
**Габдуллина А.** Лингвострановедение как область методики и лингвистики……… 54
**Габидуллина Э.** И. Юзеевның «Мәңгелек белән очрашу» поэмасында символик образлар……………………………………………………………………………….. 56
**Гайнуллина Д.** Ә. Еники публицистикасында бөек шәхесләр язмышы……………. 58
**Гайфуллина И.** Россия Федерациясенең төрки антрополисонимнары .................... 60
**Галәветдинова Л.** Массакүләм мәгълүмат чараларында спорт терминологиясе..... 63
**Галеева А.** Интертекстуальные вкрапления в творчестве татарского поэта XX века Ильдара Юзеева…………………………………………………………………… 65
**Галиәхмәтова Д.** Һ.Такташ иҗатында тел-сурәтләү чаралары................................ 68
**Галиева К.** Равиль Бухараев – интеллектуальная гордость нации!.......................... 70
**Галимбикова И.** Национальная и культурная идентичность в рамках межкультурного взаимодействия…………………………………………....... 73
**Галимова Д.** Лилия Гыйбадуллина иҗатында образлар бирелеше.......................... 75
**Гарипова Д.** XIX гасыр татар һәм чуваш әдәби телләрендә фонетик вариантлар.... 77
**Гафарова А.** Язык жестов в произведениях Рината Мухаммадиева………………... 79
**Гафиятова И.** Габдулла Тукай һәм Ленар Шәехнең балалар өчен язылган шигырьләрендә тиңдәш кисәкләр.................................................................................. 82
**Гафиятуллина Э.** Ә. Еники иҗатында фольклор традицияләре................................ 84
**Гафурова И.** Татар теле дәресләрендә төбәк тарихына караган материалларны куллану..... 86

**Гәрәев А.** Флүс Латыйфинең «Хыянәт» романында тел-бизәкләү чарасы буларак искергән сүзләр........................................................................................................... 88
**Гәрәева А.** Лингвокультурологик текстларның стилистик үзенчәлекләре…………. 90
**Гетманская С.** Лингвокультурологический компонент в преподавании иностранного языка с помощью социальных сетей (на примере инстраграм)…....... 92
**Гилмутдинова Ә.** Татарларда сәер исемнәр................................................................ 94
**Гыйздәтуллина Н**. Татар таҗына лаек олуг шәхесләр……………………………….. 96
**Гыймадиев Б.** Зөлфәт Хәкимнең «Телсез күке» драмасында символик образларның әдәби функциясе.......................................................................................... 98
**Гыйниятуллина Д.** Сынлы сәнгатьтә Бакый Урманче............................................... 100
**Гыйсмәтуллина Д.** Мансур Гыйләҗевның «Бичура» пьесасы буенча куелган спектакльдә Бичура мифологик образы....................................................................... 103
**Давлетзянов И.** Язык сказок Алиша и экологические задачи……………………….. 105
**Джумагалыева Р.** К вопросу о национальных особенностях языковой картины мира (на примере казахского и русского народов)…………………………………… 107
**Дурдыева М.** Язык и культура…………………………………………………… 109
**Евдокимова А.** Туфан Миңнуллинның «Гөргери кияүләре» этнографик музыкаль комедиясендә образлар бирелеше................................................................................... 110
**Ержан Г.** Структура романа О. Уайльда «Портрет Дориана Грея» в свете философии Платона…………………………………………………………………….. 112
**Ершова Е.** Универсальные черты и свойства «детства» в произведениях М. Горького ……………………………………………………………………………… 116
**Жалгасова Ж.** История изучения казахского народного лиро-эпоса «Кыз жибек»... 118
**Жантасова Н.** Академик Р. Сыздық және қазақ тіл білімінің өзекті мәселелері........ 120
**Жаскайратова А., Сарсенгалиева А.** Ауэзов и о переводе калмыцкого героического эпоса «Джангар».......................................................................................... 122
**Җамалетдинова Д.** Юридик лексикада гарәп алынмалары....................................... 124
**Җиһаншина М**. Татар халык җырларының поэтик үзенчәлекләре........................... 127
**Закирова А.** К проблеме исследования концепта «хлеб» в разных лингвокультурах 129
**Закирова Ә.** «Ватаным Татарстан» газетасында сәламәтлек темасына багышланган мәкаләләрнең үзенчәлеге.......................................................................... 132
**Зарипова З.** Проблемы переключения кода при обучении английскому языку (татар и русских)……………………………………………………………………… 134
**Зәйнетдинова Р.** Татар теле дәресләрендә аудиовизуаль чаралар............................. 136
**Зиннурова Э.** Формирование речевых компетенций на иностранном языке............ 138
**Ибраһимова А.** Татар паремияләренең лингвокультурологик потенциалы………... 141
**Ибраһимова Д.** Әдәбият дәресләрендә нәзари төшенчәләрне өйрәнү....................... 142
**Ибраһимова Р.** Рабит Батулла иҗатында Тукай образы............................................ 144
**Ибраһимова Э.** Кабатлаулы фигыльләрнең эмоциональ-экспрессив мәгънәләре.... 146
**Исламгареева Г.** Башкортостан Республикасы Шаран районы Күгәрчен-Бүләк авылы топонимикасы..................................................................................................... 149
**Исламова Л.** Татар һәм казах телләрендә соматизмнар……………………………... 152
**Исхакова Г.** Грамматические переводческие соответствия в переводах стихотворений А. Ахматовой на турецкий язык……………………………………………… 154
**Кабдрашова М**. Қазақ тіл біліміндегі гендерлік зерттеулер………………………… 156
**Кадыйрова Г.** Паремияләрдә хатын-кыз образы......................................................... 159
**Қазмағамбетова А.** «Қыз жібек», «Айман-шолпан» жырларының басылымдары жөнінде......................................................................................................................... 161
**Камалдинова И.** Этикет татарского застолья в селе Токаево……………………….. 164

**Камалова Д.** Лингвистик тикшеренү объекты буларак поэтик текст........................ 166
**Канапьянова Д.** Шәкәрім шығармашылығы – рухани білімнің қайнар бұлағы......... 168
**Кашаева А.** Использование мнемотехнических приемов при обучении детей в школе………………………………………………………………………………… 171
**Каюмова А.** Роль родного языка при изучении иностранного языка на примере звуковых систем английского и татарского языков…………………………………… 173
**Кәлимуллина А.** Гаяз Исхакыйның драма һәм проза әсәрләрендә милләт язмышы 175
**Кәримова А.** Мин кулыма китап алам………………………………………………… 178
**Көшімбет М.** М. Әуезов драмаларындағы вестиалды лексиканың рөлі…………….. 180
**Құлмағамбетова Ж.** Жазба жәдігерлер тілі мен қазіргі қазақ тілі: ұқсастықтар мен айырмашылықтар.............................................................................................................. 183
**Құмарова Э.** Общая характеристика восточной поэмы «Гяур» Джорджа Гордона Байрона………………………………………………………………………………… 187
**Ли Цзюньин**. К вопросу семантизации национально-культурной единицы в современных словарях лингвокультурологического типа…………………………. 190
**Макаров И.** Технология обучения аудированию....................................................... 192
**Матигуллина Р.** Башкортостан Республикасы Балтач районы Югары Карыш авылы тарихы турында....................................................................................................... 194
**Мингалиева К.** М. Хөсәеннең «Кытай дусыма» шигырендә тел-бизәкләү чаралары............................................................................................................................ 196
**Минемуллин Р.** Зөфәр Рәмиевның гыйльми эшчәнлегендә Габдулла Тукай энциклопедиясен төзү мәсьәләләре............................................................................ 198
**Миннекеева А.** Кулинария текстлары тәрҗемәсендә транслитерация алымы......... 201
**Миннибаева А.** Башкортстан Республикасы Ярмәкәй районы Абдулла авылы топонимикасы................................................................................................................... 203
**Мисбахова С.** Матур әдәбият әсәрләрендә чагыштыруларны тәрҗемә итү үзенчәлеге (Г. Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» әсәре материалында).................. 205
**Михайлов А.** Керәшен халкының йола, бәйрәмнәренә кагылышлы сынамышлар... 208
**Мойнакова А.** Қазақ тілі терминологиясының қазіргі жағдайы................................ 211
**Mohamed Lamine Mariko.** Understanding text complexity…………………………… 214
**Мөдәрисов Д.** Tatar-inform.ru. һәм bashinform.ru сайтларында кулланылган спорт лексикасының структур үзенчәлекләре.......................................................................... 215
**Мөхәммәдиева А.** Халкым өчен мәңге кирәк туган телем!........................................ 218
**Мөхәмммәтгалиева Г.** Аналитик һәм синтетик чараларны өйрәтү методикасы........ 220
**Мөхәммәтҗанова С.** М. Мәһдиев – талант иясе........................................................ 224
**Мухаметзянова Л.** Обучение языковым лакунам на основе текстовой деятельности 226
**Мухаметова И.** Особенности изучения религиозной лексики в современном татарском языке………………………………………………………………………… 228
**Насыйбуллина К.** Татар телендә ризык атамалары системасы формалашу үзенчәлекләре.................................................................................................................... 230
**Низамиев И.** Р. Шәйдуллинаның «Ялантауга ай кунган» әсәрендә табигатьне саклау һәм кеше бәхете мәсьәләсе.................................................................................. 233
**Низамутдинова Э.** Лингвокультурологический компонент в преподавании иностранного языка с помощью подкастов (на примере немецкого языка)………… 235
**Оспанова Ж.** О функциональном аспекте метафоры…………………………………… 237
**Павлова З.** Тел – милләтнең кыйммәтле ядкяре.......................................................... 239
**Пазюкова И.** Нәкый Исәнбәт – драматург.................................................................. 242
**Рамазанова А.** Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романындагы этнолексика........... 244
**Рамазанова Г.** Ф. Яруллинның әкиятләрендә хыял һәм чынбарлыкны бирүдә 246

тылсым элементлары....................................................................................................
**Рамазанова Г.** Ф. Яруллин әкиятләрендә тел-стиль чаралары һәм алар аша дөньяны сурәтләү.................................................................................................... 248
**Рахматуллина Ф.** Лингвокультурологические особенности речевого акта «обещание»…………………………………………………………………….. 251
**Сабирова Н.** «Мәдәни җомга» газетасында теркәлгән кеше шәхесе белән бәйле атамалар................................................................................................................ 253
**Сабитова Л.** Ә.Еникинең «Матурлык» хикәясендәге фразеологизмнарны төрек теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләре (Фатыйх Котлының «Güzellik» тәрҗемәсе нигезендә)........................................................................... 255
**Сағызбаева А., Ғалымжанова А.** Халық ауыз әдебиетінің әлеуметтік маңызы..... 258
**Саетгараева Л.** Морфологические и синтаксические характеристики текста кулинарного рецепта (на материале поваренной книги Е. Молоховец).................... 259
**Сайфиева М.** Сравнительные конструкции как способ отражения языковой картины мира (на материале русского, татарского и английского языков) ............. 261
**Салахова Т.** Чтение как вид речевой деятельности в обучении иностранному языку……………………………………………………………………………….. 263
**Саяпова В.** Образ праведника в русской и татарской прозе (на материале рассказа А.И. Солженицына «Матренин двор» и повести А. Гилязова «В пятницу, вечером»).. 266
**Сәйфетдинова Д.** Әдәбият дәресләрендә фольклоризмнарны өйрәтү (Г. Тукайның «Шүрәле» әсәре мисалында)........................................................................................ 268
**Сәлахов Д.** Әмирхан Еникинең «Җиз кыңгырау» әсәрендә күрүне белдергән фигыльләр.................................................................................................................. 271
**Сәлахова А.** Ф.С. Сафиуллинаның синтаксис өлкәсендәге хезмәтләре..................... 273
**Сеэрмамайти Касэнму.** Отражение лексики словаря Махмуда Кашгари «Диван лугат ат-турк» в современном татарском языке…………………………….. 275
**Сиразова С.** Татар халык мөнәҗәтләрен өйрәнү тарихыннан.................................. 277
**Сулейменова А.** Қазақ әдебиеті сабақтарын интеграциялап оқытудың әдеби және әдістемелік аспектілері................................................................................................ 279
**Сымахэцзань Илиясы.** Татар һәм казах лингвомәдәниятендә исәнләшү йолалары 281
**Сяфукатэ Иэрцзати.** Уйгырлар: мәдәният һәм сәнгать............................................ 283
**Тилеуова Н.** Көркем мәтіндегі кейіпкер бейнесі........................................................ 284
**Тимашева А.** Башкортстан Республикасы Бакалы районы Яңа Маты авылында яшәүче керәшеннәрнең йола лексикасы...................................................................... 287
**Тимофеева Т.** Керәшен халык уен-бию җырларының һәм такмакларының поэтик эшләнеше (Кукмара районы Югары Чура авылы мисалында).................................. 290
**Узум С.** Татар һәм төрек телләрендә исем сүз төркеме............................................. 292
**Уметбаева Н.** Номинация лиц в детской речи………………………………………… 295
**Фаезова Л.** Репрезентация мотива странничества в творчестве М. Юныса………... 297
**Фазылҗанова Г.** Казан шәһәренең гастрономик туризм потенциалы……………… 301
**Фатыйхова И.** Психологик алым буларак тавыш (Шәриф Камалның «Курай тавышы» хикәясе мисалында)......................................................................................... 304
**Фәсхетдинова А**. Бүгенге көн татар яшьләренең рухи-әхлакый кыйммәтләре (ассоциатив экспериментлар материалында).............................................................. 306
**Фәттахова А.** Ф. Әмирхан иҗатында музыка тәнкыйте мәсьәләләре....................... 308
**Фэн Юньхэ.** Национальная специфика образных сравнений (на материале повести А.И. Куприна «Поединок»)………………………………………………………………... 310
**Хаерова Л.** Аш-су рецептларының баш исемнәрен тәрҗемә итү үзенчәлекләре…... 312
**Ханмурзин С.** Ренат Харис иҗатында туган телнең чагылышы…………………… 314

**Ханмурзина Н.** Гөлнур Айзатуллова иҗатында сугыш темасы…………………….. 317
**Хасанзянова Г.** Особенности перевода экономических терминов с английского языка на русский язык………………………………………………………………… 319
**Хасбиева А.** Транслингвизм в изучении языков в би- и полилингвальной среде…. 322
**Хасбиуллина Г.** Җиде саны мисалында тел һәм мәдәният бәйләнеше..................... 324
**Хафизова Я.** Икетеллелек шартларында балалар сөйләмендә барлыкка килгән үзенчәлекләр........................................................................................................... 326
**Хәбибуллина А.** Татар халык мәкальләрендә ат образы........................................... 329
**Хәбибуллина А**. Фатих Әмирхан прозасында Казан образы.................................... 331
**Хәкимова Э.** Татар телендә капка лексемасы…………………………………………… 333
**Хәлилова Н.** Милли горурлык хисе тәрбияләүдә телевидениенең роле.................... 335
**Хөсәенова Р.** Айгөл Әхмәтгалиева хикәяләрендә сурәтләнгән дөнья....................... 337
**Хөсәенова Э.** Татар тел гыйлемендә текст теориясен өйрәнү тарихы……………… 339
**Хөснуллина А.** Ризык атамаларының йолалар белән бәйләнеше…………………… 341
**Хузиахметова Г.** Метод анкетирования, как способ выявления осведомленности населения о культурном наследии……………………………………………………… 344
**Һадиева А.** Прецедент исемнәр һәм метафора терминнары мәсьәләсе...................... 346
**Чан Ваньцзюнь**. Особенности русской и китайской картины мира………………… 348
**Чэнь Ясин.** Архетипические оппозиции в интернет-игре в антифразы…………….. 350
**Шакирова Г.** Шәүкәт Галиев иҗатында күтәрелгән темалар.................................... 352
**Шакирова Ф.** Буа районы сөйләшләре ……………………………………………… 355
**Шәяхмәтова Г.** Башкортстан Республикасы Илеш районы Йонны авылы турында....................................................................................................................... 357
**Шәйхетдинова З.** Роберт Миңнуллин иҗатында әхлак темасы................................ 360
**Шәнгәрәева А.** Татар һәм башкорт тел белемендә тартыклар чиратлашуы очраклары.................................................................................................................... 361
**Юнысова Р.** Башкортстан Республикасы Илеш районы Югары Яркәй авылының годонимнары................................................................................................................ 363
**Ягафарова А.** Татар телендә ышанулар...................................................................... 365
**Япбаров А.** Татар телендә «тамчы» концепты............................................................ 368

*Научное издание*

# ТЮРКСКАЯ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ: проблемы и перспективы

материалы XI Международной научно-практической конференции учащихся, студентов и аспирантов

Казань, 20-21 февраля 2020 г.

Подписано в печать
Бумага офсетная. Печать цифровая.
Формат 60х84 1/16. Гарнитура «Times New Roman». Усл. печ. л.
Уч.-изд.л. Тираж зкз. Заказ

Отпечатано с готового оригинал-макета
в типографии Издательства Казанского университета

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37
Тел.: (843)233-73-59, 233-73-28